# ШУРА

№23

2019

Печән базары мәчетенә

170 ел



ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК

ВӘГАЗЬЛӘР
Аллаһыга шөкер кылып, рәхмәтле булып яшәү . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Намаз – диннең терәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Бүгенге заман мөселманы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Хиҗаб: өстенлеге һәм әһәмиятлелеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Мәчеттә үз-үзеңне тоту әдәпләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Дога – сорау, ялвару . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Ир-ат вазифалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Рәгаиб – гаиләнең әһәмиятен искә төшерү . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Исламда хатын-кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Ришвәтчелек – җәмгыять чире . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Мөселманның милләткә һәм ватанга мөнәсәбәте . . . . . . . . . . . . 69
Мигъраҗ кичәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Галимнәр, гыйлем турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83

СОРАУ – ҖАВАП
Җеназа мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Мөлкәт бүлешү әдәбе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

ҮРНӘК ЗАТЛАР
Дүртенче тугры хәлифә – Гали радыяллаһу ганһе . . . . . . . . . . . . 98
Гайшә бинте Әбү Бәкер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Бөек имам Әбү Хәнифә Ногман бине Сәбит Әл-Куфи . . . . . . . . . . 115

ФӘН
Коръән турында гыйлем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Әл-Мәтуриди тәгълиматы татарларга ничек үтеп кергән? . . . . . . . 128

ТАРИХ
Пәйгамбәрләр тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Ике тәфсир тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Морад Рәмзи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Тугызынчы мөфти – Габдеррахман Расүли . . . . . . . . . . . . . . . . . 153

Унынчы мөфти – Шакирҗан Хияледдинов. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Мөселман галимнәренең казанышлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156

ТӘРБИЯ
Өйләндерүдә ата вә ана вазифасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161

МИРАС
Чистайның беренче җәмигъ мәчетенә – 160 . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Чистай шәһәренең икенче җәмигъ мәчете. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Печән базары мәчете тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

НӘСЫЙХӘТ
Дәгъват кылу ысулы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Динебездә юмартлык үрнәкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Сихердән ерак булыйк!. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Намазда сафларның тигезлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 200

ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА
«Кәнзүл-Гареш» догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204

**«ШУРА» дини альманах, №23**

*гыйнвар – март 2019*
*рабигыль-ахыр – раҗәб 1440*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП:**
Рәмзилә Шафикова
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ӘДӘБИ РЕДАКТОРЛАР:**
Рәмзилә Шафикова
Лилия Хәләфетдинова

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Инфо систем» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420044, Казан ш., Ямашев проспекты, 36 Б*
*Тел./факс: +7 (843) 519-91-10*
*Сайт: http://kpkps.ru/*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 28.12.2018
Чыгу көне: 21.01.2019

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

# Вәгазьләр

*11 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Аллаһыга шөкер кылып, рәхмәтле булып яшәү

Җир-күкләрне яратып, яңгырлар яудырып, шуның белән безгә барлык җимешләрен дә ризык итеп тәкъдим кылган, безне төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Ихлас күңел белән, Аллаһының әмеренә буйсынып, дога һәм гыйбадәт кылу өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Изге җомга көнебез барчаларыбызга да мөбарәк һәм хәерле булсын!

Аллаһы Раббыбыз Җирне һәм күкләрне, алар арасында булган барча мәхлүкатны нинди гүзәл итеп яраткан. Адәм балаларын акыл белән зиннәтләп, нинди гүзәл, камил сурәттә бар кылган. Шушы гүзәллекне күрү, тою, шул гүзәллек эчендә яшәү бәхет түгелме? Аллаһының бетмәс-төкәнмәс нигъмәтләренә без шөкер кылырга тиеш түгелме?

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәркем һәр көнне үзенең һәр буыны өчен садака бирсен», – дип әйткән. Йокыбыздан уянып, исән-имин килеш аякларыбызга басканбыз икән, «Әлхәмдүлилләһ!» – дип әйтеп, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылыйк, чөнки Ул безгә тагын бер көн бүләк итте.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән нигъмәтләре бихисап. Болар – кояш, сулаган һавабыз, һәр сулыш алу-

ыбыз, акыл, сәламәтлек, ашаган ризыгыбыз, кигән киемнәребез һәм безнең әйләнә-тирәбездә булган бик күп башка нигъмәтләр. Ни кызганыч, күбебез әле моны Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләре булуын танымый, шулай тиеш, дип кабул итә.

Шөкер итү – «Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләре өчен рәхмәт белдерү һәм аны сүз һәм гамәлләребез ярдәмендә ирештерү». Коръәни Кәримдә шөкер итү буйсынучанлыкның төп билгесе булуы һәм Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләренә шөкер итмәгәннәрнең шелтәләнүе хакында әйтелә. Мәсәлән, Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә Аллаһы Тәгалә:

وَاللَّهُ أَخْرَجَكُم مِّن بُطُونِ أُمَّهَاتِكُمْ لَا تَعْلَمُونَ شَيْئًا وَجَعَلَ لَكُمُ السَّمْعَ وَالْأَبْصَارَ وَالْأَفْئِدَةَ ۙ لَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ ﴿٧٨﴾

**«Аллаһы сезне аналарыгызның карыныннан чыгарды, ул вакытта һичнәрсә белми идегез. Сезгә колак, күз вә күңел бирде, шулар белән белә башладыгыз, шуларны уйласагыз, шаять, шөкер итәрсез!»** – дип әйтә.

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:78

Шөкер итү – кешенең үз хәленнән канәгать булып, Аллаһыга рәхмәтләрен белгертүедер. Аллаһы Тәгалә кешеләргә санаусыз нигъмәтләр биргән. Ашау-эчүләребезне дә бар иткән, саулыкта яшәткән бөек зат – Аллаһы Тәгалә. Акыл, рух, гәүдәбезгә көч-куәт биреп, төрле эшләрне башкарырга мөмкинлек кылучы да – Аллаһы Тәгалә. Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَإِن تَعُدُّوا نِعْمَةَ اللَّهِ لَا تُحْصُوهَا ۗ إِنَّ اللَّهَ لَغَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿١٨﴾

**«Әгәр Аллаһының биргән нигъмәтләрен санап карасагыз, һич санап бетерә алмассыз. Шиксез, Аллаһы ярлыкаучы вә рәхимле».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:18

Бу аятькә биргән аңлатмасында Ибне Җәрир: «Тәхкыйк, әгәр дә сез түбәнчелек һәм Аңа буйсынуга омтылу белән килсәгез һәм Ул риза булырлыкны эшләсәгез, кайбер нигъмәтләренә Аңа рәхмәтләрегезне әйтергә онытсагыз, Аллаһы Тәгалә сезне ярлыкар, чөнки Ул сезгә рәхимле-шәфкатьледер», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кешенең гыйбадәте – Аллаһы Тәгаләгә бирелгән нигъмәтләр өчен шөкер итүе», – дип әйткән. Бирелгән нигъмәтләр өчен шөкер итү сүзләр белән генә түгел, ә шул нигъмәтләрне кулланып та белдерелергә мөмкин. Байлык өчен шөкер итү мохтаҗларга ярдәм итү аша белдерелә, белемнәр өчен шөкер итү шул гыйлемнәрне кешеләр файдасына куллану аша, ә сәламәтлек өчен гыйбадәтләр кылып, хезмәт итеп рәхмәтебезне белдерә алабыз.

Шөкер кылу өч төрле була. Беренчесе – йөрәк белән шөкер итү. Моңа ышанган мөселман ниндидер байлыкка ирешсә, Аллаһы юлыннан һич тә тайпылмас. Нигъмәте арткан саен шөкер итә барыр. Нигъмәткә шөкер итү байлыкны арттырыр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Иманның яртысы – шөкер итү, яртысы – сабырлык», – дип әйткән. Без бүген әллә нәрсәләр турында хыялланабыз, әллә нинди планнар корабыз. Уйлаган эшебез барып чыкмаса, зарланабыз, әллә кемнәрне гаепләп бетерәбез. Әгәр ниндидер берәр уңышка ирешсәк, мактанабыз, тәкәбберлек күрсәтәбез, шөкер кылмыйбыз. Югыйсә, бер генә әгъзабыз да безнең ихтыярда түгел бит. Күзебез күрмәсә, кул-аяклар йөрмәсә, ризыкны йота алмасак, күпме түләү бәрабәренә боларны кайтарып була?

Аллаһы Тәгалә Коръәндә дә болай дип әйтә:

وَمَا بِكُم مِّن نِّعْمَةٍ فَمِنَ اللَّهِ ۖ ثُمَّ إِذَا مَسَّكُمُ الضُّرُّ فَإِلَيْهِ تَجْأَرُونَ ﴿٥٣﴾

**«Сезнең кулыгызда булган нигъмәтләр һәммәсе Аллаһыдандыр. Әгәр сезгә бер зарар ирешсә, авыз күтәреп, Аллаһыга зарланасыз».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:53

Шулай ук Коръәннең башка бер сүрәсендә Аллаһы Тәгалә:

أَلَمْ تَرَوْا أَنَّ اللَّهَ سَخَّرَ لَكُم مَّا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ وَأَسْبَغَ عَلَيْكُمْ نِعَمَهُ ظَاهِرَةً وَبَاطِنَةً ۗ وَمِنَ النَّاسِ مَن يُجَادِلُ فِي اللَّهِ بِغَيْرِ عِلْمٍ وَلَا هُدًى وَلَا كِتَابٍ مُّنِيرٍ ﴿٢٠﴾

**«Әллә күрмисезме, Аллаһы күктә булган кояш, ай, йолдызларны вә җирдә хайваннарны вә табигать байлыгын сезгә файдаландырды, вә сезгә күренгән вә күренмәгән нигъмәтләрен тәмам бирде. Кешеләрдән кайберләре Аллаһы хакында яки Аның дине хакында дәлилсез, белемсез, мәгърифәт нуры булган Коръәннән башка һәм үзе һидаятьсез булган хәлдә хакны инкяр итеп вә ялганны яклап тартышырлар»,** – дип әйтә.

«Локман», 31:20

Беренче шөкер төре – йөрәк белән шөкер итү. Йөрәк белән шөкер итү – ул барлык игелекләрнең дә Аллаһы Тәгаләдән икәнлеген аңлау. Аллаһы Тәгаләдән ирешкән һәрбер нәрсәгә (хәтта аз күләмдә булса да) без рәхмәтле булырга, шөкер итәргә тиешбез. Бер риваятьтә: «Игелекнең аз күләмдә булуына түгел, ә шушы игелекне сиңа биргән Аллаһы Тәгаләнең Бөеклегенә игътибар ит», – дип әйтелгән. Йөрәк белән шөкер итү – Аллаһы Тәгалә биргән һәр нигъмәткә канәгать булу дигән сүз. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Үзегездән яхшырак хәлдә булган кешеләргә түгел, ә сезнекенә караганда начаррак хәлдә булганнарга карагыз», – дип әйткән (Мөслим).

Икенчесе – тел белән шөкер итү. Тел белән шөкер итү – ул барлык нәрсәнең дә Аллаһы Тәгаләдән икәнлеген тану дигән сүз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Аллаһы колына бер нигъмәт биреп, ул «Әлхәмдүлилләһ» дип әйтсә, ул шөкер иткән булыр. Әгәр кеше икенче мәртәбә дә «Әлхәмдүлилләһ» дип әйтсә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең савабын арттырыр, өченче тапкыр кабатласа, гөнаһларын гафу итәр», –дип әйткән.

Өченчесе – әгъзалар белән шөкер итү. Намаз уку, ураза тоту, хаҗ кылу кебек гыйбадәтләр белән бергә, динне аңлату, тарату һәм бу юлда хезмәт итү дә әгъзалар белән шөкер итүгә кирә.

Аллаһы Тәгалә:

إِنَّمَا تَعْبُدُونَ مِن دُونِ اللَّهِ أَوْثَانًا وَتَخْلُقُونَ إِفْكًا ۚ إِنَّ الَّذِينَ تَعْبُدُونَ مِن دُونِ اللَّهِ لَا يَمْلِكُونَ لَكُمْ رِزْقًا فَابْتَغُوا عِندَ اللَّهِ الرِّزْقَ وَاعْبُدُوهُ وَاشْكُرُوا لَهُ ۖ إِلَيْهِ تُرْجَعُونَ ﴿١٧﴾

**«Аллаһыдан башка сыннарга гыйбадәт кыласыз, вә сыннарыгызны Аллаһы дип ялган сөйлисез. Аллаһыдан башка гыйбадәт кыла торган сыннарыгыз сезгә ризык бирергә кадир (көчле) түгелләр. Ризыкны Аллаһыдан сорагыз вә Аңа гына гыйбадәт кылыгыз һәм Аңа шөкер итегез, чөнки хөкем ителергә Аллаһыга кайтасыз»,** – дип әйтә.

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:17

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөенечле берәр нәрсә булганда, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт билгесе итеп һәрвакыт сәҗдә кыла торган булган. Сәхабәләргә килгәндә, алар да һәрвакыт аның үрнәгенә ияргергә тырышканнар. Мәсәлән, риваятьләрдә хәбәр ителә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам заманында Кәгъб бине Мәлик, Аллаһы

Тәгалә аның тәүбәсен кабул итүе хакында аңа шатлыклы хәбәр тапшырылганнан соң, Аллаһыга шөкер итү йөзеннән сәҗдә кылган.

Шулай ук, кояш чыгып сөңге буе күтәрелгәннән алып, өйлә вакыты кергәнче укыла торган ишракъ, духа намазлары да һәр буыныбыз өчен шөкер кылу булып тора.

Коръәни Кәримнең «Ибраһим» сүрәсенең 7 нче аятендә Аллаһы Тәгалә шөкер итүчеләргә нигъмәтләрен арттырырга вәгъдә итә: **«...Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын...».** Аятьнең дәвамында Ул бәндәләрен түбәндәге сүзләр белән кисәтә: **«Әгәр көферлек кылсагыз, Минем газабым бик каты».**

Шөкер кылуның иң беренче билгесе – бу дөньяда да, Ахирәттә дә бөтен нигъмәтләрне бирүче һәм бөтен нигъмәтләрнең хуҗасы булган Аллаһыны тану, Аңа иман китерү. Аллаһыны танымау – иң зур гөнаһ. Аллаһыны танымаучы, бу дөньяда Аллаһының нигъмәтләрен башкалар белән тигез файдалана алса да, Аллаһының Ахирәттә әзерләнгән барча нигъмәтләреннән мәхрүм кала. Ул кешегә җәһәннәм газабыннан башка берни дә юк һәм аның хәлен беркем дә, бу дөньяда тупланган бернинди байлыгы да үзгәртә алмый. Андый кеше Аллаһының бу дөньядагы бер өлеш байлыгына алданып, 99 өлешеннән мәхрүм калучы була.

Шөкер кылуның икенче билгесе – бөтен тормышыңны Аллаһы кушканча көйләү, ягъни Аллаһы кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәү. Аллаһыны танып та, Аллаһы кушканча яшәмәгән кеше, көферлеккә төшмәсә дә, зур гөнаһлы була. Ул Аллаһының олы нигъмәте булган җәннәтенә җәһәннәм газабы аркылы гына ирешә ала.

Аллаһыны танып, кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәгәннәрнең калебләре чиста, иман нуры тышка чыккан була. Алар тормышларыннан канәгать була беләләр. Тормышының ямен арттырыр, җан тынычлыгын табар өчен гел шөкер итеп торырга кирәк. Андый кешенең эшләре дә уңачак. Шөкер кылучы һичбер вакыт Аллаһы Тәгаләне оныт-

мас. Андый кеше дөньядагы байлыгы белән масаеп, кешеләргә өстен карамас, беркемне дә түбән күрмәс. Нигъмәт ягыннан үзеннән түбәнрәк булган кешеләрнең хәленә карап, алардан дөрес гыйбрәт алыр, үзенең хәленә шөкер итәр. Шул сәбәпле, Аллаһы аларның күңелләренә тынычлык бирер.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә:

مَّا يَفْعَلُ اللَّهُ بِعَذَابِكُمْ إِن شَكَرْتُمْ وَآمَنتُمْ ۚ وَكَانَ اللَّهُ شَاكِرًا عَلِيمًا ﴿١٤٧﴾

> **«Ий мөэминнәр! Әгәр чын ышану белән ышанып, Коръән белән гамәл кылсагыз һәм нигъмәтләргә шөкер итсәгез, Аллаһы сезне ник газапларга тиеш соң? Шиксез, Аллаһы чын мөселманлыкның хакын җәннәт нигъмәтләре белән түләүче һәм һәрнәрсәне белүче булды»,** – дип әйтә.

«Нисә / Хатыннар», 4:147

Мөхтәрәм җәмәгать, безнең – мөэминнәрнең – бу дөньяда да саусәламәт буласыбыз, бәхеттә-нигъмәттә яшисебез килә. Ахирәттә дә җәннәтне өмет итәбез. Шушы ике дөнья бәхетенә ирешү өчен без Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләренә шөкер итеп яшәргә тиешбез. Шөкер итсәк, Ул безгә биргән нигъмәтләрне кире алмас, киресенчә, арттырып та кайтарыр. Коръәндә дә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَإِن تَشْكُرُوا يَرْضَهُ لَكُمْ ۗ

> **«... Әгәр Аңа гыйбадәт кылып шөкер итсәгез, Ул эшегездән риза булыр».**

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:7

Хөрмәтле дин кардәшләрем, нәрсә генә эшләсәк тә, әлбәттә, Аллаһы ризалыгы өчен эшләү кирәк. Аллаһы риза булсын өчен тырышып тормышын алып баручы, башкалар сөенгәннән шатлык хисе кичерүче чын

бәхетле кеше була. Барысына да канәгать булып, шөкер кылып, Аллаһы кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп булсын.

*ТЖ МДН Дәгъват бүлеге*

*18 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Намаз – диннең терәге

Галәмнәрне юктан бар кылган, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез булса иде. Аның хак хәбибе Мөхәммәдкә дә йөрәкләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

مُنِيبِينَ إِلَيْهِ وَاتَّقُوهُ وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَلَا تَكُونُوا مِنَ الْمُشْرِكِينَ ﴿٣١﴾

**«Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, һәрвакыт Аңа итагатьтә булыгыз һәм Аңа гөнаһлы булудан сакланыгыз, билгеләнгән намазларыгызны вакытында укыгыз, һәм һичнәрсәне Аллаһыга тиң кылмагыз, мөшриклəрдән булмагыз».**

«Рум», 30:31

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намаз диннең терәге. Намаз кылмаган кеше – динне җимерүче», – дип әйткән.

Ошбу хәдистән аңлашылганча, нигезсез йорт була алмаган кебек, намазсыз Ислам да, мөселманлык та була алмый. Намаз уку һәр мөселманга да үзенең бәхетле булуы һәм үз мәнфәгате өчен кирәк. Үзләрен мөселман дип, әмма намаз укырга вакытым юк, дип йөрүчеләр, ислам динен торгызу урынына, ислам динен җимерүчеләр булалар икән.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин кешеләрне дә, җеннәрне дә Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен яраттым».**

«Зарият / Таратучы», 51:56

Намаз – гыйбадәтнең иң олысы. Адәм баласы яратылганнан соң бары тик сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәригатендә генә (гыйбадәт кылу гыйлемнәре белән бергә) көненә биш тапкыр намаз уку вазифасы йөкләтелгән. Һәм бу үзен мөэмин-мөселман дип йөргән кеше өчен, Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкер кылу өчен, Аның рәхмәте белән йөкләнгән хөрмәтле вазифа булып тора. Иман китергәннән соң намаз – гыйбадәтләрнең башы һәм иң изгесе. Намазның әҗер-саваплары, файдалары санап бетергесез. Шуларның берсе турында пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намаз – мөэминнәрнең мигъраҗы», – дип әйткән.

Мигъраҗ – Пәйгамбәребезнең Аллаһы Тәгалә хозурына чыгуы. Без намаз укыганда Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә каршына басып, Аның колы икәнлегебезне таныйбыз, дәлиллибез.

Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм намаз турында мондый хәдис-шәриф әйтеп калдырган: «Намаз – мөэминнең нуры ул. Мөселманның өйдә кылган намазы өен нурландырыр».

Тагын бер хәдистә болай дип әйтелә: «Өйләрегезне намаз кылып, Коръән укып нурландырыгыз». Ягъни, аңлатма кылып әйткәндә: «Фарыз намазларны мәчеттә укып, нәфел намазларын өегездә укып, өйләрегезне нурландырыгыз», – ди. Елына бер тапкыр азан әйтеп, йә булмаса берәр бабай чакырып, аннан азан әйттереп кенә өйләрне нурландырырга бик авыр була, ә намаз укып ул һәрвакыт нурлана.

Икенче бер хәдистә: «Аллаһының Үзен күргән кебек гыйбадәт кыл», – дип әйтелә, ягъни, Раббыңа гыйбадәт кылганда, намаз укыганда, Аны күргән кебек ихлас күңел белән, күңел рәхәтлеген тоеп, барлык чит бул-

ган нәрсәләрне онытып, өстеңә йөкләнгән гыйбәдәт кылу, коллык бурычларын җиренә җиткереп үтәүне аңлата. Шул вакытта намазның тәмен белергә була. Күзләребез белән Раббыбызны күрмәсәк тә, ул безне күрә, барлык уй-фикерләребезне дә белеп тора. Без бит Аллаһы Тәгаләнең йорты булган мәчеткә гыйбадәт кылырга килгәндә Аллаһы Тәгаләнең:

وَاعْبُدْ رَبَّكَ حَتَّىٰ يَأْتِيَكَ الْيَقِينُ ﴿٩٩﴾

**«Үзеңә үлем килгәнчегә кадәр Раббыңа гыйбадәт кыл»,**

«Хиҗер», 15:99

– дигән әмерен истә тотып киләбез. Ошбу әмерне мәчеткә килгәндә генә түгел, башка вакытларда да онытмасак иде.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гамәлләрегезнең иң фазыйләтлесе, эшләрегезнең иң хәерлесе – намаз уку», – дип әйткән.

Икенче хәдистә: «Намаз – бөтен изгелекләрнең ачкычы. Намаз – җәннәтнең ачкычы», – дип әйтелә. Ошбу хәдисләрдә иман китергәннән соң иң хәерле эш – намаз уку диелә. Иман-ышану беренче дәрәҗәдә, ә намаз икенче дәрәҗәдә, чөнки башта Аллаһы Тәгаләгә иман китермичә, (Барлыгына, Берлегенә) ышанмыйча намаз укып булмый бит.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَاعْبُدْنِي وَأَقِمِ الصَّلَاةَ لِذِكْرِي ﴿١٤﴾

**«... Миңа гына гыйбадәт кыл вә Мине зикер итәр өчен намаз укы».**

«Та Һа», 20:14

Кеше кемне яки нәрсәне яратса, шуны хәтерендә даими сакларга, һәрвакыт аны аңларга, аның турында күбрәк белергә тырыша. Кешенең фикерендә, уенда нәрсә булса, аның зикере дә, сүзе дә шуның турын-

да гына була. Аллаһы Тәгаләне барча мәхлүкълардан да күбрәк яратучы Раббысы турында күбрәк уйлап, Аның әмерләрен үтәргә тырышып, намазын вакытында укый да, ин шә Аллаһ, җәннәтле булачак. Ә инде акчаны, малны күбрәк яратучы – шул малга, акчага «табына» башлый. (Аллаһы Тәгалә аның йөрәген Үзенә гыйбадәт кылудан азат иттерә). Ул кеше: «Миңа күбрәк булсын; башкалардан зуррак дәрәҗәле урында булыйм», – дип тырышып, ахыр чиктә үзенең нәфесе артыннан иярә. Кайбер кешеләр шәйтанга гыйбәдәт кыла башлый, һәм шуның белән ширек кылганын сизми дә кала. Кыямәт көнендә, Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын, җәһәннәмгә керүе бар.

Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «(Намаз укыган кеше) аның өчен фәрештәләрнең ничек итеп дога кылганын күрсә, ул кеше намаздан һич аерыла алмас иде», – дип әйткән. Кеше өеннән мәчеткә намаз укырга дип чыгып киткәннән алып, өйгә кайтып кергәнгә кадәр барлык вакыты намазда булу, дип санала. Фәрештәләр шул вакыт аралыгында аның өчен догада булалар.

Вәгазь башындагы аятькә яңадан әйләнеп кайтсак, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

مُنِيبِينَ إِلَيْهِ وَاتَّقُوهُ وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَلَا تَكُونُوا مِنَ الْمُشْرِكِينَ ﴿٣١﴾

**«Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, һәрвакыт Аңа итагатьтә булыгыз һәм Аңа гөнаһлы булудан сакланыгыз, билгеләнгән намазларыгызны вакытында укыгыз, һәм һичнәрсәне Аллаһыга тиң кылмагыз, мөшрикләрдән булмагыз».**

«Рум», 30:31

Мөселман кардәшләрем! Ошбу аятьнең һәрбер сүзен калебебез аша үткәреп, Раббыбызның безгә әйткәннәренә төшенергә тырышсак иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ ﴿١﴾ الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ ﴿٢﴾

**«Дөреслектә, хак мөэминнәр газаптан котылып, мәңгелек сәгадәткә (бәхеткә, уңышка) ирештеләр. Алар намазларын хошугъ (түбәнчелек), әдәп белән, Аллаһыдан курку белән укыйлар».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:1-2

Риваятьләргә караганда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, намаз укыганда, башта күзләрен күк тарафына юнәлтеп укыган. Ошбу аять иңгәннән соң, намазда сәҗдә урынына карап укый башлаган. Гомумән, намаз укучы карашын намаз урынына юнәлтә. Намаздагы хошугълык (түбәнчелек, әдәп) – шул намаз укучы кешенең уң һәм сул якларында кем торганын да белмәүгә кайтып кала, дисәк тә була. Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә уңышка ирешүнең төп шарты итеп Үзе каршында түбәнчелекле булуны билгеләгән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Фарыз намазы вакыты җиткәч тиешенчә тәһарәт алучы, ә намаз вакытында тиешле түбәнчелек күрсәтүче һәм барлык сәҗдәләрне тиешенчә үтәүче һәрбер мөселманга, зур гөнаһлар кылмаган булса, аның бу намазы белән, һичшиксез, аңа кадәр кылган гөнаһлары гафу ителәчәк. Бу һәрвакытта да шулай калачак», – дип әйткән. Шулай ук бервакыт пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Гамәлләрнең кайсы иң яхшы санала?» – дип сораганнар. Ул: «Намазны үз вакытында уку», – дип әйткән.

Гобәдә бине Сәмит Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен ишеткән: «Аллаһы Тәгалә биш вакыт намазны фарыз кылган. Намазлар алдыннан тиешенчә итеп тәһарәт алучы һәм рөкүгъ, сәҗдәләрен камил рәвештә үтәп, тиешле тыйнаклык күрсәтеп укучы кеше Аллаһының андый кешеләрне гафу итәм дигән вәгъдәсенә өметләнергә

хохуклы. Ә моны эшләмәүчеләргә Аллаһының вәгъдәсе кагылмый. Әгәр дә теләсә – Ул бу кешене гафу итәчәк, теләсә – газаплаячак».

Намазын вакытында укучы кеше – Раббысы Аллаһыга буйсынган хәлдә, гөнаһлардан сакланып, Аллаһыга ширек кылудан тыелып яшәүче була. Шуңа да гаилә башлыгы булган ир кеше намазларны үзе укырга һәм динне гаиләсенә дә өйрәтергә бурычлы ителгән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намаз минем өчен шатлык һәм күз нуры», – дигән.

Намаз укучы кеше Раббысы белән бәйләнешкә кергәнгә күрә, тәкъва мөселман өчен намаз күз нуры гына түгел, тынычлык табу чарасы да булып тора. Хәдис-шәрифтә: «Мөэмин белән имансызларны аера торган нәрсә – ул намаз», – дип әйтелә. Әмма безнең башка кешегә: «Син – имансыз, чөнки син намаз укымыйсың», – дип әйтергә хакыбыз юк (кешенең күңелендә нәрсә икәнен белеп булмый). Кешегә исә Аллаһы Тәгаләдән үзенә һидаять бирүен, намаз укучылар рәтеннән кылуны сорарга кирәк.

Раббым Аллаһы, өстебезгә йөкләгән намазларны үземә, гаиләмә, нәселемә һәм дә мөэмин-мөселман кардәшләремә кимчелек, хатасыз үтәп, Үзеңнең ризалыгыңа ирешергә, рәхмәтең белән җәннәтеңә керергә насыйп әйләсәң иде. Әмин!

*Равил хәзрәт Нуруллин,*

*Яр Чаллы шәһәренең «Туфан» мәчете имам-хатыйбы,*

*Аксакаллар шурасы рәисе*

*25 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Бүгенге заман мөселманы

Әлхәмдү лилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъд: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Һәм дә салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде.

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ, хөрмәтле дин кардәшләрем!

Бүген җәмгыятьтә «Замана мөселманы нинди булырга тиеш?» дигән сорау еш ишетелә. Чынлыкта, замана үзгәрми. Адәм баласының Аллаһы Тәгаләгә мөнәсәбәте, Ул биргән нигъмәтләргә шөкер дәрәҗәсе, бер-берсенә карата мөгамәләсе үзгәреш кичерә. Ә мөселман ул, һәр заманда мөселман. «Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүлуллаһ» – «Аллаһыдан башка Илаһ юк һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм – Аның Илчесе», – дип әйтте һәм шул сүзләргә калебе белән инанды икән – ул мөселман. Нинди мөселман? Ә монысы инде үзебездән тора. Намаз укыйбызмы, ураза тотабызмы, мәчеткә йөрибезме, мохтаҗларга ярдәм итәбезме, гаиләбезне тәэмин итәбезме, дус-туганнар, күршеләр белән күркәм мөгамәлә корабызмы, әллә юкмы?

Һәр заманда, һәр мөселман өчен иң күркәм мисал – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Бүгенге заман мөселманы үзе дә Раббыбызның сөекле бәндәсе булырга тели икән, Аллаһы Тәгаләнең Илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кебек булырга омтылырга тиеш. Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдис-шәрифләрендә болай дип әйтә: «Мөселман кош сыман». Бер канаты –

шушы фани дөнья булса, икенчесе – Ахирәт. Икесен дә тигез дәрәҗәдә кайгыртырга кирәк. Дөнья дип мәңгелек тормышыбызны онытабыз икән, тиешле җәзасын алачакбыз. Ахирәт дип көнкүрешебезне ташлыйбыз, эшләмибез, гаиләбезне тәэмин итмибез икән – шулай ук гөнаһ. Динебездә монахлык, каядыр урманга китеп, җәмгыятьтән аерылып, бары тик Ахирәт дип кенә яшәү юк. Бу гөнаһ санала. Элек тә шулай булган, бүген дә шулай. Ин шә Аллаһ, Ахырзаманга чаклы шулай булачак.

Икенче бер хәдисендә Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип искәртә: «Мөселман шулдыр ки, кемнең кулыннан һәм теленнән башкалар имин булыр», ягъни мөселман көч белән дә, сүз белән дә башкаларга зыян салмас, аннан кешеләр курыкмас. Киресенчә: «Бу кеше – мөселман, аңа ышанырга, аның белән эш алып барырга, авыр чакта аңа таянырга була», – дип әйтсәләр – хак мөселманлык шул булыр.

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз гомере, үз эшләре, үз сүзләре белән нинди булырга һәм нинди булмаска, нәрсә эшләргә, ә нәрсә эшләмәскә, нәрсә ашарга яки ашамаска, гаилә, туганнар, дуслар, күршеләр белән ничек мөгамәлә корырга – барысын да бәйнәбәйнә аңлаткан, күрсәткән.

Әйе, еллар үтә, башка гасырлар, башка вакытлар килә. Ләкин кешенең әдәп-әхлак кыйммәтләре шул ук кала. Аллаһы Тәгалә ир-атка гаиләсен тәэмин итүне боерды. Ир-атны гаилә башлыгы итеп билгеләде. Бүген дөнья дәрәҗәсендә ир белән хатын тигезлеге турында күпме генә сөйләсәләр дә, бу хак тигезлек түгел. Бу – бүгенге заман хатын-кызын, тигезлек белән алдап, коллыкка кертү. Кыйммәтләр шул ук. Безнең аларны кабул итүебез генә башка. Бүгенге заман мөселманына да никах фарыз. Ир белән хатынның башка рәвешле мөнәсәбәтләре юк һәм була да алмый. Мөселман, кайсы гына чорда, кайда гына яшәсә дә, мөселман булып калырга тиеш. Һәм һәрвакыт нәрсәдер кылыр алдыннан Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искә алырга кирәк. Каршыбызда берәр

дилемма чыкты икән, уйлап карыйк: Пәйгамбәребез галәйһиссәлам мондый очракта ни эшләр иде икән? Һәм шул юлдан барыйк. Ин шә Аллаһ, шунда хәерлесе булыр.

Аллаһы Тәгалә кодси хәдистә: «Заманны, вакытны сүкмәгез, чөнки бу замана, вакыт – Мин Үзем», – дип әйтә. Без үз хаталарыбызны вакытка сылтап калдырырга яратабыз. Бабайларыбызны искә төшерик. Нинди агрессив атеистлык вакытында да диннәрен калдырмаганнар. Көчләп диннән ваз кичтергән чакларында да Ислам диненә тугры калганнар. Әлхәмдүлилләһ, хәзер безнең җирлектә мөселманнар өчен бик яхшы вакыт, чөнки мәчет салырга рөхсәт бар. Эштәме, вокзал-аэропорттамы, юлдамы – намаз укый алабыз. Кызларыбыз, хатыннарыбыз яулык кия. Әбибабайларыбыз бу хакта хыяллана да алмый иде. Вакытны сүгү исә бары тик аклану өчен генә. Барысы да шулай эшли, минем кайсы җирем ким, дип уйлау – шәйтаннан. Моннан сакланыйк.

Бүгенге заман мөселманы шушы тискәре күренешләргә ияргә түгел, үзе матур тенденцияләр булдырырга тиеш. Һәр өлкәдә үрнәк булыйк. Гаиләдәме, эштәме, күршеләр белән мөнәсәбәттәме, машинадамы, урам буйлап җәяүләп барабызмы, җәмәгать транспортындамы – мөселман һәрвакыт Аллаһы Тәгалә күзәтүе астында булуын онытмаска тиеш. Йосыф галәйһиссәлам мисалын искә төшерик әле. Зөләйха – вәзир хатыны, гаҗәеп гүзәл хатын-кыз – аның белән зина кылырга тели. Коръәни Кәримдә дә бу вакыйга тасвирлана:

وَرَاوَدَتْهُ الَّتِي هُوَ فِي بَيْتِهَا عَن نَّفْسِهِ وَغَلَّقَتِ الْأَبْوَابَ وَقَالَتْ هَيْتَ لَكَ ۚ
قَالَ مَعَاذَ اللَّهِ ۖ إِنَّهُ رَبِّي أَحْسَنَ مَثْوَايَ ۖ إِنَّهُ لَا يُفْلِحُ الظَّالِمُونَ ﴿٢٣﴾

**«Вәзир хатыны Зөләйха үз өендә Йосыфтан ялынып вә ялварып нәфесе теләгәнне үтәвен таләп итте вә барча ишекләрне бикләде һәм: «Ий, Йосыф, кил минем яныма, мине мәхрүм итмә», – диде. Йосыф әйтте: «Бу эштән Аллаһыга сыенамын,**

**тәхкыйк, тәрбиячем Газиз миңа хөрмәт күрсәтте, торачак җиремне күркәм кылды, инде мин аңар ничек хыянәт итим! Бу эшне кылсам, залимнәрдән булырмын бит, әлбәттә, залимнәр Аллаһы газабыннан котыла алмаслар».**

«Йосыф», 12:23

Йосыф галәйһиссәлам, Раббысыннан куркып, зинага бармый, гәрчә, кул сузымында гына дөньяның иң гүзәл хатын-кызы булса да. Бүгенге заман мөселманы, хәтта кечкенә булып тоелган мәсьәләләрдә дә, нәкъ шулай рөхсәт ителмәгәннән тыелырга тиеш. Урамнан барганда юлга чүп ташлап калдырабыз икән, Раббыбыз шуны да күрә. Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтне пычраттык. «Чисталык – иманның яртысы», – дип әйтелә хәдистә. Өстәвенә, динебезгә тискәре мөнәсәбәт тудырдык. Мәчеткә йөрүебезне, намазда булуыбызны берәү дә белми, дип уйламыйк. Бөтен кеше белә һәм безгә карап ислам диненә бәя бирә. Безнең заман өчен бу аеруча актуаль. Һәр кешенең кулында фотоаппаратлы телефон – төшереп тә алды, бөтен дөньяга таратты да. Бервакыт урамнан барганда чүп ташлап калдырдык ди, күршеләр белән кычкырыштык, өебездә гел тавышгауга икән – башкалар шуны күреп: «Бу мөселманнар пычрак, гаугалы, әдәпсез», – дип фикер йөртсәләр, үзебез үк динебезне пычраткан булып чыгабыз.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Әлхәмдүлилләһ, бүген мөмкинлекләр зур. Кибеттә җаның теләгән әйбер бар. Шул ук кием мәсьәләсендә дә. Бүгенге мөселман ничек киенергә тиеш дигәндә, берничә кагыйдәне истә тотарга кирәк. Киемнең төп максаты – гаурәтне каплау. Хатын-кызларыбыз яулыктан, озын итәктән, озын җиңле киемнән йөрергә тиеш. Аллаһыга шөкер, хәтта 20 ел элек кенә дә шәригатьчә, матур-пөхтә итеп тә киенеп йөрү өчен бүгенге мөмкинлекләр юк иде. Шуны да онытмыйк: ир-атларның да гаурәте бар. Мөселман тездән югары шорты киеп йөри алмый. Сәҗдәгә киткәндә бил ачыла торган джинсы чалбар киеп йөрү дә

безне бизәми. Алай гына да түгел, намазыбызны боза. Шул рәвешле, бергә гыйбадәт кылган кардәшләребезгә карата да әдәпсезлек күрсәтәбез.

Замана мөселманының киенү әдәбе дигәндә тагын бер мөһим мәсьәлә – киемнең пакьлеге. Кайвакыт карыйсың – бөтен җире шәригатьчә бик күркәм, әмма пычранып беткән. Шул кием белән Аллаһы Тәгалә каршына басабыз, шул ук киемнән кеше арасында йөрибез. Әнә шул пычрак кием ислам байрагы булмасын. Һәм дә кием мәсьәләсен йомгаклап, киенү рәвеше шул җирлеккә туры килергә тиеш. Илебездә генә дә төрле климатлы урыннар бар. Бик эссе җирлекләр бар. Бик салкын урыннар да җитәрлек. Ләкин, ничек кенә киенсәк тә, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисен онытмыйк: «Әгәр дә кем ниндидер кавемгә охшаган икән, ягъни тышкы кыяфәте белән, ул алардан булачак». Егетләр шул ук кием мәсьәләсендә дә мөрәҗәгать итәләр. Күлмәк, костюм кияргә ярыймы, дип сорыйлар. Әйе, ярый, аның гөнаһы юк. Шул ук гаурәт җирләре ачылмасын. Һәр урынның үз кием. Төзелешкә костюм-чалбар киеп бармыйбыз бит. Һәр кеше белән сөйләшкәндә аның белән билгеле бер дәрәҗәдә сөйләшергә кирәк булган сыман, киемне дә урынлы кию кирәк.

Бүген без техник үсеш заманында яшибез. Көн саен берәр төрле казаныш уйлап табалар. Сорау туа: алар бит Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында булмаган, мөселманнарга шулардан файдаланырга ярыймы? Файдаланыйк, җәмәгать. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бит бик прогрессив иде. Һәм аның заманында ниндди прогрессив әйбер булса, ул шуны кулланылышка кертә иде. Мәсәлән, хаҗга дөя белән барды, хәтта шул дөядә Гарәфәт тавына да менде. Ә ул заман өчен дөя – бүгенге иң яхшы транспорт чарасына тиңләрлек.

Техник яңалыкларга килгәндә, иң мөһиме – без аны ничек файдаланыбыз. Һәрбер исраф – харам. Сериал карап, телефоннан мәгънәсез видеолар карап вакытыбызны исраф итәбез икән – монысы тыелган. Әмма телефоннан кирәкле эш өчен файдалану рөхсәт ителә. Телевизордан фай-

далы мәгълүмат алу рөхсәт. Мөселманнар һәрвакыт прогрессив булган. Күпме фәнгә нигез салучылар да – мөселманнар. Алар үз вакытының алдынгы карашлы кешеләре булган. Бүген без замана казанышларын читкә этәрәбез икән, артка тәгәрибез. Әйе, диннең нигезе бар. Коръән һәм сөннәт кайсы гына заманда да бер үк булды һәм булачак. Ләкин техник үсештәге, тыйб гыйлемендәге ачышлардан файдаланмау дөрес булмас. Сәламәтлегебезне кайгыртып тору кирәк. Бүген нинди генә катлаулы операцияләр ясалмый, алар да бит замана казанышы. Һәм алар бүген мөселманнарның сәламәтлеген саклауга ярдәм итә. Тәнебез, аның сәламәтлеген саклау – һәр мөселманга әманәт.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Көчле мөселман Аллаһы Тәгалә каршында көчсез мөселманга караганда яхшырак», – дип әйтә. Димәк, бүгенге заман мөселманы спорт белән дә шөгыльләнә, төрле файдалы очрашуларга, мәдәни чараларга да йөри ала.

Алдынгы карашлы, динебезне матур итеп күрсәтүче, акыллы һәм, әлбәттә, тәкъва мөселманнардан булуыбызны Раббыбыз һәрберебезгә дә насыйп итсен.

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*1 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Хиҗаб: өстенлеге һәм әһәмиятлелеге

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәәтүһ!

Бүгенге вәгазебез, ин шә Аллаһ, хиҗаб, аның өстенлеге һәм әһәмиятлеге турында булыр.

«Хиҗаб» гарәп теленнән «бөркәнчек», «бөркәнү», «каплау» дип тәрҗемә ителә. Шәригатьтә исә «хиҗаб» – хатын-кызның билгеле бер таләпләргә һәм шартларга туры китереп, тәнен каплавы.

Әйткәнебезчә, тәнне каплаган кием «хиҗаб» булып саналсын өчен, Ислам динендәге кайбер таләпләрне сакларга кирәк. Тәннең кайбер өлешләрен генә каплаган гадәти кием хиҗаб булып саналмый. Алга таба без хиҗабның өстенлеге, аңа карата булган таләпләр һәм хатын-кызга тәннең кайсы өлешләрен капларга тиешлеге турында сөйләрбез.

Мөхтәрәм җәмәгать, иң элек хиҗабның өстенлеген карап үтик. Беренчедән, хиҗаб – Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Илчесенә буйсынуны белдерә.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا كَانَ لِمُؤْمِنٍ وَلَا مُؤْمِنَةٍ إِذَا قَضَى اللَّهُ وَرَسُولُهُ أَمْرًا أَن يَكُونَ لَهُمُ الْخِيَرَةُ مِنْ أَمْرِهِمْ ۗ وَمَن يَعْصِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ ضَلَّ ضَلَالًا مُّبِينًا ﴿٣٦﴾

**«Аллаһы вә Аның Расүле бер нәрсә хакында хөкем итсәләр, берниндиг мөэмин ир вә мөэминә хатын бу хөкемне читкә куеп, үзләре теләгәнне ихтыяр итәргә лаек булмас, бәлки Аллаһы вә Расүлнең әмерләрен тоту фарыз буладыр. Әгәр берәү Аллаһы вә Расүлнең әмерен тотмыйча, нәфесе теләгәнчә, яки динсез кешеләргә ияреп эш кылса, тәхкыйк, ул кеше ачыктан-ачык адашты».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:36

Аллаһы Тәгалә хатын-кызга бит һәм беләзеккә кадәр кулларыннан кала тәннең бөтен өлешләрен дә капларга әмер кыла. Коръәндә болай дип әйтелә:

وَقُل لِّلْمُؤْمِنَاتِ يَغْضُضْنَ مِنْ أَبْصَارِهِنَّ وَيَحْفَظْنَ فُرُوجَهُنَّ وَلَا يُبْدِينَ زِينَتَهُنَّ إِلَّا مَا ظَهَرَ مِنْهَا ۖ

**«Мөэминә хатыннарга әйт: карарга ярамаган нәрсәдән күзләрен йомсыннар вә фәҗерләрен зинадан сакласыннар һәм кул белән йөзләреннән башка булган зиннәт урыннарын ачмасыннар ...».**

«Нур», 24:31

Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Хатын-кыз (аның тәне) тулысынча гаурәт булып тора (чит ирләргә мөнәсәбәтле)», – дип әйткән (Тирмизи).

Икенчедән, хиҗаб гыйффәтлекне күрсәтә, хатын-кызның намусын саклый, ягъни хиҗаб хатын-кызны начар ниятле карашлардан саклап,

мөслимәнең тыйнаклыгын күрсәтә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّبِيُّ قُل لِّأَزْوَاجِكَ وَبَنَاتِكَ وَنِسَاءِ الْمُؤْمِنِينَ يُدْنِينَ عَلَيْهِنَّ مِن جَلَابِيبِهِنَّ ۚ ذَٰلِكَ أَدْنَىٰ أَن يُعْرَفْنَ فَلَا يُؤْذَيْنَ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٥٩﴾

**«Ий, пәйгамбәр галәйһиссәлам, үз хатыннарыңа, вә кызларыңа һәм башка мөэминә хатыннарга: «Бер эш белән урамга чыксалар, бөркәнчекләрен башларына салсыннар, ягъни барча әгъзаларыгызны каплый торган зур әйбер белән төренеп чыгыгыз», – дип әйт. Шулай төренеп чыгулары аларның хөр вә мөэминә хатын икәнлекләрен белергә якынрак буладыр. Итагать итүче мөэминә хатыннарны Аллаһы ярлыкаучы вә аларга рәхмәт итүче булды».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:59

Өченчедән, хиҗаб – ул чисталык билгесе. Хиҗаб кию күңелне яман һәм гөнаһлы уйлардан чистарта. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَإِذَا سَأَلْتُمُوهُنَّ مَتَاعًا فَاسْأَلُوهُنَّ مِن وَرَاءِ حِجَابٍ ۚ ذَٰلِكُمْ أَطْهَرُ لِقُلُوبِكُمْ وَقُلُوبِهِنَّ ۚ

**«...Әгәр пәйгамбәр хатыннарыннан берәр нәрсә сорасагыз, пәрдә аркылы сорагыз, әнә шулай соравыгыз сезнең күңелләрегезгә дә, аларның күңелләренә дә пакьрәктер...».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:53

Шул ук сүрәнең икенче бер аятендә болай дип әйтелә:

يَا نِسَاءَ النَّبِيِّ لَسْتُنَّ كَأَحَدٍ مِّنَ النِّسَاءِ ۚ إِنِ اتَّقَيْتُنَّ فَلَا تَخْضَعْنَ بِالْقَوْلِ فَيَطْمَعَ الَّذِي فِي قَلْبِهِ مَرَضٌ وَقُلْنَ قَوْلًا مَّعْرُوفًا ﴿٣٢﴾

**«...ят ирләргә җавап биргәндә тавышларыгызны нечкәртеп, йомшак сөйләмәгез, чөнки нечкә тавыш белән йомшак сөйләсәгез, күңелләрендә шәһвәт яки яманлык чире булган ирләр сездән өметләнерләр, вә аларга тавышыгызны нечкәртмичә яхшы сүз әйтегез».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:32

Хөрмәтле мөселманнар, игътибар итегез! Әлеге аятьләрдә Пәйгамбәр галәйһиссәламнең хатыннарына мөрәҗәгать ителсә дә, барлык мөслимәләр дә моннан үрнәк алырга һәм шул рәвешле гамәл кылырга тиешләр.

Дүртенчедән, хиҗаб – тәкъвалык билгесе.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

يَا بَنِي آدَمَ قَدْ أَنزَلْنَا عَلَيْكُمْ لِبَاسًا يُوَارِي سَوْآتِكُمْ وَرِيشًا ۖ وَلِبَاسُ التَّقْوَىٰ ذَٰلِكَ خَيْرٌ ۚ ﴿٢٦﴾

**«Ий Адәм балалары! Без сезгә гаурәтләрегезне каплар өчен һәм матурлык буларак киемнәр яраттык, әмма тәкъвалык киеме сезнең өчен хәерлерәктер...».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:26

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер хәдисендә: «Хатынны дүрт сыйфатына карап сайлыйлар: байлыгына, нәселенә, чибәрлегенә һәм тәкъвалыгына. Тәкъва булганын сайлагыз, юкса кыен хәлдә калырсыз», – дип киңәш бирә[1].

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Күргәнебезчә, хатын-кызның тәнен каплау турындагы шәригать хөкеме ирләргә тормыш иптәшен сайлаганда, аның тышкы гүзәллегенә алданып, хата эшләмәскә ярдәм итә, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең киңәшләрен тыңлап, өстен рухи сыйфатларга ия булган хатынны сайларга өнди.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, инде алга таба хиҗабның шартларын билгеләп үтик. Коръәни Кәримдә һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисләрендә дә хатын-кыз киеменә карата булган таләпләр ачык билгеләнгән. Ул түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

1. Бит һәм беләзеккә кадәр кулларыннан кала тәннең барлык өлешләре дә капланырга тиеш.

2. Кием артык игътибарны җәлеп итәргә тиеш түгел, ягъни купшы булмаска тиеш.

3. Кием үтә күренмәле булмаска тиеш. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Киенгән, ләкин шул ук вакытта ялангач булган, йөргәндә селкенеп йөрүче һәм шулай итеп ирләрне үзләренә каратучы хатын-кызлар җәннәткә кермәячәкләр һәм хәтта хуш исен дә иснәмәячәкләр», – дип әйткән[1].

4. Кием киң булырга тиеш, ягъни тәнгә сыланып торырга тиеш түгел.

5. Киемнән хушбуй исе килергә тиеш түгел.

6. Киемнәре башка дин тотучыларның киемнәренә охшарга тиеш түгел.

7. Кеше әлеге кием белән халык арасында танылуны максат итеп куярга, ягъни киемнең төсе яки ниндидер бизәкләре белән халык арасында аерылып торырга тиеш түгел.

Дин юлыннан барган хатын-кыз хиҗабны зур канәгатьләнү һәм тыныч күңел белән кабул итә, аның кирәкле нәрсә икәненә ышана, чөнки бу – Аллаһы Тәгаләнең әмере: ирләрнең кушуы яки аларның теләгенә буйсыну гына түгел.

---

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Үзенең төп максаты – хатын-кызның гыйффәтен саклау белән беррәттән, хиҗаб тагын бер күркәм вазифа башкара. Ул хатын-кызның гаурәтен каплый. Гаурәтне каплау намаз укуның да бер шарты булып тора. Шуның өчен бу мәсьәләдә бик игътибарлы булырга кирәк. Хатын-кызларның гаурәте нәрсәдән гыйбарәт соң?

1. Мөслимәнең ят ирләр алдында йөзеннән, беләзеккә кадәр кулларыннан һәм аяк табаннарыннан башка бөтен тәне гаурәт була.

2. Бүтән мөселман хатыннар алдында мөслимә тәненең киндектән алып тезләренә кадәр булган өлеше гаурәт булып санала; ә диндә булмаган хатыннар алдында гаурәт нәкъ тә чит ирләр алдында булган кебек.

3. Мәхрәм[1] туганнары алдында хатын-кыз кулларын, чәчен, балтырларын һәм колакларын ачарга мөмкин. Аның тәненең бу өлешләрен мәхрәмгә күрергә тыелмаган.

Кардәшләрем! Без мөслимәнең киеменә булган таләпләрне, шартларны карап үттек. Бу шартлар арасында кара төстәге хиҗаб кияргә кирәклеге турында әйтелми. Ир-атларга рөхсәт ителгән кебек, мөслимәләргә дә кара төстәге кием кияргә ярый, ләкин бу сөннәт түгел. Бу мәсьәләгә карата галимнәребез дә бердәм фикердә торалар. Гайшә радыяллаһу ганһәдән риваять ителә: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм чыкты һәм аның өстендә кара тиредән буйлы чапан (плащ) иде»[2].

«Мин Пәйгамбәр галәйһиссәламгә кара төстәге чапан тектем һәм ул аны киде»[3].

Хатын-кызларга килгәндә, аларга да кара төстәге кием рөхсәт ителә, ләкин бу сөннәт түгел. Өмме Халид радыяллаһу ганһәнең сөйләгәннәре моңа дәлил булып тора:

«Пәйгамбәр галәйһиссәламгә кара күлмәк китергәч, ул: «Бу күлмәкне кемгә кидерәбез? Ничек уйлыйсыз?» – дип сорады. Халык дәшмәде. Шун-

[1] Мәхрәм – никахлашырга харам булган әти-әни, апа, энекәш кебек якын туганнар.

[2] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Әхмәд, Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

нан соң Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Минем яныма Өмме Халидне китерегез!» – дип әйтте. Мине аның янына китерделәр һәм ул миңа үз куллары белән әлеге күлмәкне кидерде»[1].

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хатыннары ак, кызыл, соры һәм кара төстәге киемнәрне дә кигәннәр. Мөслимә үзе яшәгән җирлектә үк күзгә бик ташланмаган һәм аны башкалар арасыннан аерып тормаган төстәге кием кисә, хәерлерәк булыр.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Вәгаземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: хатын-кыз үз-үзен җиңеп, динебез кушканча киенеп, балаларын да шушы үрнәктә тәрбияли икән, бу – зур батырлык, үзенең сафлыгын, дәрәҗәсен, бәясен аңлый һәм саклый белгән кешенең эше. Балаларыбыз да дини тәрбияне кечкенәдән үзенә сеңдереп үссә, җәмгыятебез төзек булыр, бозыклык, гөнаһлардан ерак торыр иде. Ин шә Аллаһ! Йә, Раббыбыз Аллаһы! Безгә исәнлек-саулык, хәерле озын гомер бир һәм үзебездән соң нәселне дәвам итүче, тәкъва, галим балалар калдырырга насыйп ит. Әмин!

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

*8 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Мәчеттә үз-үзеңне тоту әдәпләре

Мәчет – гарәп телендәге мәсҗид, ягъни сәҗдә кылу урыны сүзеннән ясалган. Шулай ук мәчетне икенче төрле «Бәйтуллаһ» – Аллаһы Тәгаләнең йорты дип тә атыйлар. Мәчетнең Аллаһы Тәгаләнең йорты дип аталуы анда кылына торган гыйбадәтләргә бәйле. Мөселман мәчеткә килеп, үзенең дөнья мәшәкатьләрен онытып тора, Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кыла, зикер әйтә, Коръән укый һ.б. Мөселман ир-атлар атнага бер булса да мәчеткә барып, җомга намазы яки башка намазларны үтиләр. Мәчет Аллаһы Тәгалә йорты, анда кергән һәрбер кеше Аллаһының кунагына әйләнә. Берәр кешегә кунакка баргач, үзебезне әдәп-әхлаклы тотарга тырышабыз. Әлбәттә, мәчеттә дә шуңа охшаш үз-үзеңне тоту кагыйдәләре бар.

Мәчеткә еш йөрсәк тә, анда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен барыбыз да белеп тә, үтәп тә бетермибез. Мәчет, иң беренче чиратта, Аллаһы Тәгалә йорты. Шуңа күрә, мәчеткә кергәндә мәчет намазын уку хәерле, чөнки бу Аллаһы Тәгаләне сәламләү булып тора. Мәсҗид намазы – мәчеткә кергәннән соң укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы («тәхиййәтүл мәсҗид» дип атала).

Мәчеттә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре барысы да Пәйгамбәребез галәйһиссәлам хәдисләренә нигезләнә. Әйдәгез, аларны карап үтик:

1.Уң аяктан атлап кереп, сул аяктан чыгу.

Мәчеткә юнәлгәч тә, һәрбер кеше мәчеткә уң аяктан атлап керү турында исенә төшерергә тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мәчеткә уң аяктан атлап керегез», – дип әйткән[1].

---

[1] Имам Хәким хәдисләр җыентыгыннан.

2. Мәчеткә кергәндә дә, чыкканда да дога кылу.

Мәчеткә кергәндә укыла торган дога: «Әгүзү билләәһил-гәзыыйм. Вә би үәҗһиһил-кәриим. Вә сүлтааниһил-кадиим минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһи үәссаләәтү үәссәләәмү галәә расүүлилләһ. Аллааһуммә фтәх лии әбвәбә рахмәтик». Тәрҗемәсе: «Ләгънәт кылынган шәйтан явызлыгыннан Бөек Аллаһыга, Аның изге мәрхәмәтлегенә һәм Аның мәңгелек хакимлегенә сыенам. Аллаһы исеме белән сорыйм (Аллаһы Илчесенә салават вә сәлам булсын): Әй, Раббым, миңа Үзеңнең мәрхәмәтлелек ишегеңне ач!»

Мәчеттән чыкканда укыла торган дога: «Бисмилләәһи үәссаләәтү үәссәләәмү галәә расүүлилләәһ. Аллааһуммә инни әсъәлүкә миң фадлик. Аллааһуммә-гсыймнии минәш-шәйтаанир-раҗииим». Тәрҗемәсе: «Аллаһы исеме белән сорыйм (Аллаһы Илчесенә салават вә сәлам булсын): Әй, Раббым, мин ихлас күңелдән Синнән мәрхәмәтлек сорыйм, ий, Раббым, мине ләгънәт кылынган шәйтаннан сакла».

3. Мәчеттә чисталыкны саклау.

Мәчет эче дә күркәм рәвештә, тирә-ягы да чиста булырга тиеш. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам мәчетләрне чиста тотыгыз, дип әйтте. Шуңа күрә мәчеткә кергәндә аяк киемнәрен дә теләсә кая куймаска кирәк. Гадәттә, алар өчен аерым урын әзерләнгән була. Шулай ук идәнгә чүпләмәскә, мәчеттә өмәләр булганда, аларда катнашырга тырышырга кирәк.

4. Шаулашмаска һәм дөньяви эшләр турында сүз алып бармаска.

Мәчеттә үзегез генә түгеллеген исегездән чыгармагыз, чөнки калганнарның хакларын үтәү – бурыч булып тора. Мәчеттә булган вакытта шаулашмаска тырышырга кирәк. Бигрәк тә әңгәмә турыдан-туры гыйбадәт мәсьәләләренә карамаса, сөйләшү акрын гына алып барылырга тиеш. Мәчеттә кемдер Коръән укый, кемдер намаз вакыты кергәнен көтеп утыра. Кемдер дәрес ала, ә кемдер нәфел намазлары укый. Сөйләшеп

утырып, намаз укучының, Коръән өйрәнүченең игътибарын читкә юнәлдерергә мөмкин.

5. Мәчеттә начар исләр булмаска тиеш.

Начар ис булган бинага фәрештәләр кермәс, дигән хәдисне ишеткәнегез бардыр. Ә мәчет – гыйбадәт урыны, мөселманнарның үзләренә дә гыйбадәт кылганда уңайлы булырга тиеш. Шуңа күрә мәчетне чиста, пөхтә итеп тотарга, анда начар исләр булдырмаска тырышырга кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Суган, яки сарымсак, яки чи суган ашаган кеше мәчеткә якын бармасын. Дөреслектә, ул кешеләргә нинди уңайсызлыклар тудырса, фәрештәләргә дә шундый ук уңайсызлыклар тудыра», – дип әйткән.

Мөмкинлеге булган кешегә мәчеткә госелләнеп килергә, хушбуйлар кулланырга киңәш ителә. Җомгага госел алып килү сөннәт булып тора.

6. Мәчеткә кыска җиңле кием киеп бармау.

Мәчеткә барганда кием чиста булырга тиеш дип әйттек. Әмма ул шулай ук гаурәтне дә капларлык озын булырга тиеш. Җәй көннәрендә эссе дип, кайбер кеше шорт, майка киеп тә килгәлиләр. Әмма җиңсез кием белән намаз уку, гомумән, мәкруһ санала. Нинди генә озын шорт булмасын, аның сәҗдә вакытында тезләрне ачуы бар. Ә Пәйгамбәребез: «Тезләр – ул гаурәттән», – дип әйткән. Боларга өстәп, спорт киемнәре турында да әйтеп узарга кирәк. Бүгенге көндә спорт киемнәрен тәнгә сыланып тора торган итеп тегәләр. Әмма андый кием белән шулай ук мәчеткә килү киңәш ителми, чөнки алар гәүдә төзелешен күрсәтеп торалар.

7. Намаз укучының алдыннан үтү ярамый.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам намаз укучы алдыннан үтеп китүне тыйды. Әгәр дә берәр кеше мәчеткә кереп, анда намаз укучыны күрсә, аның алдыннан үтмәскә тырышырга кирәк. Шуңа күрә намаз укыр алдыннан, кеше үз алдына сүтрә кую турында кайгыртырга тиеш. Кешенең алдында сүтрә (теләсә нинди бер предмет) булса, аның каршын-

нан үтеп китү рөхсәт ителә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Әгәр намаз укучының алдыннан чыгучы моның нинди зур гөнаһ икәнен белсә, 40 вакыт көтеп торуны хәерлерәк күрер иде», – дигән. Хәдисне тапшыручылар: «Пәйгамбәрнең көнме, аймы, елмы, дип әйткәнен белмим», – дип әйттеләр. Шуңа да галимнәр зур гөнаһ икәнен генә билгеләп үтә. Безнең үзебезгә дә намазны кеше күп йөри торган урында укымаска тырышырга тиеш. Әлбәттә, әгәр намаз укучы кеше үтеп китәргә урын калдырмаган булса, сәҗдә урыныннан алдарак үтеп китәргә була.

8. Җомга намазының хөтбәсе барышында тик утырырга, сөйләшмәскә.

Имам минбәргә менүгә, ә кайбер галимнәр фикере буенча, үзенең бүлмәсеннән яки намаз залында утырып торган урыныннан торуга, җомга намазы вакытында сөйләшүләр тукталырга тиеш. Хәтта имам Пәйгамбәребезгә салаватлар әйткәндә дә, аларны эчтән генә әйтергә кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Әгәр син имам җомга хөтбәсен укыган вакытта янәшәңдәге берәр кешегә: «(Игътибар белән) тыңла», – дип әйтсәң, син ниндидер ярамаган сүз әйткән кебек буласың», – дип әйткән[1].

Әгәр дә хөтбә барышында сәламәтлеккә зыян сала алырлык берәр бөҗәк, агулы үрмәкүч (елан, чаян) күренсә, моның турында кисәтү ясарга мөмкин. Әгәр берәр кеше намазга соңга калып килсә яки хөтбә барышында берәр кеше төчкерсә, аларга җавап кайтарылмый. «Телефоннан язышу сөйләшүгә керми инде ул», – дип, вәгазь барышында телефон кулланучыларны да күрергә мөмкин. Әмма телефон куллану шулай ук ярамый. Гомумән, мәчеткә башка намазларга кергәндә дә, телефонның тавышын сүндереп кую хәерле булачак, чөнки намаз вакытында телефоны шалтырап, кеше үз игътибарын читкә юнәлтә ала.

9. Кеше мәсбүк, ягъни соңга кала икән, ул намазга ашыкмыйча, тыныч халәттә барырга тиеш.

---

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Имам намазны укыганда соңгарак калып килгән кешегә имамга тиз арада оеп, шул урыннан укып китү – вәҗиб. Хәтта имам ахыргы кагъдәдә булса да, аңа оеп калу – саваплы. Имамның әүвәлге рәкәгатенә өлгергән кеше «мөдрик» дип атала. Беренче рәкәгатенә җитешмәгән кеше «мәсбүк» дип атала. Мәсбүк, намаз укучыларның игътибарын читкә юнәлтмәс өчен, намазга ашыкмыйча килеп, калганнарга кушылырга тиеш.

10. Берәр кеше сәфәрдән туган ягына кайтса, аңа иң элек мәчеткә барып, намаз уку хәерле.

Пәйгамбәребез берәр төрле яудан яки сәфәрдән кайткач, иң беренче эш итеп мәчеткә барып намаз укый, аннан соң шунда җыелган кешеләр белән бераз сөйләшә, шуннан соң гына үз өенә кайтып китә торган булган.

11. Мәчеттә игътикяф вакытыннан тыш, йоклау мәкруһ.

Мөселман кешесе Аллаһы йортында мөһим сәбәпләрсез йоклап ятуны мәкруһ икәнен дә исеннән чыгармаска тиеш. Искәрмәле очрак булып кешенең йорты булмавы, сәфәрдә булып, ял итүе һәм Рамазан аенда игътикяфтә булуы тора.

12. Намаз укый торган залда артык тавыш чыгармаска, ашамаска.

Бүгенге көндә мәчетләр зур, иркен. Әмма, шуңа карамастан, сөйләшеп утыручы кешеләрне нәкъ намаз укыла торган залда күрергә мөмкин. Мөмкинлек булганда, башка залга чыгып утыру хәерле гамәл булачак. Ә инде намаз залында Коръән укыган кеше каты тавыш белән укырга тиеш түгел. Анда намаз укучыларга сезнең тавышыгыз комачауламаслык булырга тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Бер-берегез арасында булганда, Коръәнне кычкырып укымагыз. Аллаһы Тәгалә сезнең акрын тавыш белән дә Коръән укуыгызны ишетә», – дип әйткән.

Шулай ук мәчетләрнең күбесендә аерым аш бүлмәләре ясала башлады. Намаз бүлмәсендә ашарга ярамаса да, шул аш бүлмәләренә кереп ашау рөхсәт ителә.

13. Намаз укый торган җирдә сату-алу эшләре алып бармаска.

Мәчет эчендә сәүдә, сату-алу эшләре алып бару катгый тыела. Кайбер мәчетләрдә, бигрәк тә шәһәрдәге зур мәхәлләле мәчетләрдә мондый хәлләрне очратырга мөмкин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мәчет эчендә сәүдә эшләре алып бармагыз, бәхәсләшмәгез һәм шаулашмагыз ...», – дип әйткән[1].

14. Югалткан әйберне эзләп, кычкырып йөрмәскә.

Гыйбадәт кылучыларның игътибарын алмас өчен, югалткан әйберне кычкырып эзләп йөрмәскә кирәк. Намаз вакыты җитсә, аны намаз беткәннән соң эзләү хәерле. Шулай ук мәчетнең имамына килеп, нәрсә югалтканыгызны сөйләп бирә аласыз. Ул аны микрофон аша тыныч кына калганнарга әйтә ала. Тагын бер киңәш бар. Кадерле җәмәгать, әгәр дә берәр кешенең җәмәгатькә берәр әйбер әйтәсе килсә, иң башта ул аны мәчет имамы белән алдан сөйләшеп куярга тиешле. Бу, әлбәттә, күңелсез хәлләр, низаглар килеп чыкмасын өчен шулай эшләнелә.

Мәчеткә йөрүнең файдаларын санап бетергесез. Ул мөселман өммәтен берләштерүгә дә китерә, кешегә Аллаһының кунагы булып торуга мөмкинлек тә бирә, гыйлем алырга юллар ача. Ә фарыз гыйбадәтләр кылуны Пәйгамбәребез болай да мәчеттә башкарырга кушты, чөнки хәдистә мәчеттә укылган намаз өчен әҗер-савабы 27 тапкыр артык дип әйтелә. Шуңа күрә үзебезгә дә, калганнарга да Аллаһының күркәм кунаклары була алыр өчен, анда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен истән чыгармаска кирәк. Үзебезгә уңайлы булсын өчен, калганнарга да комачауламасак иде. Мәчет – Аллаһы Тәгалә йорты дип әйттек. Аның хуҗасы «мин дә, син дә» түгел. Аның хуҗасы – Аллаһы Тәгалә.

*«Хозур» редакциясе*

---

[1] Ибне Мәҗәһ хәдисләр җыентыгыннан.

*15 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Дога – сорау, ялвару

Барча галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә хәмде-сәналәр булса иде. Аның хәбибе, хак расүл Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәлләмгә дә йөрәкләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифәләребез булса иде.

قُلْ مَا يَعْبَأُ بِكُمْ رَبِّي لَوْلَا دُعَاؤُكُمْ ۖ

**«Вә (аларга): «Әгәр Аллаһыга догаларыгыз, сорау-ялваруларыгыз булмаса, Аңа ни өчен кирәксез?» – дип әйт».**

«Фуркан / Аеручы», 25:77

Безнең тормыш – ул безнең догаларыбыз нәтиҗәсе. Дин дәүләттән аерылды, шуңа карап тормышыбыз да динсезлеккә корылса, догалар да бетәчәк. Моннан чыгу юлы фәкать Ислам икәне бүгенге көндә ачык билгеле булса да, халык дингә килергә ашкынып тормый. Бездән булмый, яшебез чыккан, дип әйтүчеләр әлегә балаларын да дингә кертергә ашыкмыйлар шикелле. Халыкның дин турында сөйләшүе дә зарлануга гына кайтып кала: «Нишләп Аллаһы Тәгалә кешеләргә рәхмәтен бирми? Нишләп кайгы-хәсрәттә йөртә, алар турында һич кайгыртмый?» – дип әйтә алар. Әмма Аллаһы Тәгалә безгә бу дөньяда да, Ахирәттә дә яхшы яшәр өчен бер көчле корал биргән. Ул – дога.

Аллаһы Тәгалә дога кылып сорарга куша, чөнки Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, кеше үзенең кол икәнен таный. Әгәр берәр кешенең башкага йомышы төшеп, ул иң элек аңа мөрәҗәгать иткәнче, Раббысына мөрәҗәгать итә икән, ул үзенең дә, башкаларның да фәкать кол гына

булуларын таный була. Тормышында эшен һәрвакыт Раббысына дога кылып башлаган кеше берничек тә Раббысының кушканнарыннан баш тартучы, тыелганнарыннан тыелмаучы булмас.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَإِذَا سَأَلَكَ عِبَادِي عَنِّي فَإِنِّي قَرِيبٌ ۖ أُجِيبُ دَعْوَةَ الدَّاعِ إِذَا دَعَانِ ۖ فَلْيَسْتَجِيبُوا لِي وَلْيُؤْمِنُوا بِي لَعَلَّهُمْ يَرْشُدُونَ ﴿١٨٦﴾

**«Әгәр бер бәндәм Миннән сораса, Мин, әлбәттә, аңа һәрвакыт якынмын, Миннән сораса, сораганын бирермен. Әммә сораучылар Үземә һәм сүземә ныклап ышансыннар һәм Миңа буйсынып, Коръән белән гамәл кылсыннар! Әгәр Мин әйткәнчә эш кылсалар, шаять, туры юлны табарлар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:186

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бу аятьтә «Сорагыз һәм Мин соравыгызны үтим» генә дип калмады, бәлки: «Сораучылар Үземә һәм соравыма ныклап ышансыннар һәм Миңа буйсынып, Коръән белән гамәл кылсыннар», – дип тә әйтте.

Без бит үзебез дә теләсә кемнең соравын канәгатьләндермибез. Күпчелек вакытта, үзебезгә ачык чырай күрсәткән, ярдәм иткән кешегә генә җавап бирәбез һәм шундый кешегә генә ярдәм дә итәбез. Ә безгә каршы килгән, безгә начарлык эшләгән, яисә һәрвакыт безне сүгеп йөргән кешегә ярдәм итәргә ашыкмыйбыз. Өебезне яндырган, җимергән, балаларыбызны, туганнарыбызны, ата-аналарыбызны рәнҗеткән булсалар, без ул кешеләргә ничек карар идек?

Әмма Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең Гафурур-Рахим сыйфаты бар. Ничә еллар динсезлектә торып та, без бүген мәчетләргә җыелып, намаз укыйбыз икән, бөтенебезгә дә шәригатьчә яшәргә мөмкинлекләр тудырылган икән, бу бөек Затның мәрхәмәтлелегенә шаккатасы гына кала.

Дөрес аңларга кирәк, Аллаһы Тәгалә адәм баласының догасына мохтаҗ түгел, бәлки, киресенчә, адәм баласы дога кылуга үзе мохтаҗ. Адәм баласы күпме генә тәкәбберләнеп йөрсә дә, үзенең көчсезлеген аңларга тиеш: ул ашап утырганда, бер чебен аның ризыгыннан бер өлешен алып китә; бер черки аның канын эчә һәм ул шуларга да каршы тора алмый. Ул тырышып йорт сала, көчле җил чыгып йортын җимерә, ул табигать күренешләренә каршы тора алмый. Өстәвенә, ул хәерче, аны бер нәрсә белән дә канәгатьләндереп булмый.

Сабый бала нәрсә дә булса теләсә, сорый, елый, ягъни үзенең көчсезлеген күрсәтә. Кеше дә Раббысы каршында үзенең көчсезлеген таныргa тиеш, ул сорау-үтенүләр белән фәкать Раббысына гына мөрәҗәгать итәргә тиеш. Шуңа күрә дә дога – буйсынуның нигезе булып тора. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَقَالَ رَبُّكُمُ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ ۚ

**«Һәм Раббыгыз: «Миннән сорагыз, Мин сезгә җавап бирермен», – дип әйтте».**

«Мөэмин», 40:60

Әмма адәм баласына бөтен нәрсәне дә сорау рөхсәт ителми, чөнки белеме аз, иманы зәгыйфь булу сәбәпле, кеше үзенә зыянлы әйбер дә сорарга мөмкин.

Әнәс радыяллаһу ганһедән риваять кылына, ул болай дип әйтә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вәгазь сөйләде, андый вәгазьне минем моңарчы ишеткәнем булмады. Ул: «Әгәр сез мин белгәнне белсәгез, аз көләр һәм күп елар идегез», – дип әйтте. Шуннан соң Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә түбәндәге аятьне иңдерде:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لاَ تَسْأَلُوا عَنْ أَشْيَاءَ إِنْ تُبْدَ لَكُمْ تَسُؤْكُمْ

**«Ий мөэминнәр! Тиешсез сораулар бирмәгез, әгәр соравыгызга җавап бирелсә, ул җавап сезне кайгыга салыр ...»[1].**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:101

Кеше үз әҗәленең тизрәк килүен теләп дога кылырга тиеш түгел. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сезнең берегез дә үзенең үлемен, ягъни тизрәк үлүен теләмәсен, чөнки сез яхшы кеше булсагыз, сезгә яхшылыгыгызны арттырырга мөмкинлекләрегез тагын да күбрәк булачак; әгәр дә сез начар кеше булсагыз, начар үткәнегезне төзәтергә мөмкинлегегез булачак», – дип әйткән. [2]

Дога – ул гыйбадәт. Аның җимеше Ахирәттә булачак. Аллаһы Тәгалә безгә сынау бирә һәм вакыт бирә. Без шушы вакытта дога кылып калырга тиешбез. Мәсәлән, корылык белән бәйле булган дога, ул фәкать ниндидер мөрәҗәгать, гыйбадәт. Ә яңгыр яумый торган вакыт – ул гыйбадәт өчен вакыт. Бүген яңгыр яудырам диючеләр бар, шуларга ышанучылар бар. Кеше Кыямәт көнне кемгә мөрәҗәгать итүе өчен җавап бирәчәк. Кулга байлык керсә дә, шулай ук вакытлыча гына керә. Вакытында шөкер итеп, тиешле зәкятен чыгарып, садакасын биреп, хәерле, бәрәкәтле байлык булуын сорап дога кылып калырга кирәк. Бәла-каза белән дә шулай ук.

Аллаһы Тәгалә байлыкны да, мохтаҗлыкны да, шатлыкны да, бәла-казаны да вакытлыча бирә. Адәм баласы ни өчендер байлык, бәхет-шатлык килгәндә Аллаһы Тәгаләне исенә төшерми, бәлки кайгы-хәсрәт, бәла-каза килгәндә генә исенә төшерә. Ә бит адәм баласы шуларның кайсы аның өчен хәерлерәк икәнен белми. Шуңа күрә ул һәрвакыт догада булырга тиеш.

Нинди дога кылырга соң? Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең иң күп кылган догасы булып Коръәни Кәримнең түбәндәге аяте тора:

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан, 4261.

2 Имам Әхмәд Мөснәде, 8307.

رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الْآخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ ﴿٢٠١﴾

**«Әй Раббыбыз! Безгә дөньяда да, Ахирәттә дә изге нигъмәтләр бир һәм безне җәһәннәм газабыннан сакла».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:201

Вәгаземне Имам Бохари хәдисләр җыентыгында китерелгән бер дога белән тәмамлыйсым килә. Шушы доганы берөзлексез кабатласак, ин шә Аллаһ, изге теләкләребезгә ирешербез.

اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ الْكَسَلِ وَالْهَرَمِ وَالْمَأْثَمِ وَالْمَغْرَمِ وَمِنْ فِتْنَةِ الْقَبْرِ وَعَذَابِ الْقَبْرِ وَمِنْ فِتْنَةِ النَّارِ وَعَذَابِ النَّارِ وَمِنْ شَرِّ فِتْنَةِ الْغِنَى وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْفَقْرِ وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْمَسِيحِ الدَّجَّالِ

اللَّهُمَّ اغْسِلْ عَنِّي خَطَايَايَ بِمَاءِ الثَّلْجِ وَالْبَرَدِ وَنَقِّ قَلْبِي مِنْ الْخَطَايَا كَمَا نَقَّيْتَ الثَّوْبَ الْأَبْيَضَ مِنْ الدَّنَسِ وَبَاعِدْ بَيْنِي وَبَيْنَ خَطَايَايَ كَمَا بَاعَدْتَ بَيْنَ الْمَشْرِقِ وَالْمَغْرِبِ

**«Йә, Раббым! Сиңа ялкаулык һәм картлык зәгыйфьлегеннән, бөтен төрле гөнаһлардан, кабер сынавыннан һәм кабер газабыннан, Тәмугъ сынавыннан һәм Тәмугъ газабыннан, байлыкка алданудан, фәкыйрьлек фетнәсеннән һәм шулай ук Мәсих Әд-Дәҗҗәл явызлыгыннан сыенамын!»**

**«Йә, Раббым! Ак киемне пычраклардан арындырган кебек, Син дә минем гөнаһларымны кар һәм боз сулары белән юып төшер, калебемне чистарт. Көнчыгыш белән көнбатыш арала-**

**рын ерак иткән кебек, минем белән гөнаһларым арасын да шулай ерагайт»[1].**

*Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев,*

*Яр Чаллы шәһәренең «Ак мәчет» мәдрәсәсе директоры*

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан, 6368.

*22 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Ир-ат вазифалары

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِيَ لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ۚ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿٩﴾

> **«Ий, мөэминнәр, әгәр җомга көнне җомга намазына азан әйтелсә, эшләрегезне вә сәүдәләрегезне куеп, намаз укырга, вәгазь тыңларга ашыгыгыз. Бу эш сезнең өчен хәерледер; әгәр бу эшнең файдасын белсәгез!»**

«Җомга», 62:9

Аллаһы Тәгаләнең чакыруына җавап итеп, без бүген дә җомга намазларына җыела алдык, Аллаһыга шөкер. Аллаһы Тәгалә безгә якын булган эшләребезне, сәүдәләребезне ташлап торырга кушты һәм без

аны эшләдек. Пәйгамбәребез галәйһиссаләтү вәссәлләм игътибар белән вәгазьләрне тыңлаган кешенең ике җомга арасында кылган кечкенә гөнаһкимчелекләре ярлыканачагын әйтеп калдырган. Һәм без, эшләребезне кырыйга куеп, телефоннарыбызны сүндереп, дөнья мәшәкатьләрен мәчет бусагасының теге ягында калдырып, вәгазь тыңлыйбыз. Җомганың шартлары да шулар бит. Ин шә Аллаһ, бу гыйбадәтләребез дә кабул булсын.

Бүген 22 нче февраль. Ир-атлар мәчетләрдә җомгада утырсалар, гүзәл затларыбыз – хатын-кызларыбыз кибетләрдә бүләк сайлап йөриләрдер. Бу уңайдан кадерле ир-атларыбызны 23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне белән тәбрик итәргә рөхсәт итегез.

Хатын-кызларыбыз кибетләрдә йөргәндә, бүген без сезнең белән үзебез хакында – ир-атлар хакында сөйләшеп китәрбез. Кем соң ул ират? Аның нинди вазифалары бар?

Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә игътибар итсәк, анда ир сүзе болай аңлатыла:

«Ир — борынгы төркиләрдә эр — сугышчы, яугир. Ир аты (исемен) алу өчен угыл ауда яисә яуда нинди дә булса батырлык күрсәтергә тиеш булган. Бүгенге татар телендә ир-ат — «ирләр» мәгънәсендәге җыйма сүз».

Димәк, элек-электән ир исеменә ирешү өчен, күпмедер дәрәҗәдә үз-үзеңне күрсәтергә яки нинди дә булса билгеле бер сыйфатларга ия булырга кирәк булган. Татарларда ир-атны элек-электән һөнәрле булырга, алынган эшләрен камил башкарырга, батыр, кыю булырга өйрәткәннәр. Балаларны шулай тәрбияләгәннәр. Татар халык мәкальләрен алып карасак, анда: «Егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз»; «Яхшылыкка яхшылык – һәр кешенең эшедер, яманлыкка яхшылык – ир кешенең эшедер»; «Ил – иргә, ир илгә таяна» кебек мәкальләр күрербез.

Кайбер чыганакларда ирләргә аңлатманы «хатын-кызларга антоним, ягъни капма-каршы булган зат» дип тә бирәләр. Бу гади генә аңлатма булса да, моның да үз мантыйгы бар: хатын-кыз гаиләне эчтән саклый,

ир-ат тышкы яктан; хатын-кыз нечкә күңелле, хискә бирелүчән, ир-ат – салкын акыллы; хатын-кыз 10 кг күтәрә, ә ир-ат – 50. Әмма бу – мәсьәләгә бер яктан килеп караганда гына шулай.

Инде Аллаһы Тәгаләнең китабы Коръәни Кәримгә игътибар итик. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً

**«Һәм синең Раббың фәрештәләргә әйтте: «Мин, әлбәттә, җир өстендә Адәмне хәлифә итеп кылмакчымын».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:30

Аллаһы Тәгалә җир йөзендә хәлифә буларак Адәм галәйһиссәламне, ягъни ир-ат кешене урнаштырган. Зур дәрәҗә белән беррәттән, олуг җаваплылык та биргән. Димәк, Ислам буенча ир-ат бик җаваплы кеше булырга тиеш. Һәм бу ир-аттан бик күпне таләп итә торган сыйфат, чөнки җаваплы кеше үз өстенә йөкләнгән вазифаларның барысын да үтәргә тырышачак. Шул вазифаларны Пәйгамбәребез галәйһиссәлам хәдисләреннән чыгып, санап үтик:

1. Күркәм холыклы булу. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәлләм бу хакта түбәндәге хәдисләрдә әйткән:

«Кулыннан һәм теленнән бүтән кешеләр имин булган кеше – мөселман була».

«Дөреслектә, нинди генә хәлләрдә дә йомшак булу – мөселманны бизи. Ә аның юклыгы (нинди генә эштә булмасын) – кешене каралта».

2. Калган кешеләргә яхшы мөгамәләдә булу. Бу хакта түбәндәге хәдисләрдән чыгып әйтеп була:

«Һәрбер мөселман – икенче мөселман өчен кардәш, шуңа күрә ул аны беркайчан да кыерсытмаска тиеш. Берәү авыр вакытта кардәшенә булышса, аңа авырлык килгәндә Аллаһы Тәгалә Үзе булышыр. Кем бер кардәшен

куркынычлыктан азат итсә, Аллаһы Тәгалә аны Кыямәт көнендәге куркынычлыктан азат итәр».

Бу пунктка тагын: кардәшең авырганда, аның хәлен белергә бару; вафат булганының җеназасын уку; чакырган кардәшнең чакыруын кабул итү; кардәшең белән күрешкәндә аңа сәлам бирү; үз кардәшеңә һәрвакыт яхшылык теләү; кардәше янында булганда да, булмаганда да аңа карата ихлас булу кебек вазифаларны кертеп булыр иде.

3. Пөхтә булу: кием, транспорт, йорт-җир һ.б.

Пәйгамбәребез ир-атларның матур булуларын яратып кына калмаган, ул һәрвакыт аңа чакырган да. Бер сәфәр вакытында ул сәхабәләренә: «Дөреслектә, сез үзегезнең кардәшләрегез янына барасыз. Шуңа күрә пөхтәләнегез, үзегезнең киемнәрегезне чистартыгыз, иярләрегезне матурлагыз. Сез аларның күңелләрендә чиста чишмәгә охшарга тиешсез», – дип әйтә. Әйе, мөселман кеше эчке яктан да, тышкы яктан да пөхтә булырга тиеш. Ниндидер яңа әйбер алырга акча җитмәгән очракта да, искенең кадерен белеп, чисталыкта тотарга тырышырга кирәк. Сәхабәләр заманын беләбез: Сәгъд бине Мөгаз атнага бер тапкыр өеннән чыкмый торган була. Шәһәр башлыгы булуга карамастан, кияргә бер генә киеме булган. Ул аны атнага бер тапкыр юып, аның кипкәнен көткән. Аннан соң кешеләр янына чыгып, идарә эшләрен дәвам иткән. Алмашка юк дип, атналар буе пычрак кием белән йөрмәгән.

4. Үз гаиләсен тәэмин итү, гаилә әһелләренә карата иң күркәм мөнәсәбәттә булу.

«Иң камилегез – холкы ягыннан иң күркәм булганыгыз. Ә иң яхшыларыгыз – үзенең хәләл җефетенә иң яхшы булганыгыз». Өйләнгән ир-ат, әлбәттә, үзенең хатынын, балаларын тәэмин итә. Өйләнмәгән булса, әти-әнисен кайгырта. Ничек кенә булмасын, ул гаиләле кеше булып санала һәм көченнән килгәнен эшләргә тиеш була. Нәкъ менә тиеш була: Коръәни Кәрим аятьләрендә һәм Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең

хәдисләрендә әйтелгәнчә, ир-ат – гаиләне матди яктан тәэмин итүче, анда тәртип саклаучы һәм тормыштагы авырлыкларны чишүне үз өстенә алучы кеше. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

الرِّجَالُ قَوَّامُونَ عَلَى النِّسَاءِ بِمَا فَضَّلَ اللَّهُ بَعْضَهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ وَبِمَا أَنفَقُوا مِنْ أَمْوَالِهِمْ ۚ

**«Аллаһы Тәгалә ирләрне акыл һәм көч-куәт ягыннан хатыннардан өстен кылганга һәм алар байлыкларын хатыннарга сарыф иткәнгә күрә, ир-атлар – хатыннар турында кайгыртып торучылар».**

«Нисә / Хатыннар», 4:34

Шулай ук ир-атның гаиләдәге иң зур вазифаларының берсе – хатынына һәм балаларына да яхшы мөнәсәбәттә булу.

وَعَاشِرُوهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ ۚ

**«...Никахта булган хатыннарыгыз белән яхшы мөгамәләдә булыгыз ...».**

«Нисә / Хатыннар», 4:19

Ир-ат һәрвакыт ир булып калырга тиеш. Юк-бардан тавыш чыгармаска, җаваплы булырга, гаиләне тәэмин итәргә тырышырга тиеш. Һәм әгәр дә хатынының берәр сыйфатын яратып бетермәсә дә, ул аны икенче бер сыйфаты өчен тагын да катырак ярата ала. Шуңа күрә, гаилә мөнәсәбәтләрен дә хикмәтле итеп алып бара белергә кирәк.

5. Гыйлемле булу. Аллаһы Тәгалә дә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә бу мәсьәләгә бик күп басым ясаганнар. Гыйлемле булу турында бик күп мәкаләләр язылган, бик күп вәгазьләр сөйләнелгән. Ир-ат дини гыйлем дә алырга, үзенең һөнәре буенча да камил гыйлемле булырга тиеш.

Дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле – пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам булган, дип әйттек. Шуңа күрә без – ир-атлар: «Безгә үрнәк күрсәтегез», – дип әйтсәк, иң беренче, Пәйгамбәребезгә карыйк! Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: ир-ат булу – кешегә кайбер «өстенлекләр» бирсә дә, масаер өчен бер генә дә сәбәп бирми, киресенчә, вазифалар гына өсти. Ир-ат дөрес итеп максатлар куярга һәм аларга ирешә белергә тиеш, ул башкаларны хөрмәт итәргә һәм үзе дә хөрмәтле булырга, ярдәмчел һәм үзенә күрсәтелгән ярдәмне кабул итә белергә, һәрвакыт үсәргә (һөнәри яктан, гыйлем ягыннан һ.б.), тәрбияле, күркәм әхлаклы булырга, ә иң мөһиме – тәкъва булырга тиеш. Аллаһы Тәгаләдән курыккан ир калганнарның да хакларына керергә, гөнаһлар кылырга, үз вазифаларын үтәмәүдән куркачак.

Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә дә өстебезгә йөкләгәннәрне башкарып чыгарга көч, дәрт, дәрман бирсә иде. Бу дөньяда да, Ахирәттә дә уңышларга ирешергә насыйп вә мияссәр кылса иде. Әмин!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*
*Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*1 март вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Рәгаиб – гаиләнең әһәмиятен искә төшерү

Барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә. Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез булса иде.

Аллаһы Тәгалә барча мәхлүкатны парлы итеп яратты. Коръәни Кәримдә Раббыбыз болай дип әйтә:

وَخَلَقْنَاكُمْ أَزْوَاجًا ﴿٨﴾

**«Дәхи, сезне парлы (ирле-хатынлы) итеп халык кылдык».**

«Набә / Хәбәр», 78:8

Кояш белән ай, җир белән күк, ут белән су, җәннәт белән җәһәннәм – барысы да парлы. Кошлар, хайваннар дөньясында да ир һәм хатын җенесләре бар. Атабыз Адәм галәйһиссәламне яратканнан соң, Аллаһы Тәгалә аның кабыргасыннан Хәва радыяллаһу ганһәне ярата. Шул вакыттан бирле ир-ат белән хатын-кыз пар булып, гаилә булып яши. Ислам дине гаиләне нык саклый. Гаилә ул – калкан. Ә гаиләнең башлангычы исә – никах. Шәригатебез ир-ат белән хатын-кызның никахсыз мөнәсәбәтләрен катгый тыя:

وَلَا تَقْرَبُوا الزِّنَىٰ ۖ إِنَّهُ كَانَ فَاحِشَةً وَسَاءَ سَبِيلًا ﴿٣٢﴾

**«Зинага якын да бармагыз, аның сәбәпләреннән дә ерак булыгыз, чөнки ул пычрак эш вә бик яман юлдыр».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:32

Никах – Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте. Һәм раҗәб аеның беренче атнакиченә туры килә торган Рәгаиб кичәсе безгә шул хакта искә төшерә дә. Раҗәб ае быел 7 март көнне ахшамнан соң башлана.

«Рәгаиб» дигән сүз гарәп телендәге «рәгабә» фигыленнән алынган, ягъни «нәрсәнедер теләү, шул теләгәненә ирешү өчен тырышу» мәгънәсен бирә. Шәргый яктан караганда, бу расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе белән әнисе никахлашкан көн. Ягъни бу – Пәйгамбәребезнең әнисе Әминә белән әтисе Габдуллага никах укылган һәм алар, ир белән хатын булып, Әминә безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә авырга узган вакыт.

Күп кеше шушы кичәдә нишләргә дигән сорау бирә. Догада булыйк, намаз укыйк, садака бирик. Гомумән, бер көндә дә гыйбадәтләребезне киметмик. Аеруча шушындый мөбарәк кичәләрдә нәфел гыйбадәтләребезне арттырыйк. Аллаһы Тәгалә каршында иң сөекле гыйбадәт – кыска, әмма дәвамлы булганы.

Шуны да искә алыйк – Рәгаиб кичәсе раҗәб аеның беренче атнакиченә туры килә, ягъни пәнҗешәмбедән җомгага каршы кич була. Быел ул милади буенча, ин шә Аллаһ, 7 нче март кичәсе булачак. 8 нче март – дәүләтебездә Халыкара хатын-кызлар көне булып билгеләнелә. Илебездә бу көн рәсми рәвештә ял булып санала. Димәк, пәнҗешәмбе иртәсеннән уразага кереп була. Нәфел, өстәмә ураза өчен иң хәерле көннәр булып дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе санала. Кич, кояш баегач, фарыз намазларыннан соң нәфел намазларын да укырга була. Төнге тәһәҗҗүд намазлары аеруча саваплы санала. Икенче көнне госелләнеп, җомга намазына барасыз. Ялны файдалы, саваплы үткәрү өчен бу бик яхшы форсат.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм раҗәб аенда уразаларын күбәйтә иде. Хәдис-шәрифләрендә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Раҗәб – ул утырту ае, шәгъбан – ул су сибү ае. Аннан

соң килә торган Рамазан – уңышны җыю ае. Раҗәб ае җитте икән – димәк, без Рамазан-шәриф аена якынлашабыз. Димәк, Рамазанга инде ныгытып әзерләнү кирәк», – дип әйткән.

Рәгаиб кичәсеннән без нинди дәрес-гыйбрәт алырга тиеш? Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең атасы Габдулла – бай нәселдән, затлы, белемле егет булган. Әнисе Әминә дә – күркәм, матур нәселдән. Алар Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән никахлашканнар. Без, шушы мәчетләрдә утыручы ир-атлар, – гаилә башлыклары, хатын-кызлар – йорт учагын саклаучылар, балаларыбызны никахка әзерлибезме? Үзебезгә иң элек шушы сорауны бирик әле. Әллә кызыбыз йә улыбыз укырга дип шәһәргә китеп, күпмедер вакыттан кайтып төшә дә: «Әтием, әнием, менә бу минем булачак ирем/хатыным», – дип, кисәк кенә хәбәр бирәме? Шунда гына, аһ-ваһ килеп, мулла эзләргә, никахка әзерләнергә тотынабызмы? Аллаһы сакласын, никахка кадәр үк балага узган очраклар да бар бит. Никахларга барабыз, ә килен инде бала көтә, шуны мулладан ничек яшерик икән дип тырышалар. Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын.

Монысы беренче мәсьәлә. «Әйе, без балаларыбызны никахка әзерлибез», – дип җавап бирсәк, сезгә икенче сорауны бирәм: без аларны кайсы вакыттан алып никахка әзерлибез? Мәктәптәнме? Әллә шул кызыбыз университет-институтка киткән чакта гынамы? Нинди сүзләр белән әзерлибез? Үзебезнең милләттән булсын дибезме? Мөселман егете булсын дибезме?

Безгә, хәзрәтләргә көн саен диярлек әти-әниләр килә дә: «Менә бит, хәзрәт, егет тә яхшы, әти-әнисе дә бик тәрбияле, ләкин безнең милләттән, безнең диннән түгел, нишлик?» – дип зар елый. Хөрмәтле әти-әниләр! Балаларыбызны никахка әзерләү – безнең бурыч! Телибезме, теләмибезме – без моны үтәргә тиеш. «Хәзрәт, нишлик инде, башка милләттән, башка диннән; никахсыз яшиләр, никахсыз балага узганнар», – дип елап киләбез

икән – димәк, без, әти-әниләр буларак, үз вазифабызны үтәмәгәнбез. Рәгаиб кичәсе шуның белән кыйммәтле: Габдулла белән Әминәне ничек итеп тәрбияләделәр, ничек итеп никахка әзерләделәр, ничек итеп никахландырдылар – бу безнең өчен үрнәк, искә төшерү. Без дә шулай итәргә тиеш: ул үстерәбез икән – аны ир-ат итеп тәрбиялик, якын-тирәбездә, дусларыбыз-танышларыбызда кайсыларында кыз үстерәләр – шуларны өйрәник. Нәселе, җиде буыннары нинди – тикшерик. Нәсел шәҗәрәсе дип күпме авыз корытабыз – ул бит матур агач кына түгел. Ул – нәселнең тарихы. Кемнәр булган, нинди булган – өйрәник, белик. Кыз үстерәбез икән – әдәпле, әхлаклы, тәртипле, иманлы, чын мөслимә булырлык итеп тәрбиялик. Балаларыбызны кечкенә чакларыннан ук дөрес итеп үстерик.

Рәгаиб кичәсе безгә нинди дәрес бирә? Никахтан соң күп вакыт та үтми – Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе сәфәргә чыккач, вафат була. Бала дөньяга ятим булып туа. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бабасы, Габдулланың әтисе киленне беркая да куып җибәрми: «Баланы табасың, сине карыйбыз, баланы тәрбиялибез», – дип әйтә. Ул вакытта гарәп кабиләләрендә гадәтләр кырыс булган. Ләкин бу гаиләдә берәү дә киленне куып чыгармый. Шушы бабасы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тугач, аны, Кәгъбәтуллаһ янына алып барып, аңа Мөхәммәд дип исем куша. Рәгаиб кичәсенең безгә искәртә торган тагын бер мәсьәләсе – без балабызга хәерле, матур, мәгънәле исем сайларга тиеш. Балаларыбызга да шуны өйрәтергә тиешбез.

Яңа туган сабыйларны мәчетләргә алып киләләр: нинди генә исемнәр юк! Моннан тәүбә итү кирәк. Шушы Рәгаиб кичәсендә Аллаһы Тәгаләгә ялварыйк, оныкларыбыз, аларның балалары һәм нәселебезнең киләсе буын дәвамчылары хәерле исемнәр йөртсен, әдәпле-әхлаклы, тәрбияле булсын, дип сорыйк. Раббыбыз әле никахлашмаган яшьләргә хәерле ирләр, хатыннар бирсен.

Рәгаиб кичәсе безгә гаилә тәртипләрен күрсәтә торган кичә. Габдулла белән Әминәнең никахлашуы, шушы никахтан Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тууы, аның хатыннары белән ни рәвешле никахлашуы, гаиләдә мөгамәлә кору рәвеше – болар барысы да мөселманнар өчен үрнәк булып тора. Без алардан өйрәнеп, аны үз балаларыбызга да җиткерергә тиешбез.

Аллаһы Тәгалә имин тормыш, бәрәкәтле гомер бирсә иде. Әмин!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*8 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Исламда хатын-кыз

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәәтүһү!

Зәйнәб бинте Җәхеш, Хафса бинте Гомәр, Гайшә бинте Әбү Бәкер, Хәдичә радыяллаһу ганһәләр дип әйткәч, кемнәр күз алдына килә? Әлбәттә, иң беренче чиратта, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хатыннары. Әмма без аларны пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам хатыннары булганга күрә генә истә калдырдыкмы икән? Әлбәттә юк! Ул хатын-кызларның һәрберсенең дә кылган гамәлләре аларны шундый югары дәрәҗәгә күтәрә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә алар турында бик күп әйтеп калдырган.

Ни өчен мин күркәм хатын-кыз сәхабәләребезне санап киттем соң? Бүген – 8 март, илебездә бәйрәм буларак билгеләп үтелә. Бүгенге җомга вәгазебез дә күркәм затларыбыз – хатын-кызларыбыз турында булыр, ин шә Аллаһ.

Элек-электән кешелек дөньясында исламда хатын-кызларның урыннары турында дөрес булмаган фикерләр яшәп килде һәм бүген дә яши. Ислам килгәнче, чыннан да, хатын-кызларга карата караш түбән иде. Әмма аларга гына түгел, ак тәнлеләр кара тәнлеләргә, байлар ярлыларга, кол биләүчеләр үзләренең колларына карата бик кырыс иделәр. Ислам дине килү белән, боларның һәммәсенә дә караш уңай якка таба үзгәрде. Хушлашу хаҗы вәгазендә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Раббыгыз бердер. Атагыз да бердер, сез барыгыз да Адәм балалары. Аллаһы янында иң кадерлеләрегез – Аңа бөек хөрмәт күрсәтүчеләрегездер. Гарәпнең гарәп булмаганнардан Аллаһыны хөрмәтләүдән башка бернинди өстенлеге дә юк», – дип әйткән. Аллаһы Тәгалә дә әйтә:

إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ

**«... Тәхкыйк, сезнең Аллаһы хозурында хөрмәтлерәгегез – Аллаһыдан куркып, гөнаһлардан күбрәк сакланучыгыздыр ...».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

Тарих буенча китапларны укып карасак, кайда да хатын-кызларның бернинди хокуклары булмавын, аларның хайваннарга тиң булуларын, хатын-кызның җаны юк, дип бәхәсләшкәннәрен һ.б. күрербез. Үзебездә патша хакимияте заманында хатыннарны ирләренең паспортларына гына язганнар һәм күз алдыгызга китерегез: иреннән киткән хатынны ире полиция ярдәмендә кире кайтара алган. В. И. Ленин хатын-кызларның хәле турында: «Россиядә хатын-кызларның хокуксызлыгы яки тулы хокуклы булмавы кебек түбәнлек, әшәкелек, кабахәтлек (бүтән бер җирдә дә) юк», – дип язган. Күрәбез, хатын-кызлар проблемасы диннән генә тормый. Ул элек-электән килгән дәүләтләрнең, милләтләрнең үз проблемасы. Әйе, гарәпләрдә дә бу проблема бик кискен булган. Әмма дин килү белән боларның һәрберсе тамыры белән юкка чыгарыла. Моңа дәлил итеп, күбебезгә мәгълүм булган ана турында әйтелгән хәдисне

китереп булыр иде: бервакыт сәхабәләрнең берсе Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән: «Мин кемгә күбрәк итагать итәргә тиешмен?» – дип сорый. Сөекле Пәйгамбәребез ни ди? «Әниеңә», – дип җавап кайтара. Сәхабә янә: «Ә аннан соң кемгә?» – дип сорый. Расүлуллаһ: «Әниеңә», – ди. Сәхабә тагын бер тапкыр: «Ә аннан соң, йә, Расүлуллаһ?» – дип сорый. Җавабы – әниеңә. Инде сәхабә дүртенче мәртәбә соравын кабатлагач, Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Әтиеңә», – дип әйтә. Ягъни өч тапкыр рәттән Пәйгамбәребез һәркайсыбыз өчен иң кадерле, хөрмәткә һәм игътибарга иң лаек кешенең әниебез булуын ассызыклый. Безгә билгеле, Коръәндә һәм хәдисләрдә өч тапкыр кабатлау – ул без аеруча игътибар итәргә, һичшиксез үтәргә тиешле әйбернең күрсәткече. Исламда хатын-кызларны җәберлиләр дип йөрсәк, мин менә бу җомгага җыелган барлык мөселманнардан сорыйм: кайсыгыз әниегезне яратмыйсыз? Аллаһы Тәгалә дә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُم مِّن نَّفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً

> **«Ий кешеләр! Сезне бер ата-анадан яратучы Аллаһыга каршылык күрсәтүдән сакланыгыз, Ул Адәмнең үзеннән хатын ятратты вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте».**

«Нисә / Хатыннар», 4:1

Тарих безгә бик күп танылган хытын-кызларны бүләк итте. Кайберләренең тормыш рәвешләрен карап үтик.

**Зәйнәб бинте Җәхеш радыяллаһу ганһә**

Пәйгамбәребез үрнәгенә ияреп, Зәйнәб юмарт һәм тыйнак була. Шулай көннәрнең берендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм барлык хатыннары барында: «Миннән соң сезнең иң озын куллыгыз миңа

иярәчәк», – дип әйткән. Пәйгамбәр галәйһиссәламнән соң беренче булып Зәйнәб бинте Җәхеш үлгән. Шул вакытта Пәйгамбәр хатыннары аның «иң озын куллы» (юмарт) булуын белгәннәр, чөнки Зәйнәб кул эшләрен яратып башкарган (тире эшкәрткән, күннән киемнәр теккән, дисбеләр ясаган) һәм ярлыларга шул малдан садакалар тараткан. Бу гамәлләрен ул барысын да Аллаһы ризалыгын өмет итеп башкарган. Өмме Сәләмә Зәйнәбнең үлеменнән соң: «Зәйнәб бик тугры хатын иде. Бик еш уразалар тотты һәм бик күп кул эшләре белән шөгыльләнде һәм шул рәвешле эшләп тапкан акчасын ярлыларга таратты», – дип әйткән.

**Гайшә радыяллаһу ганһә**

Гайшә бик юмарт булган. Үзе турында онытса да, мохтаҗлар турында беркайчан да онытмаган. Бервакыт ул ураза тоткан көнне аңа йөз мең дирһәм биргәннәр. Ул акчаны бүлгән дә, мохтаҗларга тараткан. Гайшә гыйлем алуга да зур игътибар биргән, Пәйгамбәр галәйһиссәламнең күп хәдисләрен һәм гамәлләрен истә калдырган. Аның гыйлеме турында сәхабәләр түбәндәге сүзләрне әйткәннәр: «Гайшәнең гыйлемен җыеп, аны башка бар хатын-кызлар гыйлеме белән чагыштырсаң, Гайшәнең гыйлеме өстенрәк булыр иде. Безгә нинди дә булса хәдис аңлашылмаса, без аның турында Гайшәдән сорый һәм һәрвакытта да җавап таба идек». Гайшә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән 2210 хәдис тапшырган.

Гәйсә пәйгамбәр әнисе Мәрьямнең диндарлыгы хакында Коръәни Кәримнең күп кенә аятьләрендә әйтелә. Коръәни Кәримнең бер сүрәсе дә аның исеме белән атала.

Коръәндә баштарак килгән сүрәләрнең озын булуларын беләбез. Аллаһы Тәгалә шул озын сүрәләрнең берсен «Ән-Нисә», ягъни «Хатын-кызлар» дип атады. Бу хатын-кызларга карата хөрмәт күрсәтү түгелме? Коръәндә «Ир-атлар» сүрәсен күргәнегез бармы?

Күп-кешеләр хатын-кызларны баштанаяк төренеп йөрергә мәҗбүр итәләр, дип әйтәләр. Хәтта кайбер мөселманнар арасында да киенү

мәсьәләсенә карата тискәре фикерләр бар. Күз алдыгызга китерегез: сездә бик кыйммәтле бриллиант бар, ди. Сез аны бөтен кеше күрсен дип, муеныгызга тагып йөриячәксезме? Әллә инде чит-ятлар кул сузмасын дип, сейфка салып куячаксызмы? Менә хатын-кыз да шул бриллиантка тиң. Шуңа күрә хатын-кызның тәнен каплап йөрүе тиешледер дә. Капламаса – бөтен ир-атларның күзләре аңарда булыр иде. Хатын-кызлар ярым ялангач йөри торган илләрдә фәхешлекнең артканын барыбыз да беләбез. Никахсыз бала алып кайтулар, гаиләләр таркалу – болар барысы да шушы таләпләрне үтәмәүдән килә бит.

Аллаһы Тәгалә хатын-кызларга бик күп өстенлекләр биргән. Физик яктан хатын-кызлар беренче өлгерә, аларда авыруларга карата иммунитет көчлерәк була, алар гына бала таба ала һ.б. Бөек галимнәр, укытучылар тормышын өйрәнсәк, аларның галим булуларында яшьтән үк белем алырга өндәгән әниләренең өлеше зур. Мисал итеп, Әбү Хәнифә, Имам Шәфигыйны һ.б. китерергә була. Шулай ук, Томас Эдисон дигән олуг галимне ишеткәнегез бардыр. Мәктәптә укыган вакытында, ул әнисенә укытучыдан хат алып кайтып бирә. Малай ул вакытта үзе укый белми. Әнисе хатны кычкырып укый башлый: «Сезнең улыгыз – галим. Безнең мәктәбебез дә кечкенә, аны укытырлык укытучыларыбыз да юк. Аны үзегез укытыгыз». Әнисенең вафатыннан соң (Эдисон ул вакытта инде бик зур галим була) ул гаилә архивын карап утыра. Шунда ул бу хатны табып ала. Хатны ачып укый башлый. Анда: «Сезнең балагыз – акыл ягыннан артта калган. Без аны калган балалар белән бергә укыта алмыйбыз. Аны үзегез укытыгыз», – дип язылган була. Эдисон берничә сәгать елап утыра. Соңыннан үзенең көндәлеген ачып, мондый язу яза: «Томас Алва Эдисон акыл ягыннан артта калган бала була. Әмма үзенең герой анасы аркасында ул үз заманының олуг галименә әверелә».

Күргәнебезчә, бер гаилә эчендә генә дә хатын-кызның роле нинди зур. Ул – ана да, ул – гаилә учагын саклаучы да, ул – яратучы хатын да.

Шуңа өстәп бүгенге көндә мәктәп укытучыларының 95 % – хатын-кызларыбыз. Алар кулында милләтебезнең киләчәге тәрбияләнелә.

Шулай итеп, хатын-кыз да, ир-ат та Аллаһы Тәгалә каршында бер үк хокукларга ия затлар, дип әйтергә була. Аллаһы Тәгалә хатынны да, ирне дә ике күзле, ике колаклы, бер төрле җанлы итеп яраткан. Яшәү урыннары да Җир шарында, икесенең дә барачак урыннары йә җәннәт, йә җәһәннәм. Аңа карамастан, Аллаһы Тәгалә хатын-кызларны зурлап, башта аталарына кызларын күбрәк кайгырга, ә инде кияүгә чыккач, ирләргә хатын-кызны барлык кирәк-ярак белән тәэмин итәргә куша. «Җәннәт – аналарның аяк астында», – дибез. Ир-атның җәннәтле булуы – аның хәләл җефетенең дә, шул ук аның анасының да ризалыгында гына була ала. Болар барысы да хатын-кызның Исламда тоткан югары урынын күрсәтә. Безгә дә Аллаһы Тәгалә үзебезнең динебезне өйрәнеп, аны дөрес аңлап, калган кешеләргә дә күркәм рәвештә җиткерергә насыйп әйләсә иде. Бер-беребез белән матур, тату яшәргә мияссәр кылса иде. Әмин!

*«Хозур» редакциясе*

*15 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Ришвәтчелек – җәмгыять чире

Бүгенге көндә ришвәтчелекнең тирән тамыр җибәрүе, афәткә әйләнә баруы турында чаң сугалар, әмма ничек кенә булмасын, илнең икътисади үсешенә зыян салган, әхлакый кыйммәтләргә каршы килгән бу золым белән көрәшергә бик үк атлыгып тормаганнарын күрәбез. Ни өчен? Чөнки аның «яшәве», булуы, хакимлек итүе уңайлы күренеш. Ришвәт җир йөзендә кешеләр барлыкка килгән дәвердән диярлек яши килә.

Ришвәтчелек (рус телендә «коррупция») дип аталган бу билгеләмәнең латинчадан тәрҗемәсе «таркалу, бозылу» дип яңгырый. Аның бик күп галәмәтләрен күзәтә алабыз. Хокуксыз рәвештә мал-мөлкәтне, акчаларны үзләштерү дә шуңа керә.

Әлбәттә, ришвәтчелек кайбер намуссыз түрәләрнең, югары урыннарда утырган яки бүтән кешеләргә теге яисә бу хезмәт күрсәтә алырга җайлары булган кешеләрнең үз мөмкинлекләрен кулланып, шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерергә омтылулары аркасында тирән тамыр җибәрә. Бер караганда, бу эштә ике як та риза кала сыман, әмма башка кешеләр хакында бермә-бер онытыла, аларның уй-теләкләре, ниятләре, максатлары бөтенләй юкка чыга.

Кызганычка, ислам илләре дә бу чирдән азат түгел. Сәбәбе – шәригать кануннарын рәсми рәвештә генә үтәп яшәүләре.

Аллаһыдан ихлас курку белән курыкмаган кеше бик тыныч халәттә гөнаһлар, гаделсезлекләр кылып яшәячәген истә тотыйк.

Түбәндәге хәдисләрдән динебезнең чыннан да ришвәтчелек белән көрәшкәнен, аның бу афәткә тулаем каршы булганын күрәбез:

1. Габдуллаһ бине Гомәрдән (Аллаһы аннан риза булсын) тапшырылган бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең болай дип әйткәне риваять ителә: «Сезнең һәрберегез көтүче һәм һәрберегез үз көтүе өчен җавап бирә. Ир-ат үзенең гаиләсе өчен җавап бирә, хатын-кыз йорты өчен, кол булган кеше хуҗасының мал-мөлкәте өчен җавап бирә».

Моннан бигрәк Пәйгамбәребез: «Һәр ир-ат үз атасының малы өчен җавап бирә. Шулай булгач, сезнең һәрберегез үзенә әманәт итеп тапшырылган һәрнәрсә өчен җавап тота», – дип әйткән.

2. Әнәс бине Мәлик (Аллаһы аннан риза булсын) сөйләвенчә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә: «Үзегезнең кардәшегезгә гаделсезлек кылганда һәм аның үзенә гаделсезлек кылганнарын күрсәгез, ярдәм итегез», – дип әйткән. Сәхабәләр: «Аңа карата гаделсезлек кылуны аңладык, әмма ул гаделсезлек кылганда ничек ярдәм итик?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Аны гаделсезлек кылудан йолып калу – үзе ярдәм була инде», – дип җавап кайтарган[1].

3. Гадийә бине Гомәйра (Аллаһы аннан риза булсын) тапшыра: Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Без хезмәткә яллаган берәр кеше үзендә энә генә яшереп калдырса да, бу дәүләт мөлкәтен урлау булып санала. Моның өчен ул Кыямәт көнендә җавап бирәчәк», – дип әйтә. Шулчак Аллаһының Илчесенә әнсарлардан булган бер ир-ат килә дә: «Йә, Пәйгамбәребез, минем эшемне кире ал, мин үземә йөкләнгән садака җыю хезмәтеннән баш тартам», – дип әйтә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам гаҗәпләнеп: «Ни булды сиңа? – дип сорый. Теге кеше: «Мин әйткәннәреңне ишеттем», – дип җавап кайтара. Шулчак Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Мин яңадан әйтәм, мин хезмәткә яллаган һәркем үзенә бирелгәнне, кечкенә яки зур булуына карамастан, тапшырырга тиеш», – дип әйтә[2].

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

4. Габдуллаһ бине Гамердән (Аллаһы аннан риза булсын) китерелгән бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең болай дип әйткәне риваять ителә: «Ришвәтне бирүчегә дә, алучыга да Аллаһының ләгънәте була»[1].

Килешәсездер, бу ришвәтчелеккә кагылган бик катгый һәм җитди кисәтү.

5. Ибне Борайдә (Аллаһы аннан риза булсын) әтисе сүзләреннән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әйткән сүзләрен бәян итә: «Өч төр казыйның берсе генә җәннәткә ия булыр. Үз файдасы өчен һәм гыйлеме булмаган хәлдә хөкем чыгаручы җәһәннәмгә эләгер. Бары һәрдаим дөреслеккә таянып эш итүче казый гына җәннәт белән шатландырылыр».

6. Алдагы хәдистә Гайшә радыяллаһу ганһә риваять итеп калдырган кыйсса китерелә:

Бер көнне Корәеш кабиләсе кешеләре Бәни Мәхзум кабиләсендәге караклыкта тотылган хатын-кыз өчен борчылды. «Пәйгамбәребез алдында аның файдасына кем җавап тотар икән», – дип үзара фикерләште. Кайберәүләр: «Моны Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең яраткан сәхабәләреннән булган Усәмә бине Зәйдтән гайре кеше булдыра алмас», – дип әйттеләр. Усәмә бине Зәйд бу хакта Пәйгамбәребезгә сөйли башлагач, Аллаһының Илчесе әлеге сәхабәдән: «Син Аллаһы каршында җәзага тартыла торган гамәл файдасына арадашчы булырга тырышасыңмы?» – дип сорый. Шуннан соң Пәйгамбәребез галәйһиссәлам күтәрелеп, әлеге вәгазен сөйли: «Сезгә хәтле булган кавемнәрнең юкка чыгуының бер сәбәбе – алар югары даирә кешесе караклык кылса – кичерә, ә фәкыйрь кеше урласа – Аллаһы шәригате буенча җәзага тарта иделәр. Аллаһы белән ант итәм, әгәр Мөхәммәд кызы Фатыйма караклык кылса, мин аның кулын кисәргә әмер бирер идем», – дип әйтә (Бохари).

[1] Ибне Мәҗәһ хәдисләр җыентыгыннан

Ришвәтчелек тамыр җәюенең төп проблемасы – билгеле бер һөнәргә яраклашмаган, гыйлеме булмаган кешенең шул хезмәтне башкарырга омтылып эш итүе. Бәлки бу кеше сәләте булган бүтән хезмәттә яхшы гына эшли алыр иде. Ә аның эшен күпкә тиешлерәк итеп башка берәү башкара алыр.

Моңа ачык мисал итеп Коръәни Кәримнән Йосыф галәйһиссәлам вакыйгасын китерик. Ул үзен Фиргавенгә казна белән эш итүче һәм дәүләт керем-чыгымнарын исәпкә тотучы башлык буларак тәкъдим итә. Бу тәкъдиме белән ул ике төп шартны алга чыгара. Беренчедән, бу эшләргә алынучы үз эшенең остасы, ягъни бу өлкәдә гыйлемдар булырга тиеш. Икенчедән, ул намуслы, Аллаһы каршында үз гамәлләре өчен җавап бирүдән курыккан, кешеләр алдында ышану яулаган булырга тиеш.

Йосыф галәйһиссәламнең әлеге сүзләре Коръәни Кәримдә китерелә:

قَالَ اجْعَلْنِي عَلَىٰ خَزَائِنِ الْأَرْضِ ۖ إِنِّي حَفِيظٌ عَلِيمٌ ﴿٥٥﴾

**«Мине җирләрне саклаучы итеп билгелә, чөнки мин белдекле сакчы».**

«Йосыф», 12:55

Бу контекстта пәйгамбәрнең «саклаучы» дигән сүзенә басыйм ясыйк. Чыннан да, зинданга ул югары даирә вәкиле булган мисырлының хатыны корган фетнә аркасында эләгә. Йосыф үзенең дә, бу хатынның да намусын саклап кала, Аллаһыдан курыкканга күрә гөнаһка батмый.

Шулай ук, Йосыф галәйһиссәламнең күз явын алырлык чибәрлеге булган ир-ат булу белән беррәттән, бик хикмәтле, һәрнәрсәгә анализ ясый белгән шәхес булганлыгын беләбез.

Хезмәткә яраклы булу дигән төшенчә турында сөйләшеп үткәч, шуның хакында да әйтеп узу кирәк: еш кына физик эшкә яраклы булган кеше гыйльми эшкә туры килми яки киресенчә була. Мондый хезмәтләргә кеше билгеләгәндә, бу мәсьәләгә аеруча да игътибарлы булу кирәк.

Бервакыт Муса галәйһиссәлам Шөгәеб пәйгамбәр кызларының көтүдә булган хайваннарына су эчерергә ярдәм итә.

قَالَتْ إِحْدَاهُمَا يَا أَبَتِ اسْتَأْجِرْهُ ۖ إِنَّ خَيْرَ مَنِ اسْتَأْجَرْتَ الْقَوِيُّ الْأَمِينُ ﴿٢٦﴾

**«Ике кызның берсе: «Ий атам, бу кешене хакын түләп көтүчелеккә ал, тәхкыйк, син хак түләп алган кешеләрнең хәерлесе, куәтлесе һәм әманәтле булганы – улдыр», – дип әйтә.**

«Касас / Хикәя», 28:26

Атасы аның шундый икәнен ничек белдең дигәндә, кызы: «Ун кеше тарта торган чиләкне бер үзе тартып, куйларыбызны эчерде һәм чакырырга баргач, күзе төшмәс өчен, мине артыннан кайтарды», – дип әйтә. Билгеле булганча, монда гыйлем, акыл белән эш итү турында сүз бармый, чөнки Муса галәйһиссәламне физик әзерлек таләп ителгән авыл эшенә ялларга телиләр. Әмма башкаларындагы кебек үк, бу аятьтә дә кеше нинди генә эшкә алынса да, аның, иң беренче чиратта, намуслы, ышанычлы булу мөһимлеге ассызыклана. Кеше физик хезмәткә алынса да яки гыйльми эшкә тотынса да, иң беренче чиратта, ул намуслы, ышанычлы кеше булырга тиеш. Бу сыйфатлар һәр хезмәтнең нигезендә ятса, һәр өлкәдә дә гаделлек, дөреслек хакимлек итәр иде.

Муса галәйһиссәлам хакында сөйләнгәч, аның турында тагын бер вакыйганы әйтеп узыйк. Аңа Аллаһыдан Фиргавен янына барып, бер илаһлыкка чакырырга әмер килгәч, Муса галәйһиссәлам туганы Һарунны үзе белән алырга тели:

وَأَخِي هَارُونُ هُوَ أَفْصَحُ مِنِّي لِسَانًا فَأَرْسِلْهُ مَعِيَ رِدْءًا يُصَدِّقُنِ إِنِّي أَخَافُ أَن يُكَذِّبُونِ ﴿٣٤﴾

**«Кардәшем Һарун миннән яхшырак сөйли, аны миңа ышандырып, миңа ярдәмче итеп җибәр, югыйсә, мин аларның мине ялганга тотуларыннан куркам».**

«Касас / Хикәя», 28:34

Муса галәйһиссәлам Фиргавен алдында сүз тотасын, аны ышандырырга тиешлеген аңлый. Һәм бу эштә матур сөйләмгә ия булган туганы Һарунны үзе белән җибәрергә Аллаһыдан рөхсәт сорый.

Димәк, изге китабыбыздан без теләсә нинди хезмәткә алынучы кешенең төп ике сыйфатка ия булуының мөһимлеген аңлыйбыз. Ул үз эшенең остасы, ягъни бу өлкәдә гыйлемгә ия булырга һәм намуслы кеше дә булырга тиеш. Намуслы кеше Аллаһыдан курка һәм кырын эшләр кылудан үзен дә, үз кул астында эшләүчеләрне дә саклый.

Әгәр кеше бу сыйфатларына хыянәт итсә, ул бу дөньясына гына түгел, ә Ахирәтенә дә зыян сала.

Беркөнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына берәү килеп: «Миңа Кыямәт көне турында хәбәр бир», – дип әйткән. Аллаһының Илчесе бу вакытта әңгәмә кору белән мәшгуль булганга, әлеге кешегә бераз көтеп торсын, дип ишарәләп аңлаткан. Бераздан ул сорау бирүченең кайдалыгын сораган. «Мин монда, Аллаһының Илчесе», – дип җавап биргән теге кеше. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Сәгать, ягъни Кыямәт көне, намус, вөҗдан юкка чыккач җитәчәк», – җавап кайтарган. Бу кеше: «Алар ни рәвешле юкка чыгачак соң?» – дип сораган. Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Эшләрне алып барырлык гыйлемнәре һәм хәтта ул эшләрдән хәбәрдар булмаган кешеләргә шул хезмәтләрне йөкләгән вакытта намус юкка чыгачак», – дип җавап кайтарган.

Ислам галимнәре бу хәдискә аңлатма биреп ике вариантны тәкъдим итә. Беренчесе – туганлык, ришвәт бирү аркасында билгеге бер өлкәдә эшли алмаучыларга эш урыны бирү. Бу гамәл Кыямәт көне якынлашуының ачыктан-ачык мисалы, чөнки бу рәвешле Җир йөзендә тәртип бозыла.

Икенчесе – Җир йөзендә намус юкка чыгу аркасында җәмгыятьтәге хәл начарланганга күрә, Кыямәт көне җитәчәк, чөнки дәүләтләр, халыклар арасында билгеле бер тәртип югалачак.

Бу күренешләрне бүгенге көндә бик күп илләрдә күзәтә алабыз. Болар ислам илләре өчен дә ят түгел. Хакимияттәгеләр нәрсәдер үзгәртергә тырышып карасалар да, алга китеш һәм яхшы якка үзгәрешләр күренми.

Ришвәтчелек, кайсы гына өлкәне алсак та, аны чорнап алып, тирән тамыр җибәргән. Ә барысы да иң баштан ук теге яки бу өлкәдә тиешсез кешеләргә, лаек булмаганнарга билгеле бер вазифа бирү аркасында килеп чыкты. Шул рәвешле административ ришвәтчелек үрчеде һәм аннан котылу җиңел түгел.

Әлеге язмада ришвәтчелек, аның килеп чыгышы, барлыкка килүенең сәбәпләре, бу афәт турында Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең әйткән сүзләре һәм бу бәланең җәмгыятебез өчен коточкыч зыян салганы, хәтта ки Кыямәт көненең бер билгесе булуы турында сүз барды.

Йомгаклап шуны әйтик, динебез рухи кыйммәтләрне иң беренче урынга куя. Намус, гаделлек, кешелеклелек, миһербанлылык, ихласлылык, дөреслек, һәркемгә тигез карау һәм башка бик күп сыйфатлар динебезнең, кыйблабызның асылын тәшкил итә. Кызганыч, әмма җәмгыятьтә, кешеләр арасында әлеге төшенчәләргә урын юк. Ни генә булса да, һәркем изгелеккә, чисталыкка омтылып яшәргә тырышса иде, гәрчә бүгенге тормышта бу гамәлләрне кыен тоелса да.

Аллаһы Тәгалә күңелләребезне чистартып, гөнаһларыбызны гафу итеп, кылган изге гамәлләребездән риза булса иде.

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*Казанның «Галиев» мәчете имам-хатыйбы*

*22 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Мөселманның милләткә һәм ватанга мөнәсәбәте

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахим. Әлхәмдү лилләһи Раббил гааләмиин, вәс-саләәтү вәс-сәләмү галәә сәййидинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Раббыбыз Җәнабел-Хак хәзрәтләре Кәламе-Шәрифендә болай дип хәбәр итә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُم مِّن نَّفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالْأَرْحَامَ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا ﴿١﴾

**«Ий кешеләр! Сезне бер җаннан (яки Адәм галәйһиссәламнән) яратып, аннан ишне (яки Хәва ананы) бар итеп һәм (нәселләндереп) алардан күп ирләрне һәм хатыннарны (җир буйлап) тараткан Раббыгыздан куркыгыз! Үзе белән (яки Аның хакы өчен дип) бер-берегездән үтенә торган Аллаһыдан һәм кардәшлек бәйләнешләреннән (яки аларны өзүдән) куркыгыз! Аллаһы сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче бит».**

«Нисә / Хатыннар», 4:1

Димәк, Адәм галәйһиссәламне Адәм атабыз дип атау сере шушы илаһи хикмәт белән бәйле.

Шуннан Раббыбыз башка бер аятьтә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«Ий, кешеләр! Без сезне (бер) ирдән вә хатыннан, (ир белән хатын буларак) яраттык һәм дә бер-берегезне белеп таныр өчен халыклар вә кабиләләр иттек. Хакыйкать ки, арагыздан Аллаһы каршысында иң хөрмәтлегез – иң тәкъва булучыгыз. Аллаһы Белүче вә һәр эшегездән Хәбәрдар».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

Вакыты килеп җиткәч, бер ата, бер ана балалары төрле-төрле халыкларга, кабиләләргә бүленәләр. Шуннан соң төрле телләрдә сөйләшә торган, төрле гореф-гадәт ияләре була торган халыклар барлыкка киләләр. Әгәр Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә хәзрәтләре теләгән булса, барча адәм баласы бер дин иясе, бер өммәт булыр иде. Раббуль-Гыйззә хәзрәтләре болай дип игълан итә:

كَانَ النَّاسُ أُمَّةً وَاحِدَةً

**«Кешеләр бер өммәт булган иде ...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:213

Шуның кебек, әгәр Аллаһы Раббыбыз барча адәм балаларын бер халык, бер кабилә буларак калдырырга теләсә, ул шулай булган булыр иде. Ләкин бүген җир йөзендә, төрле чыганаклар буенча, биш мең тирәсе төрле халык яши. Һәр халыкның борынгы заманнардан бирле яшәгән, сыенган урыннары бар. Әти-әни, аларга кадәр әби-бабалар, аларның әбибабалары яшәгән урынны Ватан дип, үзебез дөньяга килгән урынны – туган як дип атыйбыз.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ватанын сөйгәнме? Туган ягын ратканмы? Милләтенә карашы нинди булган?

Һәр эштә, фигыль, гамәлдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнар өчен күркәм, изге үрнәк булып тора. Раббуль–Гыйззә хәзрәтләре болай дип әйтә:

لَقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا ﴿٢١﴾

**«Аллаһыны (яки Аның ризалыгын) өмет иткән вә Ахирәт көненә (өметен баглаучыга) вә Аллаһыны күпләп зикер кылучыга, сезнең (барчагыз) өчен Аллаһының Расүлендә күркәм үрнәк бар».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:21

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган ягын, ватанын, халкын, милләтен бик яраткан. Аның шикелле без дә, татарлар, халык буларак туган ягыбызны, ватаныбызны, халкыбызны, милләтебезне яратырга тиешбез. Туган ягыңны, ватаныңны, халкыңны, милләтеңне чын күңел белән ярату татар телендә «ватанпәрвәрлек» дип атала. Димәк, ватанын, туган ягын, халкын, милләтен чын ихлас күңеленнән яраткан кеше «ватанпәрвәр» дип аталыр. Бүген бу сүзләрне күп кеше белми, алар урынына «патриотизм» һәм «патриот» дигән юнан (грек) теленнән алынган сүзләрне кулланалар. Монысы да бер күрсәткеч: туган ягыңны, ватаныңны, халкыңны, милләтеңне яраткач, туган телеңне белергә һәм сакларга тиешсең, туган телеңдә сөйләшә алырга тиешсең.

Мөселман бәндәсе өчен туган як – бер ватан, туган ил – икенче ватан, мөселман өммәте яши торган урын – өченче ватан. Шәригатебез ягыннан намаз уку хөкеме кешенең яшәгән урыны белән бәйле: бәндә яки асыл ватанында яши, яки икамәт ватанында яки ватан-сүкнәдә тора. Асыл ватан – туган илең, даими хәлдә яши торган урының. Икамәт ватан һәм ватан-сүкнә сәфәр кылу белән бәйле: ягъни бара торган урын асыл

ватаннан 100 чакрымнан артык ераклыкта булу һәм сәфәргә чыккан урында кешегә 15 көнгә кадәр яки 15 көн һәм аннан артыгырак вакыт уздыру кирәк.

Ватанпәрвәрлек дөрес булырга, чиктән чыкмаска тиеш. Үз халкыңны яратып, башкаларны күрә алмау яки башка халыкларны кимсетү – шәригатькә сыймас күренешләр. Саубуллашу хаҗы тәмамлангач, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләргә мөрәҗәгать итеп: «Ий кешеләр! Раббыгыз бердәнбер түгелмени? Хакыйкать ки, сезнең Раббыгыз – бердәнбер! Гарәпнең гарәп булмаганнан, гарәп булмаганның гарәптән, кызыл төсленең кара төследән, кара төсленең кызыл төследән өстенлеге – бары тик тәкъвалыкта гына түгелме? Җиткердемме?» – дип әйткән. Халык: «Җиткердең, йә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм!» – дип, сорауга җавап кайтара. Димәк, шәригать йөзеннән бер кеше икенче кешедән, бер кавем башка бер кавемнән ниндидер бер милләткә, кабиләгә катнашы булганга күрә генә өстен була алмый. Аллаһы Тәгалә каршындагы өстенлек бары тик тәкъвалыкта, диндарлыкта, игелектә генә була ала. Фәлән кеше башка фәләннән тәкъвалырак; фәлән ханым икенче бер ханымнан диндаррак булырга мөмкин; әмма фәлән милләткә катнашы булган берәү башка бер милләт кешесеннән өстен була алмый. Шәригать буенча, гомумән, аерым милләтне, халыкны кимсетү, мыскыл итү рөхсәт ителмәс. Үз халкыңны, кавемеңне яратып, өстен һәм якын күреп, башка халыкны, кавемне күрә алмау, аларга дошман кебек карау – Шәригате-Гаррәдә катгый хәлдә тыелган. Мондый хис Ислам динен белмәгән, наданлык чорыннан чыкмаганнарга гына хас. Бу күренеш шәригатебездә «гасабийя» дип атала. Хәзерге татар телендә хәтта бу күренешне аңлата торган сүз, төшенчә дә юк. Татар халкында андый гадәт тә булмаган, әлхәмдүлилләһи вә шөкер! Әгәр халык арасында, аның гореф-гадәтендә берәр төрле нәрсә кулланмаса, халыкка ул нәрсә таныш булмаса – телдә аны билгели, күрсәтә торган сүз, төшенчә дә булмас. Шуңа

күрә татар телендә мондый әшәке күренешне француз теленнән алынган сүз белән, төгәлләп әйткәндә «шовинизм» сүзе белән билгелиләр. Шовинизм – бер милләтнең икенчесен түбәнсетүдән, кимсетүдән, аны үзенә буйсындырудан гыйбарәт. Ислам динендә бу күренеш юк! Әмма үзләрен мөселман дип исәпләгән берәр кавемдә бу күренеш барлыкка килсә, алар тәүбәгә килеп, хаталарын аңлап, ялгышлыкларын төзәтмәсәләр, шуны белсеннәр: Ислам дине алардан пакь, андый кавемгә Ислам диненең катнашы да юк.

Башкалабызда, шәһри Казанда Татарстан халыклары Ассамблеясе яки җәмгыяте, Халыклар дуслыгы йорты уңышлы гына эшләп торалар, Аллаһыга шөкер. Бүгенге көндә җөмһүриятебездә даими хәлдә йөз җитмештән артык милләт яши. Шулай ук, үзләрен, гаиләләрен тәэмин итәр өчен вакытлыча эш эзләп килә торган кешеләр дә шактый.

Раббыбыз Тәбәракә вә Тәгалә хәзрәтләре Кәламе Шәрифтә:

قَالُوٓا أَلَمْ تَكُنْ أَرْضُ اللَّهِ وَاسِعَةً فَتُهَاجِرُوا فِيهَا ۚ

**«... Алар: «Әллә һиҗрәт кылган булсагыз, Аллаһының җирен киң буларак тапмас идегезме?»**

«Нисә / Хатыннар», 4:97

– дип фәрештәләрнең үз-үзләренә карата золым кылганнарга сорау бирәчәкләрен сөйли.

Димәк, бер җирдә яшәрлек шартлар җитәрлек булмаса, ризыгыңны башка урында эзләргә кирәк. Ризыгы кайда булса, бәндә шунда булыр. Моны раслап, Раббыбыз Тәбәракә вә Тәгалә хәзрәтләре:

وَمَن يُهَاجِرْ فِي سَبِيلِ اللَّهِ يَجِدْ فِي الْأَرْضِ مُرَاغَمًا كَثِيرًا وَسَعَةً ۚ

**«һәм кем булса да Аллаһының юлында һиҗрәт кылса, җир йөзендә күп төрле сыеныр урын вә (ризык) киңлеге табар ...».**

«Нисә / Хатыннар», 4:100

Җөмһүриятебезгә вакытлыча килүчеләр арасында, безнең белән элекке бердәм илебездә, Советлар Берлегендә яшәгән үзбәк, таҗик, кыргыз, әзербайҗан да, ерак чит илләрдән килгәне дә, мәсәлән, төрекләр вә бар. Югары белем бирә торган уку йортларына укырга килгән гарәпләр, фарсылар, һиндлылар, Африка илләреннән килгән укучылар да шактый күп.

Ризык падишаһы – Аллаһы Тәгалә. Ул – Раззак булучы. Һәркем үз ризыгын кәсеп итә, берәү икенче берәүнең ризыгына хуҗа була алмас. Шуңа күрә без, мөселманнар, эш, ризык эзләп, кәсепләнергә килгән чит ил кешеләренә һәркайсысына, һәрберсенә ихлас күңел белән елмаеп карарга, кабул итәргә тиешбез. Йөзеңдә булган ихлас елмаю – сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәткәнчә садака, игелек галәмәте булганны истә тотыйк! Мөселман булганнарына карата моны дини кардәшлек таләп итсә, мөселман булмаганнарына карата моны Адәм атабыз хакы, адәми кардәшлек таләп итә. Мөселман өммәте, татар халкы ярдәмчел булуы белән мәшһүр. Шушы изге сыйфатны саклап, иманыбызны ныгытырга насыйп булсын.

Халкыбызның «Төрле авылда төрле әт-тәхият» дигән мәкален дә истә тотыйк. Һәр халыкның башка халыклардан аермалы буларак саклый торган үз гореф-гадәтләре бар. Яшәр өчен күчеп килгәнме, эш эзләп килгәнме – аермасы юк. Яңа килгән кешеләр безнең гореф-гадәтләр белән күбесенчә таныш түгелләр. Аларны өйрәтү, бер береңне хөрмәтләү, ихтирам белән аралар төзү – дәүләт эше генә, дип уйларга ярамый. Җөмһүриятебезгә килә торган чит ил халыклары, күбесенчә, мөселман илләреннән, төбәкләреннән булып чыга. Мөселман бәндәсенең мөселман кардәшенә тартылу сер түгел, бу илаһи тәртипләрнең берсе. Ыгы-зыгы, фетнә чыкмас өчен аларга җирле үзенчелекләрне аңлату – хәзрәтләр, абыстайлар, остаз, шәкертләр, һәр ихлас мөэмин-мөэминәнең изге бурычы.

Дуслык, кардәшлек хисләрен, җәмгыятьтә татулыкны, тынычлыкны саклау Халикъ каршында да, халык каршында да өстебездә булган изге бурыч. Аллаһы Тәгалә безгә аны җиренә җиткереп үтәргә көч-куәт, түземлек-сабырлык бирсә иде.

*Фәрид хәзрәт Сәлман,*

*Татарстан Җөмһүрияте Коръәни-Кәрим вә*

*Пакь Сөннәт өйрәнүләре мәркәзенең баш мөдире*

*29 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Мигъраҗ кичәсе

Барлык мактау, хәмде-сәналәр дөньяларны барлыкка китерүче, барчабызны да һәрдаим нигъмәтләндереп торучы, һәр гамәлебезне белүче вә аның өчен гадел рәвештә хөкем итәчәк, Үз рәхмәтенә ирешүчеләрне мәңгелек җәннәткә һәм адашканнарны җәһәннәмгә кертәчәк Бөек зат – Аллаһыга булсын!

Соңгы пәйгамбәр итеп иңдерелгән, дөньяга Раббыбызның сүзләрен вә шәригатен тараткан, җәннәт ишеген беренче булып ачачак вә үзенең өммәтен – мөселманнарны беренчеләрдән булып анда алып керәчәк сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә салаватлар булсын! Шулай ук барчаларыбызга да Аллаһы Тәгаләнең сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын!

Раҗәб аеның 26 нчы көненнән 27 нче көнгә каршы киче – Мигъраҗ кичәседер. Быел икесеннән өченче апрельгә каршы төндә мөселманнар ислам тарихындагы гаҗәеп вакыйганы – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең төнге сәяхәтен һәм аның күккә ашуын билгеләп үтәчәк.

«Мигъраҗ» сүзе «күккә ашу» дигән мәгънәне белдерә. Аллаһының бөек кодрәте белән, пәйгамбәребез Мөхәммәд бу фазыйләтле, изге кичтә гадәти булмаган сәфәр кыла.

Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең күккә ашуы – мигъраҗы турында Аллаһы Тәгалә олуг нигъмәте Коръәни Кәримендә болай дип әйтә:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

**«Үзенең колы Мөхәммәдне бер кичтә Мәккә шәһәрендәге мәсҗед Харамнан Кодес шәһәрендәге мәсҗед Әкъсага кайтаручы Аллаһы Тәгаләне һәр кимчелектән пакь дип белегез! Без Кодес шәһәренең тирәсен бәрәкәтле кылдык, Мөхәммәдне шулай кодрәтебез белән йөрттек, гаҗәп галәмәтләребезне күрсәтер өчен, әлбәттә, Аллаһы һәр сүзне Ишетүче вә һәр нәрсәне Күрүчедер».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:1

Пәйгамбәребез Кодес (Иерусалим) шәһәренә, ягъни Бәйтел мөкатдәскә барганнан соң, Әкъса мәчетендә ике рәкәгать намаз укый. Гадәти булмаган сәфәрнең шушы өлешенә «Исра» диелә.

Мигъраҗ кичәсе нинди кичә ул? Ни өчен бу бәйрәмне 2 миллиардка якын мөселман кардәшләребез шатланып, дулкынланып каршы ала? Алда әйтеп үткәнчә, мигъраҗ – ул «күккә ашу» дигән мәгънәне аңлата һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышында ул иң олуг могҗиза булып исәпләнә.

Пәйгамбәрлекнең 10 нчы елында Мөхәммәд галәйһиссәламне тәрбияләп үстергән агасы Әбү Талиб үлеп китә, аңа таяныч булган хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә дә вафат була һәм шуннан соң да Мөхәммәд галәйһиссәламгә бик күп авырлыклар күрергә туры килә. 621 елда бер төнне Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кичен Кәгъбәдә гыйбадәт кылган вакытта, Җәбраил фәрештә Бурак дигән ат (оча торган җан иясе) белән килеп, аңа: «Әй Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә беркемгә насыйп итмәгән шәрәфне сиңа насыйп итте. Сине янына чакыра», – дип әйткән. Һәм канатлы тылсымлы атка атландырып, күз ачып йомганчы, Гарәбстаннан

изге Кодес шәһәрендәге Әл-Әкъса мәчетенә яшен тизлегендә китереп җиткергән[1].

Әл-Әкъсага җыелган барлык пәйгамбәрләр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә оеп намаз укыйлар. Соңрак Җәбраил Мөхәммәд галәйһиссәламнең алдына өч савыт китереп куя. Берсенә – су, икенчесенә – сөт, өченчесенә хәмер салынган була. Мөхәммәд галәйһиссәлам сөт салынган савытны ала, фәрештә: «Әй Мөхәммәд, син вә өммәтең дөрес юлда! Исерткеч эчү – харам», – дип кычкырып җибәрә. Шул мизгелдә күктән яктылык баскычы төшерелә һәм бу баскычтан Мөхәммәд галәйһиссәлам вә фәрештә күккә күтәрелә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм 7 кат күк ишеге аша үткәндә һәр капуста үзенә кадәр җир йөзенә килеп киткән пәйгамбәрләр белән очраша. Күкнең беренче капусы ачыла, күрәләр: алар алдында атабыз Адәм галәйһиссәлам – сәлам бирешәләр. Адәм уңга карый да, елмая, шатлана, чөнки уңдагылар – изгеләр, тәкъвалар, әүлияләр. Сулга карый да, өзелеп-өзелеп елый, кайгыра. Сулдагылар – залимнәр, кяферләр, гөнаһлылар. Күкнең икенче катында Гайсә вә Яхъя галәйһимуссәлам белән күрешеп бер-беренә изге теләкләр әйтәләр. Күкнең өченче катында тулган ай кебек күркәм Йосыф галәйһиссәлам белән сәлам алышалар. Дүртенче кат күктә Идрис галәйһиссәлам белән күрешәләр. Күкнең бишенче катында Муса галәйһиссәламнең ир туганы Һарун пәйгамбәр галәйһиссәлам белән очрашалар. Күкнең алтынчы катында Муса галәйһиссәлам белән күрешәләр, үзе намаз укый, үзе елый – өммәтендәге Бәни Исраил кавемендә иманнарына гөнаһ катыштырган бәндәләр өчен Аллаһы Тәгаләдән гафу үтенә. Күкнең җиденче катында Әл-Бәйтел Мәгъмур бинасына аркасы белән сөялеп утырган Ибраһим галәйһиссәлам белән сәламләшәләр. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу мөкатдәс бинага көн дә 70 мең фәрештә кереп, гыйбадәт кылганнарын күрә. Бу бинага бер кергән фәерштә бүтән анда әйләнеп кайт-

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан, № 429

мый. Җәбраил фәрештә күкнең иң өске катына җиткәч: «Миңа куелган чик шушында бетте, алга таба барырга рөхсәт юк», – дип әйтә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәфәрне үзе генә дәвам итә. Расүлебез галәйһиссәлам җәннәт белән җәһәннәм галәмәтләрен күрә, Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү бәхетенә ирешә.

Мигъраҗда Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә хөрмәтле булуда ике җәядән аткан ук микъдары якын булды. Әле моңа кадәр бер пәйгамбәрнең дә бу кадәр якын булганы булмады. Хәдистә болай дип әйтелә:

«Шуннан соң Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: «Әй, Мөхәммәд, Мин сине Үземә дус иттем, Ибраһимны хәлилем иттем. Синең белән, Муса белән сөйләштем, ләкин сиңа өстенлек бирдем, синең өммәтеңне изге өммәт иттем. Әй, Мөхәммәд, әй, хәбибем, Мин сиңа биргән бүләгемне сакла, шөкер кылучылардан бул».

Аллаһы хозурына баргач, Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Әт-тәхиййәтү лилләәһи вәссаләвәтү вәт-таййибәәт», ягъни «тел гыйбадәтләре, тән гыйбадәтләре, мал гыйбадәтләре – һәрбарчасы да Аллаһы Тәгалә өчен», – дип хәмед әйтә. Аллаһы Тәгалә бераздан: «Әс-сәләмү галәйкә әййүһән-нәбиййү вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү», – дип җавап бирә, ягъни «Әй, Пәйгамбәребез, сиңа Аллаһы Раббыңның сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын». Моңа җавап итеп Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Әс-сәләмү галәйнә вә галәә гибәдил-ләһис-салихиин», ягъни «Сәлам безгә дә һәм Аллаһы Тәгаләнең һәрбер изге бәндәсенә булсын», – диде. Шуннан соң фәрештәләр: «Әшһәдү әл-ләә иләәһә илләллааһ вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү вә расүлүһ» ягъни «Шәһадәт бирәбез Аллаһы Тәгалә барлыгына вә берлегенә, Мөхәммәд галәйһиссәлам Аллаһының Расүле вә Илчесе икәнлегенә», – дип әйтәләр.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Бу сүзләрне без барыбыз да намазда, ягъни кагъдәдә, «Әт-тәхият»кә утыргач әйтәбез. Без өч затның:

Аллаһы Тәгаләнең, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең һәм фәрештәләрнең әйткән сүзләрен кабатлыйбыз, шуңа күрә хәдис-шәрифтә: «Намаз – мөэминнең мигъраҗы», – дип әйтелгән. Димәк, намаз укыган һәр мөселман Аллаһы белән сөйләшә, Аңа мөрәҗәгать итә, Аннан ярдәм сорый, Аңа якыная. Шундый олуг бәхеткә көн саен биш тапкыр ирешә.

Әйткәнебезчә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу төнге сәфәрендә җәннәт вә җәһәннәмне үз күзләре белән, җаны, тәне вә гакылы белән күргән. Ул җәннәттә булган мөэмин-мөселманнарның кабатланмас җәннәт бакчаларында торуларын һәм җәһәннәмдә гөнаһлы бәндәләрнең коточкыч газаплануларын тамаша кылган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам өммәте өчен Аллаһыдан гафу үтенеп: «Йә, Раббым, миңа өммәтемне җәннәтле итә торган бер гыйбадәт бир», – дип сораган. Аллаһы Тәгалә: «Тәүлеккә 50 вакыт намаз укысалар, өммәтең җәннәтле булыр», – дип әйткән. Пәйгамбәребез шул хәбәрне ишетә дә, сөенеп, китеп бара. Кайтканда Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Муса галәйһиссәлам очрый һәм киңәш биреп: «Син Аллаһы хозурына кабаттан бар, синең өммәтең бит кәсеп итә, эшли, гаиләләренең тормышын алып барасылары бар, җирдә яшиселәре бар, алар 50 вакыт намазны үти алмасалар, җәннәткә керә алмаслар. Аллаһы Тәгалә хозурына барып, киметүен сора», – дип әйтә. Пәйгамбәребез Аллаһы хозурына кабат бара. Раббыбыз илле вакыт намазны кимета. Пәйгамбәребез Аллаһы хозурына кабат-кабат барып, намазны киметүен сорый. Шул рәвешле, 9 мәртәбә барганнан соң, намаз бишкә калдырыла.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм соңгы мәртәбә Муса галәйһиссәлам белән күрешкәч, Муса: «Аллаһы Тәгалә намазны бер вакытка гына калдырсын», – дип сорарга киңәш итә. Пәйгамбәребез: «Инде мин оялам, кабат бармыйм», – дип җавап кайтара. Шушыннан соң Аллаһы Тәгалә: «Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәламнең

өммәте үз вакытында биш вакыт намаз укыса, 50 вакыт намаз укыганның савабын алыр», – дип әйткән.

Мигъраҗ кичәсендә Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мөхәммәдкә өч олуг бүләк тапшыра:

1. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Кыямәт көнендә үз өммәтен яклау хокукы бирелә (шәфәгать).

2. «Бәкара» сүрәсенең ахыргы ике аяте бирелә (285-286 аятьләр).

3. Биш вакыт намаз фарыз кылына.

Мигъраҗ – Аллаһыга якын булуның иң өстен дәрәҗәседер. Билгеле булганча, могҗиза кылу мөмкинлеге – пәйгамбәрлекнең шартларыннандыр. Аллаһыга һәм Пәйгамбәргә ышанган кеше, Пәйгамбәребезнең могҗизаларына да ышанырга тиеш. Мигъраҗ – Мөхәммәд Пәйгамбәребезнең иң зур могҗизаларының берседер.

Кардәшләрем! Мигъраҗ кичәсен мөселманнар, гадәттә, гыйбадәттә, изгелектә үткәрә. Бу көнне укылган намазлар, тотылган ураза аеруча саваплы булып санала.

Аллаһы ризалыгы өчен дип, Мигъраҗ кичәсе алдыннан өч көн ураза тотсак, әлбәттә, бик күркәм эш булыр иде. Үзебезнең Аллаһы Тәгалә каршысында кылган гөнаһларыбызга тәүбә итеп, истигъфарны күбәйтеп: «Йә, Раббым, гөнаһларымны ярлыка. Йә, Раббым, уразаларымны кабул ит», – дип, Аллаһы ризалыгы өчен барчабыз да, ким дигәндә, өч көн нәфел уразалары тотыйк. Әлбәттә, Раҗәб аенда бер генә көн ураза тотуның да әҗере бик күп, дигән Пәйгамбәребез бер хәдисендә. Раҗәб аен, Мигъраҗ кичәсен каршыларга насыйп иткән икән, без аны уразага кереп, гыйбадәттә, күркәм итеп үткәрсәк хәерле булыр.

Аллаһы Тәгалә барчабызның да калган гомерләрен хәерле гомерләрдән кылып, хәерле сәламәтлекләр биреп, Аллаһы Тәгалә кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп итсә иде. Аллаһы Тәгалә күңелебезгә күркәм сабырлыклар биреп, фарызларын

үтәүгә тырышлык куярга ярдәм итсә иде. Бу дөньядан үткәндә: «Ләә иләәһә илләллааһ Мөхәммәдүр Расүлуллаһ», – дип Аның хозурына барып, Аллаһының җәннәтләрендә дә очрашуларыбызны насыйп итсә иде.

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

*5 апрель вәгазе,*

*Раҗәб аеның 29 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Галимнәр, гыйлем турында

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең хәбибе һәм хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Борынгыларыбыз болай дип әйтеп калдырганнар:

Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,
Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул.
Белмәде һөнәрне гыйлемсез кеше,
Булмады аңарда бәхетнең эзе.

Дөрестән дә, бу дөньяда нинди генә күренеш булмасын, һәрберсе гыйлемгә бәйле. Ничә төрле һөнәр булса, шул һөнәргә өйрәтә торган бик күп уку йортлары да бар. Гыйлемле кеше – һөнәр иясе. Шуңа күрә үз акылында булган һәрбер кешегә гыйлем алу фарыз итеп куелгандыр да. Дөньяда акны карадан, яхшыны начардан аера белү өчен дә гыйлем кирәк.

Мөхтәрәм җәмәгать! Гыйлем сүзе Коръәндә 70 тән артык урында кабатланып килә. Аллаһы Тәгалә изге Коръәндә болай дип әйтә:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ

**«Әйт син аларга: «Белгән белән белмәгән бер булырмы?»**

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:9

Кеше һәрвакыт бер-берсенә каршы булган сыйфатлар арасында яши: комсызлык һәм юмартлык; батырлык һәм куркаклык; тәкәбберлек һәм тыйнаклык; саранлык һәм исраф итү... Кеше бу әйберләр арасында гомере буе яшәргә мөмкин. Һәм бары тик хакыйкый гыйлемгә ия булган кеше генә начар сыйфатларның да, яхшы сыйфатларның да асыл мәгънәсенә төшенә ала. Ул шул гыйлеменә таянып, үзенең дөньясын кора, планнар төзи, яши, гыйбадәт кыла.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәлләм кешелек өчен дә, җеннәр өчен дә расүл иде. Ул пәйгамбәрлек чоры дәвамында сәхабәләргә дә, җеннәргә дә динне аңлаткан. Кайбер көннәрдә сәхабәләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне югалта торган булганнар. Ул кайтып: «Мин җеннәр кавеменә динне өйрәттем. Мин аларга да пәйгамбәр буларак җибәрелдем», – дип әйтә торган була.

Шулай ук, барыбыз да Җәбраил турындагы хәдисне беләбез. Анда Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребезгә дүрт төрле сорау бирә. Ул киткәч, Пәйгамбәребез сәхабәләренә: «Бу – Җәбраил галәйһиссәлам иде. Ул сезгә сезнең динегезне өйрәтер өчен килде», – дип җавап кайтара. Күрәбез, ислам дине дә нәрсәнедер күреп, шуны кабатлауга гына корылмаган. Ягъни Пәйгамбәребез: «Сәхабәләрем, минем арттан гына кабатлагыз, мин эшләгәнне эшләгез», – дип кенә әйтмәгән. Ул сәхабәләренә вәгазьләр, дәресләр биргән. Гомәр бине Әл-Хаттаб: «Пәйгамбәребез Ислам дине барлыкка килгәннән алып, Кыямәт көненә кадәр ни булачагы турында, шулай ук Кыямәт көне, җәннәт һәм җәһәннәм әһелләренең үз урыннарына урнашканчы, ни булачагы турында сөйләп бирде»[1], – дип әйтә. Әбү Дәрда: «Пәйгамбәребез безгә барлык фәннәр турында да сөйләде һәм кошларның һавада ничек очуларына кадәр аңлатып бирде», – дип әйтә.

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

Дөньяда акны карадан, яхшыны начардан аера белү өчен дә гыйлем кирәк, дип әйттек. Әмма дөрес гыйлем аламмы икән, дип йөрүчеләр дә бардыр. Чыннан да, безнең гыйлемебезнең дөреслеккә туры килгәнен кайдан белергә? Пәйгамбәребез, сәхабәләр заманы күптәннән артта калдылар бит. Бу очракта без үзебезнең галимнәребезгә мөрәҗәгать итәбез. Хәдисләрдә: «Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары», – дип әйтелә. Дөрестән дә, пәйгамбәрләр дирһәм дә, динар да калдырмадылар, мирас итеп алар гыйлем калдырдылар. Һәм шул гыйлемне бүгенге көнгә кадәр алып килүче кешеләребез – галимнәребез. Бүгенге көндә, Аллаһыга шөкер, урта, югары дәрәҗәдәге мәдрәсәләребез, магистратураларыбыз бар. Кайбер фәннәр буенча 10ар ел укыта торган уку биналары да бар. Болар барысы да Ислам динендә гыйлемле булуның әһәмияте турында сөйли.

Инде без – мәхәлләнең гади мөселманнары гыйлемне кайдан алырга тиеш соң? Камазда йөргәнче иң башта аны йөртергә өйрәнәләр. Экономист булыр өчен иң башта икътисад бүлегендә гыйлем алалар. Теш сызласа, теш табибына, берәр төрле җиһаз ясыйсы килсә, балта остасына барабыз. Шуның кебек, дини сорауларга җавапларны белер өчен, мәхәллә-мәчет имамнарына барырга кирәк. Һәрбер имам (бездә аларны күбрәк мулла дип йөртәләр) – мәдрәсә тәмамлаган кеше.

Фарсы телендә «мулла» — «дин гыйлеме белгече, ислам дине әһеле». Мулла сүзе олылап эндәшү мәгънәсенә дә ия. Шулай ук Себер татарларында мулла сүзе укыган, укымышлы мәгънәсендә дә йөри. Ә имам сүзе «әмәмә», ягъни алда торучы сүзеннән чыккан. Ул намазда гына алда тора дигәнне аңлатмый, белем дәрәҗәсе ягыннан да алда тора. Шуңа күрә дин буенча берәр сорау туса, без үзебезнең мәхәлләбезгә караган имамнарыбыз янына барып сорарга тиешбез.

Шулай ук Коръәндә:

يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ ۚ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ

**«... Аллаһы Тәгалә сезнең арадан иманлыларның һәм гыйлем ияләренең дәрәҗәсен арттырыр. Аллаһы бөтен кылган гамәлләрегезне белеп тора»,** – диелгән.

«Мүҗадәлә / Бәхәсләшү», 58:11

Кайчакларда без имамнарның теге яки бу гамәлләре белән килешмәскә мөмкинбез. Ник? Үзебезгә ошамаганга. Тыйб гыйлеме булмаган кеше гомере буе табиб булып эшләгән кеше янына килеп, аны өйрәтә башласа, ни булыр иде? Әлбәттә, ул кеше үзенең хаксызлыгын аңлап, гафу үтенер иде. Шулай ук авылларда гомере буе агроном булып эшләгән кешегә шәһәрдә туып үскән, авыл турында берни дә белмәгән кеше берәр нәрсә өйрәтсә, шулай ук көлке генә булыр иде. Шуның кебек мәдрәсәдә гыйлем алып, гомере буе мәчеттә эшләгән имамнар – шулай ук үз эшләренең осталары булып саналалар. Шәригатьтә гыйлемсез кылырга ярамый торган бик күп гамәлләр бар. Коръәндә дә белмәгән нәрсәләрне белгән кешеләрдән сорагыз, дип юкка гына әйтелмәгәндер.

Гыйлемне һәр кеше алырга тиешме, әллә инде имамнар гынамы? Гыйбадәтләр төренә карап, гыйлемне дә шулай бүлеп була. Әгәр кеше фарыз намазларын укырга тели икән, аңа бу намазны дөрес укыр өчен билгеле бер күләмдә гыйлем кирәк булачак. Ягъни бу иң аз гыйлем дип алыйк. Шуның кебек, һәрбер гыйбадәт турында кешедә иң аз булса да гыйлем булырга тиеш. Ә инде көнкүреш мәсьәләләргә килгәндә, аларны имамнан гына сорап чишеп була икән, димәк, ул гыйлемне алу бу кешегә тиеш булмый.

Аллаһыга шөкер, гыйлем бүгенге көндә үзе безнең арттан йөри. Кибетләрдә киштә тулы китаплар, өйләребездә интернет бар. Һәр район-

да диярлек мәдрәсләр эшләп килә. Китапларны компьютерда язып, 1000 тираж белән чыгара алабыз. Элек бу мөмкинлекләр булмаган, бер китапны бик күп кеше күчереп яза торган булган. Бервакыт хәзрәтебез Әбү Хәнифә рахимәһуллаһ бер кешенең бик вак язу белән дәрес язганын күрә. Ул аңа: «Ник син шулай вак язасың? Әгәр картаймыш көннәреңә кадәр җитсәң, син кайгыга батачаксың, вафат булсаң, сине шелтәлиячәкләр», – дип җавап кайтара. Бүген күзлекләр, яки зур шрифтлы китаплар да була ала. Ул вакытта бездәге кебек чаралар булмаса да, гыйлем ягыннан алар өстенрәк торалар.

Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә дә гыйлемне яратырга, аны алырга һәм калганнарга да таратырга насыйп әйләсә иде. Әмин!

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

# Сорау-җавап

# Җеназа мәсьәләләре

## Мәет юу

Юу өчен мәетне нинди дә булса хуш ис белән эшкәртелгән махсус тагаракка салалар, аның гаурәтен материя кисәге белән каплыйлар һәм киемнәрен салдыралар[1].

Моннан соң, авызын һәм борынын чайкамыйча гына, тәһарәт алдыралар. Башын һәм сакалын әйбәтләп юалар. Аннары сул якка салып уң ягын юалар, уң якка салып сул ягын юалар. Моны тәмамлагач, мәетне утыртып җиңелчә генә эчен сыйпыйлар, әгәр дә нәҗесе чыкса, аны юалар. Моннан соң бар тәненә хуш исле әйбер кушылган су салалар, аннары корытып сөртәләр һәм гаурәтен каплаган материяне корысына алмаштыралар. Мәетне юганда суга сабын һәм хуш исле әйберләр кушарга рөхсәт ителә[2].

## Мәетне кәфенләү

Ирләр кәфене өч өлештән – изар, камис һәм лифәфәдән тора. Изар һәм лифәфә – кеше буеның башы ягыннан да, аягы ягыннан да 30ар см озынрак материя кисәкләре. Камис – муеныннан алып үкчәсенә кадәр ике озынлыктагы материя. Камисның уртасы Т хәрефе сыман кисеп куела. Өч кат кәфенләү мөмкинлеге булмаса, изар һәм лифәфә белән чикләнү дә җитә. Сәбәпсез рәвештә ике кат кына чорналса – мәкруһ гамәл булыр[3].

---

1 Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр мәетне хуш исле сумала яндырып исләндерергә уйласагыз, бу так рәвештә башкарылырга тиеш», – дип әйткән (Әл-Хәким).

2 Өмме Гатыядән радыяллаһу ганһә риваять кылына: «Пәйгамбәр галәйһиссәлам без аның кызын юганда килеп керде һәм: «Аны садра (лотос) кушылган су белән өч, биш кат яки күбрәк мәртәбә юыгыз, соңыннан камфара яки башка шуңа охшаш әйбер кушыгыз», – диде (Мөслим).

3 Габдулла бине Гамер бине Әл-Гас радыяллаһу ганһе әйткән булган: «Мәетне камис, изарга, өченче катында лифәфәгә чорныйлар. Әгәр дә бер кат тукымадан башка берни булмаса, шуңа төрәләр» (имам Мәлик).

Кәфен өлешләрен түбәндәге тәртиптә җәеп куялар: башта лифәфә җәелә, аның өстенә изар, ә аннары – камис куела. Юылган мәетне башын камисның Т рәвешле кисеменә туры китереп салалар, башын кигезәләр һәм камисның калган өлеше белән үкчәсенә кадәр каплыйлар. Шуннан соң изар һәм лифәфәгә урыйлар. Ураганда һәрвакыт уң яктан башлыйлар. Кәфенлек сүтелмәсен өчен, аны баш очыннан, аяк табаныннан һәм уртадан бәйләп куялар.

Хатын-кыз кәфенлеге биш өлештән: дирга (бөркәнчек), изар, лифәфә, химар (ахирәт күлмәге) һәм хиркадан тора. Дирга ирләрнең камис дип аталган өлеше кебек. Химар дигәне – өч терсәк буе материя. Хирка – күкрәгеннән ботына кадәрле материя кисәге. Хатын-кыз кәфенен ирләрнеке сыман җәяләр. Юылган мәетне диргага салалар, башын Т сыман кисем аркылы, дирганың калган өлеше белән гәүдәне муеннан алып үкчәсенә кадәр каплыйлар. Шуннан соң чәчләрен ике толым итеп үрәләр, күкрәгенә салалар, хирка белән каплыйлар. Шуннан соң чәчләрен химар белән каплыйлар, аннары изар һәм лифәфә белән чорныйлар[1]. Шулай ук, чишелмәсен өчен, өч урыннан бәйләп куярга мөмкин.

Кәфенләү алдыннан ирләрнең дә, хатын-кызларның да кәфеннәрен хуш исле әйбер белән эшкәртәләр.

Мәетнең чәчен тарамыйлар да, алмыйлар да, тырнагын да кисмиләр.

Кәфенләгәннән соң мәетне өйдән алып чыгу алдыннан, җеназа намазы уку өчен имамга һәм мәрхүмнең туганнарына аның янәшәсендә утырышырга кирәк. Аннары имам кыскача вәгазь сөйли, вафат булган кеше рухына дога кылу кагыйдәләре турында нәсыйхәт бирә. Гореф-гадәт буенча барысы да җәмәгать белән эчтән генә йөз тапкыр тәһлил (Ләә иләһә илләл-лаһу) әйтәләр, аннары имам «Әл-Мүлек» сүрәсен укый һәм үлгән кеше хакына кычкырып дога кыла.

[1] Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыны Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә әйткән булган: «Мин Расүлуллаһның кызы Өмме Көлсемне кәфенләүдә катнаштым. Пәйгамбәр безгә иң элек биргән тукыма кисәге хирка иде, аннан дирганы һәм химарны, иң соңыннан лифәфәне бирде» (Әбү Давыдта китерелә).

## Мәетне җирләү

Мәетне тиз алып баралар, ләкин йөгермиләр. Күтәреп баручылар алмашырга теләсә, алдан уң яктан башлыйлар. Сәгать теленә каршы юнәлештә алмашалар. Мәетне һәрвакыт аягы белән алга таба каратып алып баралар.

Зиратка килеп җиткәч, утырырга рөхсәт ителә, әмма җеназа куелганчыга кадәр утыру – мәкруһ.

Кабернең тирәнлеге кеше буеның яртысыннан ким булырга тиеш түгел, ә тирәнрәк булса – ярый. Кабер кыйблага аркылы юнәлештә казыла. Кабернең иң астында кыйбла ягыннан ләхет алалар. Әгәр дә туфрак бик йомшак булса, ләхетне аска таба алсаң да ярый[1].

Мәетне ләхеткә куйганда түбәндәге доганы әйтәләр:

بسم الله وعلى ملة رسول الله

**Бисмилләәһи вә галә милләти расүлүүллаһи**

«Аллаһы Тәгалә исеме белән һәм Аллаһы Расүленең милләтенә муафыйк итеп».

Ләхет эчендә мәетне уң ягына салалар, кәфеннең бәйләгән урыннарын чишәләр, ә ләхетне нинди дә булса материал белән ябалар. Болардан соң каберне күмәләр, бу вакытта имам Коръәннән түбәндәге аятьне укый:

مِنْهَا خَلَقْنَاكُمْ وَفِيهَا نُعِيدُكُمْ وَمِنْهَا نُخْرِجُكُمْ تَارَةً أُخْرَى

**Минһәә халәкънәкүм вә фииһә нүгыйдүкүм вә минһә нүхриҗүкүм тәәратән ухраа**

> **«Без сезне җирдән яраттык һәм үтереп янә җиргә кайтарабыз, вә һәм Кыямәт булганда икенче мәртәбә сезне җирдән чыгарырбыз».**

«Та Һа», 20:55

---

1 Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ләхет алу безгә, чокыр казу – башкаларга», – дип әйткән (Тирмизи).

Кабер өстенә бераз туфрак өяргә ярый, ләкин ул бер карыштан (20-25 см) артык булмасын. Шәригать кабер өстенә цемент яисә гипс измәсе салуны тыя[1].

Идел-Урал төбәгендә таралган гадәт буенча, мәетне җирләгәннән соң имам яисә ул вәкаләт биргән зат «Әл-Мүлек» сүрәсен укый (кышкы салкын көннәрдә «Фәзкурүни...» дигән аятьне уку да җитә) һәм мәетне ярлыкауны сорый. Моннан соң, дүрт мөселман кабернең дүрт читенә басып берәр тапкыр «Фатиха» һәм унберәр тапкыр «Ихлас» сүрәләрен укыйлар. Шуннан соң кабер янында имам гына кала, укылган сүрәләрне үлгән кеше рухына багышлый һәм мондый сүзләр әйтә (исемнәре мисал буларак кына китерелә): «Әй, Габдрахман Әхмәт улы (Зөләйха Фатыйх кызы), синең яныңа ике фәрештә килеп сорарлар: «Синең Раббың кем?» дип, «Минем Раббым Аллаһы Тәгалә», – диярсең. Алар: «Синең пәйгамбәрең кем?» – дип сорарлар, син: «Минем пәйгамбәрем Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам», – диярсең. Алар тагын: «Синең динең нинди?» – дип сорарлар, «Минем динем – Ислам», – дип җавап бирерсең.

Бала тере килеш туып, аннары үлеп китсә, аңа исем кушалар, җеназа намазы укыйлар һәм җирлиләр. Әгәр бала үле туса, аны материя кисәгенә төрәләр һәм җеназа намазы укып тормыйча гына күмәләр.

Мөселман кешесен мөселман зираты саналмаган зиратта, ә мөселман зиратында Ислам динендә булмаган кешене җирләү тыела. Имам моны белергә һәм мәхәллә халкына да аңлатырга тиеш.

*Габдулла хәзрәт Әдһәмовның*

*«Дингә өндәү нигезләре һәм имамның вазифалары» китабыннан*

1 Җәбир радыяллаһу ганһе болай дип әйткән булган: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кабернең өстенә измә коюны, аның өстенә утыруны һәм аның өстендә берәр нәрсә төзүне тыйды» (Мөслим).

# Мөлкәт бүлешү әдәбе

Әмир кешеләр арасында мөлкәт бүлешү вакытында килеп чыккан бәхәсләр белән шөгыльләнүче кешене билгели һәм аңа эш хакын казнадан түли. Хөкем кылганда кешеләр бәхәсләре өчен аңа бернәрсә дә түләмиләр. Әгәр казнада бу кешегә түләү өчен акча булмаса, ул бәхәсләрен чишү өчен аңа мөрәҗәгать итүчеләрдән түләүне таләп итә ала. Кешеләрнең сайларга хокуклары булсын өчен мондый мөлкәт бүлүчеләр берничә булырга тиеш, ләкин бер бәхәстә берничә бүлүче булырга тиеш түгел.

Әбү Хәнифә бу казыйга хезмәте өчен түләү дәгъвага катнашучы шәрикләр арасында тигез итеп бүленә, диде. Аның укучылары әйтүенчә, түләүдәге өлеш мөлкәт бүлүдән алынган өлеш белән туры килеп (пропорциональ) үсәргә тиеш.

**Сорау:** Берничә кеше бер йортны мирас итеп алуга дәгъвалашсалар, судка алар нинди дәлилләр китерергә тиеш?

**Җавап:** Алар йорт хуҗасының үлемен раслаган дөрес документлар һәм шаһитлар китерергә тиеш булалар. Күчә торган мөлкәт мирас булып калган очракта, варислар бу мөлкәтне үз биләмәсенә алу хокукын белдерүләре дә җитә.

**С:** Сез мирас хакында әйттегез, әгәр берничә кеше бер йортны үз милекләренә алуга дәгъвалашсалар һәм бу йортны сатып алдык дисәләр, ләкин тиешле документларын күрсәтмәсәләр, нинди хөкем кылына?

**Җ:** Бу йорт аларның белешмәләре белән килешенеп, алар арасында бүленә.

**С:** Әгәр варисларның берсе булмаса, казый күчемсез мөлкәтне алар арасында бүлә аламы?

**Җ:** Әйе, бүлә ала, ләкин ул алдан ук бүлү вакытында булмаган варис урынына бер кешене билгеләргә тиеш һәм бу кеше аның мирастагы өлешен саклап торырга тиеш.

Шәрикләр йорт сатып алган очракта, шәрикләрнең берсе булмаганда бу йортны бүлү дөрес түгел.

**С:** Әгәр мирас судта булмаган варисның кулында булса, башка варислар бу мирасны бүлүне таләп итә алалармы?

**Җ:** Юк, таләп итә алмыйлар.

**С:** Бер шәрик уртак милекне башка шәрикләр булмаганда бүлүне таләп итә аламы?

**Җ:** Әгәр ул уртак милекнең күбрәк өлешен кулланса, ә калганнарының өлешләре әз булу сәбәпле, файда ала алмасалар, бу шәрикнең таләбе үтәлергә тиеш.

**С:** Товарны ничек бүлергә ярый?

**Җ:** Әгәр товар бер җенестән (төрдән) булса, бер шәрикнең таләбе буенча, әлеге товарны бүлү дөрес. Әгәр бер җенестән булмаса, шәрикләрнең бергә таләп итүләре буенча гына бүленергә тиеш.

**С:** Колны һәм кыйммәтле ташларны бүлергә ярыймы?

**Җ:** Әбү Хәнифә фикеренчә, кол һәм кыйммәтле ташлар бүленмиләр. Әбү Йосыф һәм Мөхәммәд фикеренчә, колны бүлергә ярый, ә кыйммәтле ташларны ярамый.

**С:** Тегермән һәм мунчаны бүлергә ярыймы?

**Җ:** Барлык шәрикләрнең дә таләп итүләре буенча гына бүленә.

**С:** Әгәр шәрикләрнең шәһәрдәге берничә бинасы уртак биләмәләрендә булса, аларны ничек бүләләр?

**Җ:** Әбү Хәнифә һәрбер бинаны бер шәрик тулысынча алырга тиеш, дип саный. Аның укучылары әйтүенчә, шәрикләрнең үз ихтыярларында, аларның һәрберсенең һәр йорттан билгеле бер өлешне үз биләмәсенә алырга хакы бар.

**С:** Әгәр аларның уртак биләмәләрендә бина һәм кибет булса, нишләргә?

**Җ:** Берсе бинаны, икенчесе кибетне үз мөлкәтенә ала.

**С:** Билгеләнгән кеше бүлүне ничек итеп башкарырга тиеш?

**Җ:** Билгеләнгән кеше бүленә торган мөлкәтне ачык итеп күрергә һәм үзе аны үлчәргә һәм бәясен белергә тиеш. Әгәр ике тарафның да хокуклары бер үк төрле булса һәм берничек тә килешә алмасалар, бәхәсне шобага салып хәл итәргә була. Акчаны бары тик бүленүчеләрнең ризалыгы белән генә бүлеп була.

**С:** Әгәр җирне бүлгәннән соң, юл яки сугару каналы, бүленүче ике тарафның берсенең җире аша үтсә, ә килешү төзегәндә бу хакта берни дә әйтелмәгән булса, нишләргә?

**Җ:** Әгәр каналны яки юлны шәригенең җиреннән алу мөмкинчелеге булса, канал яки юл хуҗасы бу юлны яки каналны кулланырга тиеш түгел. Әгәр мондый мөмкинчелек булмаса, бүлү килешүе кире кагыла.

**С:** Бүлүдә катнашучы үз өлешен тулысынча алмадым дисә, ә калганнары ул үзенекен тулысы белән алды, дисәләр һәм ике казый алар белән килешсә, бу казыйларның шаһитлыгы кабул ителәме?

**Җ:** Әйе, кабул ителә.

**С:** Бүлүдә катнашучыларның берсе, аңа тиешле мөлкәт башка берәүнең белмәсе булып чыгу сәбәпле, бүлгәндә хата килеп чыкты, дисә һәм шул ук вакытта ул үзенә тиешле мөлкәтне алуын расласа, аның гаризасы кабул ителәме?

**Җ:** Юк, әгәр ул үз сүзләрен документлар белән расламаса, кабул ителми.

**С:** Әгәр берәү: «Мин үз өлешемне тулысынча алдым, ләкин соңыннан аның бер өлешен бүлүдә катнашучы икенче берәү үзенеке итте», – дисә, ә җавап бирүче моны кире какса, нишләргә?

**Җ:** Җавап бирүче үз сүзләренең дөреслеген ант итеп расласа, аның сүзләре кабул ителә.

**С:** Әгәр бүлүдә катнашучыларның берсе: «Мөлкәттәге минем өлешемне шәригем бирмәде», – дисә, ә моңа кадәр үз өлешен тулысынча

алуга шәһадәт биргән булса, ә шәригe аның сүзләрен инкяр итсә, нинди хөкем кылына?

**Җ:** Икесе дә үз сүзләренең дөреслеген раслап ант итәләр һәм моннан соң бүлү килешүе юкка чыгарыла.

Әгәр дәгъвачы дөрестән дә мөлкәттәге өлешенең берникадәрен алган булса, бүлү килешүе үз көчендә кала, дип саный Әбү Хәнифә. Әбү Йосыф әйтүенчә, мондый бүлү юкка чыгарыла.

*Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрнинең*

*«Әт-тәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури» китабыннан*

# Үрнәк затлар

# Дүртенче тугры хәлифә – Гали радыяллаһу ганһе

**Тулы исеме:** Гали бине Әбү Талиб бине Габделмотталиб бине Хашим бине Габдеманәф Әл-Корәйши.

**Әтисе:** Әбү Талиб бине Габделмотталиб.

**Әнисе:** Фатыйма бинте Әсәд.

**Кушаматлары:**

1. «Әбү Хәсән» – Хәсәннең әтисе.

2. «Хәйдәр» – «арыслан». Хандәкъ сугышында күрсәткән батырлыгы өчен бирелә.

3. «Әбү Тураб» – «туфрак атасы». Әлеге кушамат түбәндәге вакыйгага бәйле.

Бер көнне Мөхәммәд галәйһиссәлам Галине эзләп Фатыйма радыяллаһу ганһә йортына килә. Фатыйма Галинең мәчеткә киткәнлеген әйтә. Мөхәммәд галәйһиссәлам Галине эзләп мәчеткә бара. Гали радыяллаһу ганһе мәчетнең бер читендә чапанына төренеп яткан була. Мөхәммәд галәйһиссәлам аның өстенә кунган тузаннарны кага-кага: «Әй, туфрак атасы, тор!» – дип әйтә. Шуннан соң аңа бу кушамат тагылып кала.

**Яшәгән еллары:** Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә пәйгамбәрлек килгәнче 10 ел элек, якынча 600 елда Мәккәдә туган. 661 елда Куфада вафат була.

**Хәлифәлек еллары:** 658 – 662 (4 ел 9 ай дәвамында хәлифә булып торган).

**Балалары:** уллары – Хәсән, Хөсәен, Габбас, Габдуллаһ, Җәгъфәр, Мөхәммәд бине Әл-Хәнәфия, Һиләл, Госман; кызлары – Зәйнәб, Өмме Көлсем, Рокыя, Рамлә.

## Ислам динен кабул итүе

Гали радыяллаһу ганһе беренчеләрдән булып Ислам динен кабул итә. Әбү Талибның картаюы сәбәпле көче, игътибарлыгы җитми башлагач, Галине Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәрбиягә ала.

Бер көне Гали радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез галәйһиссәлам белән Хәдичә радыяллаһу ганһәнең намаз укыганнарын күрә дә: «Әй, Мөхәммәд, бу нинди дин?» – дип сорый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Бу – Аллаһының дине. Ул бу динне сайлады һәм аны кешеләргә ирештерер өчен илчеләр җибәрде. Мин сине Аллаһыга гыйбадәт кылырга Лат белән Гоззәне калдырырга чакырам», – дип әйткән. Гали радыяллаһу ганһе аңа: «Минем бу хакта бер дә ишеткәнем юк, әтиемнән сорарга кирәк», – дип җавап кайтара. Аллаһының Илчесе үзенең сере таралуын теләми, шуның өчен дә ул Галигә: «Әй, Гали, әгәр Исламны кабул итмәсәң, моның турында беркемгә дә әйтмә», – дип үтенә. Гали ул төнне ислам дине хакында уйланып чыга, бу серне саклый. Аллаһы Тәгалә аның күңелендә Ислам диненә мәхәббәт уята. Иртә белән ул Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янына килеп: «Әй, Мөхәммәд, син миңа нәрсәне тәкъдим иттең?» – дип сорый. Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам аңа: «Син Аллаһының берлегенә, Аның тиңдәше юклыгына шәһадәт китерергә тиешсең», – дип әйтә. Шулай итеп, Гали радыяллаһу ганһе 10 яшендә Ислам динен кабул итә.

## Гали радыяллаһу ганһенең һиҗрәте

Мөхәммәд галәйһиссәлам мөселманнарга Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылырга боерганнан соң, һиҗрәт кыла алган бөтен мөселман Мәдинәгә күчеп бетәләр. Бары тик Әбү Бәкер һәм Гали радыяллаһу ганһүмнәр генә Мөхәммәд галәйһиссәламне калдырып чыгып китә алмыйлар.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә һиҗрәт кылыр-га теләгәч, иптәш итеп Әбү Бәкер радыяллаһу ганһене сайлый. Гали радыяллаһу ганһене исә әманәтләрен тапшырырга, йомышларын үтәргә вәкил итеп калдыра. Корәешлеләр Мөхәммәд галәйһиссәламне үтерергә дип өен чолгап алуларына карамастан, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, сөекле Расүлебез йортыннан гына түгел, ә Мәккәдән дә имин рәвештә чыгып китә. Гали радыяллаһу ганһе исә Расүлуллаһның киемнәрен ябы-нып, гомерен дә корбан итәргә разый булып, аның урынында ятып йо-клый. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа: «Әй, Гали, сиңа бернинди дә зарар ирешмәс. Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кыл да, рәхәтләнеп йокла», – дип әйтә. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, мөшрикләр аңа бернинди дә зыян китермиләр.

Расүлуллаһның әманәтләрен үтәгәч, ул үзе дә Мәдинәгә җәяүләп һиҗрәт кыла. Күп йөрүдән аяклары ярылып, канап бетә. Мөхәммәд галәйһиссәлам аны күреп, бик кызгана һәм аның өчен дога кыла.

## Гали радыяллаһу ганһенең тыйнаклыгы

Гали радыяллаһу ганһе сәхабәләр арасында иң тыйнакларыннан санала. Ул бөтен вөҗүден Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуга тапшыра. Аллаһы Тәгалә безгә бу тәнне рәхәт кичерү өчен түгел, бәлки гыйбадәт кылу өчен бирде дип, һәр әгъзасын гыйбадәт кылдырырга тырыша.

Ул беркайчан да тамагы туйганчы ашамый. Ашаган ризыгы да бик гади була. Моның турында аннан сорагач, ул: «Бу саранлык сәбәпле түгел, бәлки мин үземә җиткәнен генә һәм шөбһәсез ризыкны ашарга тыры-шам», – дип җавап кайтара торган булган.

Кием-салымына килгәндә, гадәттә ул эченә таш бәйләп йөргән. Шул таш киеменә ышкылып, киемен ерткан очраклар да булган. Шул вакыт-ларларда ул үзенең мәшһүр кылычын биреп, кием алган. Соңыннан, ак-часы булгач, кылычын яңадан сатып алган.

Ул кыска һәм ямаулы киемнәр кигән. Кайбер мөселманнарга ул: «Мин моны мөселманнар миңа иярсеннәр өчен һәм калеб хошугълы булсын өчен киям», – дип әйткән. Кышын исә җылы кием таба алмыйча, туңып йөргән.

## Гали радыяллаһу ганһенең казна малына игътибарлыгы

Гали радыяллаһу ганһе хәлифә булып сайланганнан соң да казнага зур игътибар бирә. Аның хәлифәлеге вакытында казнада мал арта.

Бер көнне казна сакчысы Гали радыяллаһу ганһене туктатып: «Әй, Гали, син безнең арабызда хөрмәткә лаеклы зат – хәлифә, ә үзеңнең киярге киемең дә юк. Мин сиңа казнадан бер күләм акча яшереп алып калдым, синең аңа хакың бар, өстеңә кием ал», – дип Галигә бирә. Гали радыяллаһу ганһенең моңа бик нык ачуы чыгып: «Син мине сатлыкҗаннардан күрәсең киләме? Үземне һәм гаиләмне утка кертергә телисеңме?» – дип акчаны кире казнага кайтара, ә сакчыны эшеннән азат итә.

Икенче бер вакыйгада, Гали булмаганда казнага бал китерәләр. Галинең кызы Өмме Көлсем бу балның бер өлешен ашый. Әтисе бу хәлне белеп, бик нык кайгыра һәм балның ашалган өлешенең кыйммәтен ике өлеш итеп кайтара.

Гали радыяллаһу ганһе шул рәвешле үзен, гаиләсен һәм үзенең кул астында булган һәр кешене харамнан сакларга тырыша.

## Гали кәррамәллаһу вәҗһәһунең гыйлемлеге

Гали радыяллаһу ганһе сәхабәләр арасында иң гыйлемле кешеләрдән санала, чөнки ул кече яшьтән үк Мөхәммәд галәйһиссәлам йортында тәрбияләнеп, аннан гыйлем ала. Ул үзе үк: «Миннән сорагыз, миннән сорагыз Аллаһының китабы турында. Мин кайсы аятьнең

иртән, кайсы аятьнең кич иңгәнен, барысын да беләм», – дип әйтә торган булган.

Аның гыйлемлегенә мисал итеп бер вакыйганы китерергә була: Гомәр радыяллаһу ганһенең хәлифәлеге вакытында бер хатын алты айдан бала таба. Бу хатынны зина кылуда гаепләп, җәзага тартырга телиләр. Гали радыяллаһу ганһе аларны туктатып: «Бу хатын баласын иң аз срокта тапты», – дип әйтә һәм Коръәннең түбәндәге аятен китерә:

> **«Без кешегә ата-анасына изгелек итәргә әмер иттек, аны анасы мәшәкать белән корсагында күтәрде вә мәшәкать белән тудырды, дәхи аны корсагында күтәрү вә тудыргач имезү утыз айдыр, хәтта үсеп куәткә ирешсә, кырык яшькә җитсә, әйтер: «Ий Раббым, миңа илһам бир, үземә вә ата-анама биргән һидаять вә ислам нигъмәтенә шөкер итүем өчен вә Син риза була торган изге гамәлләр кылуым өчен. Ий Раббым, балаларымны да исълах ит, бар да мөэмин булсыннар, йә Рабби, мин Сиңа кайттым вә мөселманнардан булып һәр әмереңә итагать иттем».**

«Әхкаф / Комлык», 46:15

## Гали радыяллаһу ганһенең дәрәҗәсе

Гали радыяллаһу ганһе сәхабәләр арасында иң югары дәрәҗәгә ирешүчеләрдән санала. Аның дәрәҗәсен түбәндәге мисаллардан күрәбез:

1. Дүртенче тугры хәлифә.

2. Исән чагында ук җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе.

3. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәрбиягә алган улы.

4. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең кызы Фатыйма белән никахлашып, аның кияве була.

5. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафат булгач аны юып кәфенләүче.

6. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм урынына әмир булып калучы (Тәбук сугышында).

7. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гали радыяллаһу ганһе хакында бик күп хәдисләр әйтеп калдыра. Шуларның мәшһүре: «Кем Галине сөйсә, мине сөйгән кебек булыр. Кем Галине дошман күрсә, мине дошман күргән кебек булыр».

## Гали радыялллаһу ганһенең гаделлеге

Гали радыяллаһу ганһе сәхабәләр арасында гадел, тугры кеше буларак таныла. Сәхабәләр аның гаделлеген белеп, үзләре аны казый, хөкемдар итеп күрәләр.

Гали радыяллаһу ганһе нинди генә авыр хәл булмасын, халык арасында тигезлек белән эш итәргә тырыша. Хөкем чыгарганда ул һәрвакытта да Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең киңәшенә таяна. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәр мәсьәләгә карата хөкем чыгарырга теләсәң, башта ике якны да тыңла, соңыннан гына хөкем ит», – дип әйтә торгани булган.

Гали радыяллаһу ганһенең гаделлегенә мисал итеп түбәндәге вакыйганы китерергә була:

Бер көнне Гали радыяллаһу ганһе үзенең калканын яһүди егетендә күрә һәм аның белән бергә казыйга барып: «Бу минем калканым. Мин аны аңа сатмадым да, бүләк итеп тә бирмәдем», – дип белдерә. Яһүди егете моңа җавап итеп: «Әйе, әйе. Ул аны миңа сатмады да, бүләк тә итмәде, ләкин ул минеке», – дип әйтә. Кызый хөкемне Гали радыяллаһу ганһе яклы чыгарырга тели. Ләкин Гали аңа: «Гадел хөкем ит!» – дип әйтә. Казый Гали радыяллаһу ганһедән дәгъвасына дәлил сорый. Гали исбатлый алмагач, казый хөкемне яһүди егете файдасына чыгара.

Яһүди егете бу хәлдән гаҗәпкә кала: ничек итеп хәлифә гади кеше белән хөкемләшеп, аңа оттыра ала? Соңыннан, «бу дин дөрестән дә хак дин», дип Ислам динен кабул итә һәм калканны хуҗасына кайтара. Гали радыяллаһу ганһе исә аның Ислам динен кабул итүенә сөенеп, калканын аңа бирә һәм шуңа өстәп ат та бүләк итә.

Гали радыяллаһу ганһе үзенең үтерүчеләре белән дә гадел була.

Габдрахман бине Мүлҗим исемле хавариҗлы Гали радыяллаһу ганһене үтерергә карар кыла һәм иң оста үтерүчеләрне бу эшкә чакыра. Аларның бары тик берсе генә моңа ризалаша. Алар Гали радыяллаһу ганһенең өеннән чыкканын саклап торалар. Гали радыяллаһу ганһе өеннән чыккач, аңа хәнҗәр белән һөҗүм итеп, каты җәрәхәтлиләр. Иптәшләре аны өенә алып керәләр. Галигә һөҗүм иткән кешеләрне тотып китергәч, ул аларны җәзага тартмый. «Нигә бу эшне эшләдегез?» – дип сорый. Габдрахман бине Мүлҗим: «Мин бу хәнҗәрне 40 көн кайрадым һәм Аллаһы Тәгаләдән бу хәнҗәр аша иң явыз кеше үтүен сорадым», – дип җавап кайтара. Гали радыяллаһу ганһе: «Мин ул явыз кешенең син булуына шикләнмим» һәм сәхабәләренә: «Әгәр мин үлсәм, аларны да үтерерсез. Әгәр исән калсам, үзем хөкем итәрмен», – дип әйтә.

## Гали радыяллаһу ганһенең Аллаһы юлында сугышуы һәм батырлыгы

Гали радыяллаһу ганһе тарихта Гали батыр исеме астында мәгълүм. Ул Тәбук сугышыннан кала, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам булган барлык сугышларда да катнаша. Тәбук сугышында Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны Мәдинә әмире итеп калдыра.

Бәдер сугышында Гали радыяллаһу ганһе гаскәр алдына чыгып сугыша һәм үзенең дошманын иң беренчеләрдән булып җиңә.

Өхед сугышында ул Мөхәммәд галәйһиссәламне якларга дип иң беренчеләрдән килеп җитә.

Хандәкъ сугышында мөшрикләрнең иң батыр сугышчысы Гамер бине Әбү Вәдд мөселманнарга якын килеп: «Кем минем белән сугышыр?» – дип әйтә. Аңа каршы Гали радыяллаһу ганһе чыгып: «Әй, Гамер, син вәгъдә иттең. Әгәр сине берәр корәешле ике әйбернең берсенә чакырса, син аларның берсен кабул итәрсең», – дип җавап бирә. Гамер бине Әбү Вәдд: «Әйткәнең дөрес», – ди. Гали радыяллаһу ганһе аңа: «Мин сине Исламга чакырым», – дип әйтә. Гамер үзенең дингә мохтаҗ түгеллеген белдерә. Гали радыяллаһу ганһе аны сугышырга чакыра. Бераз сугышканнан соң Гали Гамерне үтерә. Шул рәвешле, ул аны җиңеп, Хәйдәр исеменә лаек була.

Бәни Корайза сугышында Гали радыяллаһу ганһе байрак йөртүче була.

Хайбәр сугышында да Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа байракны тоттырып: «Бу байракны Аллаһы Тәгалә һәм Аның Илчесе яраткан кешегә бирәм», – дип әйтә.

## Гали радыяллаһу ганһенең хәлифәлеге

Баш күтәрүчеләр Госман радыяллаһу ганһене үтергәннән соң, хәлифә булырга Гали радыяллаһу ганһегә тәкъдим итәләр. Ул исә үз чиратында: «Мин сездән моны сорамадым һәм хәлифә булырга теләмим дә», – дип катгый рәвештә баш тарта. Ләкин Зөбәер бине Гаввам һәм Талхә бине Гобәйдуллаһ кебек олы сәхабәләр килеп, Гали радыяллаһу ганһегә: «Без синнән башка хәлифә булырга лаеклы кешене күрмибез. Син хәлифә бул», – дип үтенгәч кенә, ул хәлифә булырга ризалык бирә.

Гали радыяллаһу ганһе 656 елда (һиҗри белән 35 нче елда) хәлифәлеккә килә. Ул хәлифәлек эшен үзенә кадәр булган Гомәр һәм Госман радыяллаһу ганһүмнәр заманындагы тәртип буенча дәвам иттерергә тели, ләкин Госман радыяллаһу ганһене үтергәннән соң килеп чыккан мәшәкать аңа тыныч кына идарә итәргә бирми. Шам әмире Мөгавия

Галигә буйсынудан баш тарта. Ул Гали радыяллаһу ганһегә: «Иң элек Госманны үтерүчеләрне җәзага тартырга кирәк. Әгәр шулай итсәң, мин сиңа бәйгать бирермен», – дип әйтә.

Гали радыяллаһу ганһе белән Мөгавия арасында килеп чыккан низаг көннән-көн үсә. Бу каршылыкларга түзә алмыйча, Гайшә радыяллаһу ганһә Мәдинәдән чыгып китә. Мөгавия дә гаскәр белән чыга. Шул рәвешле, ике гаскәр бер-берсе белән очрашкач, арада булган фетнәчеләр яшерен рәвештә уклар җибәрәләр һәм ике гаскәр арасында сугыш чыга. Тарихта бу сугыш «Дөя сугышы» исеме астында мәгълүм.

Озакламый Мөгавия белән Гали арасында тагын бер бәрелеш була. Ул «Саффәйни сугышы» буларак мәгълүм. Бу ике сугышта 700 сәхабә шәһит китә һәм аларның күбесе Коръән-хафизлар була. Әлеге хәлләрдән соң Гали радыяллаһу ганһе Мөгавия белән килешүгә бара һәм Госманны үтерүчеләрне җәзага тарта. Тарихта алар хариҗилар исеме астында мәгълүм. Гали радыяллаһу ганһе аларны җәзага тартса да, Мөгавия барыбер аңа буйсынмый. Хариҗилар исә үз чиратында Галине үтерергә ант итәләр.

## Гали радыяллаһу ганһенең шәһит булып китүе

Гали радыяллаһу ганһе үзенең шәһит булып китәчәген белә, чөнки Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Син иң явыз кешеләр кулыннан китәчәсәксең», – дип әйткән була.

Гали радыяллаһу ганһе һәркөн кешеләрне иртәнге намазга уятып йөри. Хариҗилардан булган Габдрахман бине Мүлҗим аны үтерер өчен үзенең өлкәсендә булган иң оста үтерүчене таба. Ләкин ул кеше бу эшкә алынырга теләми. Габдрахман аңа: «Әгәр син Галине үтерсәң, сиңа җәннәт кенә була. Ул безнең абыйларыбызны, туганнарыбызны үтерде», – дигәч кенә ризалаша.Моның өчен ул хәнҗәрен үткенләп, агулап әзерләп куя.

Билгеләнгән көнне алар Гали радыяллаһу ганһене өеннән чыкканын көтеп торалар. Ул өеннән чыккач, үтерүче аңа һөҗүм итә, ләкин Гали радыяллаһу ганһе читкә китеп өлгерә. Икенче яктан Габрахман бине Мүлҗим һөҗүм итеп, аңа тирән җәрәхәт ясый.

Гали радыяллаһу ганһе иртәнге намазга бара алмый. Ул үзенең вафат булачагын белеп, улларына нәсыйхәтләрен әйтә. Сәхабәләр аннан: «Синнән соң хәлиф итеп Хәсәнне калдырыйкмы?» – дип сорагач, Гали радыяллаһу ганһе: «Бу минем эшем түгел», – дип җавап кайтара.

Гали радыяллаһу ганһе 63 яшендә шәһит булып китә һәм соңгы сүзләре Коръәннең түбәндәге аятьләре була:

**«Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аның җәзасын күрер. Вә берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер».**

«Зүллзиләт / Җир Селкенмәк», 99:7-8

# Гайшә бинте Әбү Бәкер

**Исеме:** Гайшә бинте Әбү Бәкер. Аллаһының Илчесе аны төрлечә атаган: Гайш, Мүәффәка (Бәхетле), Хүмәйра (Алсу йөзле), Шүкәйра (Ак йөзле) һәм Өмме Габдуллаһ.

**Туган елы, урыны:** Гайшә бинте Әбү Бәкер дүртенче (бишенче) пәйгамбәрлек елында Мәккәдә дөньяга килә.

**Әтисе:** Әбү Бәкер Әс-Сыддыйк.

**Әнисе:** Өмме Руман.

**Тормыш иптәше:** Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

## Гайшәнең гаиләсе

Күренекле ата-ана (әтисе – беренче мөселманнардан, әнисе – Гайшә туганчы ук Ислам динен кабул иткән итагатьле хатын була) гаиләсендә Гайшә яхшы холыклы, әдәпле булып үсә. Моннан тыш ул ике сәхабәдән дини тәрбия ала. Әсма исемле апасы белән бик яшьләй Ислам динен кабул итә.

## Пәйгамбәр галәйһиссәламнең Гайшәгә өйләнүе

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм еш кына дусты Әбү Бәкер гаиләсенең хәлен белергә бара торган булган. Гайшә аның күз алдында бөтерчек кебек тере һәм зирәк кыз булып үсә.

Хәдичәне югалтканнан соң Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенә урын таба алмый. Барысы да аңа ничек авыр булганны күрәләр, ләкин берсе дә аңа өйләнергә тәкъдим ясарга җөрьәт итми. Ә Хәүлә бинте Хәким аның янына килеп: «Әй Аллаһының Илчесе, син өйләнергә теләмисеңме? Теләсәң – гыйффәтле кызга, теләсәң – хатынга. Гыйффәтле кызга килгәндә, ул синең сөекле дустыңның кызы – Гайшә бинте Әбү Бәкер.

Икенчесе сиңа ышанган һәм ияргән – Сәүдә бинте Зәмга», – дип тәкъдим ясый. Пәйгамбәребез: «Аларны миңа яучыла әле», – ди.

Хәүлә бинте Хәким бу хәбәрне Әбү Бәкер йортына җиткерә. Кызның әтисе хәбәрне ишеткәч: «Кардәшенең кызына өйләнергә ярыймы?» – дип сораган. Аллаһының Илчесе: «Мин – аның кардәше, ул – минем кардәшем, без Исламда кардәшләр. Аның кызы минем хатыным булырга хаклы», – дип җавап биргән. Шуннан соң кызның әтисе ризалык биргән.

Яшь килен Пәйгамбәр мәчете янындагы Мөхәммәд галәйһиссәламнең йортына урнаша. Кияүгә чыгу белән Гайшә тормышында бернәрсә дә үзгәрми диярлек. Бары тик мәхәббәт һәм кайгыртучанлык кына өстәлә. Пәйгамбәр галәйһиссәлам яшь хатынның теләкләрен аңлый һәм аларны үтәргә тырыша. Аларның икесенең бергәләп хәбәшиләрнең сөңге белән уйнаганнарын карап торганнары мәгълүм. Шулай ук алар бергәләп спорт белән дә шөгыльләнгәннәр.

Гайшә радыяллаһу ганһәдән риваять ителә: «Бервакытны мин Аллаһының Илчесе белән сәфәргә чыктым. Ул чакта мин гәүдәгә бик үк таза булмаган яшь кыз идем. Мөхәммәд галәйһиссәлам кешеләргә: «Монда килегез», – дип әйтте һәм алар килделәр. Соңыннан ул миңа: «Йөгерү өчен бирегә кил», – диде. Шуннан соң мин аның белән йөгердем һәм алдан килдем. Ул миңа бернәрсә дә әйтмәде. Бераз үсеп гәүдәгә тазаргач, мин аның белән тагын сәфәргә чыктым. Бу юлы да Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләргә: «Монда килегез», – дип әйтте һәм алар килделәр. Соңыннан ул миңа: «Йөгерү өчен бирегә кил», – диде. Бу юлы йөгергән вакытта ул мине узды. Шуннан соң ул: «Бу теге юлы узганың өчен», – диде һәм көлде» (Имам Әхмәд).

## Гайшәнең күркәмлеге

Гайшә киңкүңеллелек, талымсызлык һәм юмартлык белән аерылып торган. Ачлык һәм ярлылыкка сабыр иткән, чөнки күп вакытта ат-

налар буе аның өендә мичкә ягылмаган, ягъни икмәк яки башка ризык пешерелмәгән. Пәйгамбәр галәйһиссәлам өендә су һәм хөрмә белән генә торганнар.

Гайшә бик юмарт булган. Үзе турында онытса да, мохтаҗлар турында беркайчан да онытмаган. Бервакыт ул ураза тоткан көнне аңа йөз мең дирһәм биргәннәр. Ул акчаны бүлгән дә, мохтаҗларга тараткан. Аның хезмәтчесе: «Ифтар кылыр өчен бер дирһәмгә генә булса да ит сатып ала алмадыңмыни син?» – дип сораган. Гайшә радыяллаһу ганһә аңа: «Әгәр дә син исемә төшергән булсаң, мин шулай эшләгән булыр идем», – дип җавап кайтарган.

Гайшә гыйлем алуга да зур игътибар биргән, Пәйгамбәр галәйһиссәламнең күп хәдисләрен һәм гамәлләрен истә калдырган. Аның гыйлеме турында сәхабәләр түбәндәге сүзләрне әйткәннәр: «Гайшәнең гыйлемен җыеп, аны башка хатын-кызлар гыйлеме белән чагыштырсаң, Гайшәнең гыйлеме өстенрәк булыр иде. Безгә нинди дә булса хәдис аңлашылмаса, без аның турында Гайшәдән сорый һәм һәрвакытта да җавап таба идек». Гайшә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән 2210 хәдис тапшырган.

## Гайшәнең өстенлеге

Гайшәнең Пәйгамбәр галәйһиссәламнең башка хатыннарына хас булмаган ун өстенлеге булган:

1. Пәйгамбәр галәйһиссәлам аннан башка бер гыйффәтле кызга да өйләнмәгән.

2. Гайшәне аклап Аллаһы Тәгалә аять иңдергән.

3. Җәбраил фәрештә аның ефәк тукымадагы сурәтен Мөхәммәд галәйһиссәламгә күрсәтеп: «Аңа өйлән, ул – синең тормыш иптәшең!» – дигән.

4. Алар Пәйгамбәр галәйһиссәлам белән бер савыттан госел коенганнар.

5. Гайшә аның алдында ятканда Пәйгамбәр галәйһиссәлам намаз укыган.

6. Гайшә белән булганда Пәйгамбәр галәйһиссәламгә вәхи иңгән.

7. Җәбраил фәрештә аңа сәлам җибәргән һәм ул – Пәйгамбәрнең җәннәттәге хатыны.

8. Пәйгамбәрнең башы Гайшәнең тезендә булганда Аллаһы аның җанын алган.

9. Пәйгамбәр галәйһиссәлам Гайшәнең чираты булган көнне җан тәслим кылган.

10. Пәйгамбәр галәйһиссәлам Гайшәнең өендә күмелгән.

## Гайшәгә яла ягу вакыйгасы

Гайшә радыяллаһу ганһә тормышында булган иң әһәмиятле һәм катлаулы вакыйга – аңа яла ягу вакыйгасы.

Һиҗри белән алтынчы елда мөселманнар Бәнү Мөстәликъ кабиләсенең үзләренә һөҗүм итәргә җыенганнарын ишеткәннәр һәм аларга каршы чыгарга уйлаганнар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәфәргә чыгар алдыннан, гадәттәгечә, шобага салган. Шобага бу юлы Гайшәгә төшкән. Мәдинәгә кайтып барганда гаскәр ял итәргә тукталган. Төн җиткәч, Гайшә үзенең хаҗәте белән читкә киткән. Кире килгәч, Гайшә мәрҗәне югалганын күреп, аны эзләргә китә. Мәрҗәнне тапкач, гаскәр торган урынга килсә, анда беркем дә булмаган.

Гаскәрдән калгач, кем дә булса кире әйләнеп кайтыр әле дип, Гайшә шул урында торуын дәвам иткән. Бераздан ул шул утырган җирендә йоклап та киткән. Гаскәр артыннан тикшереп баручы Сафуан бине Мугаттәл ниндидер кара нәрсә күреп, аның янына килгәч, моның Гайшә икәнлеген

күрә. Ул Гайшә радыяллаһу ганһәне дөясенә утыртып, гаскәр янына алып барып җиткерә.

Аллаһының Илчесе Гайшә радыяллаһу ганһәне исән-имин килеш күреп, тынычлана.

Пәйгамбәр галәйһиссәламнең дошманы Ибне Сәлүл, Гайшәне һәм Пәйгамбәребезне түбәнсетү өчен, әлеге форсатны кулланырга уйлый: Сафуан белән Гайшә зина кылганнар, дип сүз тарата. Бу хәбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә тиз барып ирешә һәм ул бу сүзләргә ышана. Бу хәлләрдән соң аның хатынына да мөнәсәбәте үзгәрә. Гайшә исә, салкын тию сәбәпле, нык авырый. Халык арасында үзе турында яман сүзләр таралганны ишеткәч, бик нык кайгыра, елый. Шундый авыр вакытында аның янына Пәйгамбәребез галәйһиссәлам килеп: «Әй Гайшә, миңа синең турыда фәлән-фәлән сүзләр килеп иреште. Әгәр дә син гөнаһсыз булсаң, Аллаһы сине аклаячак. Гөнаһ кылган булсаң, Аллаһыдан гафу сора һәм Аңа тәүбә ит. Әгәр бәндә гөнаһысын таныса һәм тәүбә кылса, Аллаһы аны ярлыкар», – дип әйтә. Гайшә Пәйгамбәр галәйһиссәламгә җавап бирүләрен үтенеп әти-әнисенә дә мөрәҗәгать итеп карый, ләкин алар Аллаһының Илчесенә нәрсә дип җавап бирергә дә белмиләр. Шуннан соң Гайшә радыяллаһу ганһә үзе җавап бирә: «Аллаһы белән ант итәм, мин сезнең әлеге вакыйганы ишеткәнегезне һәм аңа ышанганыгызны беләм. Әгәр дә мин үземне гаепсез дип әйтсәм, сез миңа ышанмас идегез. Мин сезнең өчен дә, үзем өчен дә Йосыфның этисе әйткәннән дә яхшырак сүз таба алмыйм:

> **«... миңа күркәм сабырлык кирәк! Сез тасвирлаган нәрсәләрдә Аллаһыдан ярдәм сорыймын».**

«Йосыф», 12:18

Күп та үтми, Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд галәйһиссәламгә түбәндәге аятьләрне иңдерә:

**«Сездән бер җәмәгать синең алдыңа: «Гайшә радыяллаһу ганһә зина кылды», – дип зур ифтира белән килде. Ий Мөхәммәд галәйһиссәлам вә Гайшә: сез бу ифтираны үзегезгә зарарлы дип уйламагыз, бәлки сезнең өчен хәерледер. Ул ифтира итүче җәмәгатьнең һәрберсенә кәсеп иткәннәре хәтле гөнаһ булачак. Алардан олуг ифтираны башлап сөйләүчегә ахирәттә олуг газап булыр. Ни өчен ул хәбәрне ишеткәч күңелегездән яхшы уй уйламадыгыз, мөэмин ирләр вә мөэминә хатыннар үзләре хакында яхшылыкны уйлаганнары кебек. Вә ни өчен бу хәбәр ачык ялган дип әйтмәдегез? Гайшә зина кылды диючеләр дүрт шаһит китерсәләр иде, әгәр дүрт шаһит китермәсәләр, алар Аллаһы хозурында ялганчылардыр. Әгәр сезгә дөньяда вә ахирәттә Аллаһының фазълы вә рәхмәте булмаса, әлбәттә, ий сез ялган сөйләүчеләр, төшкән гөнаһыгыз сәбәпле, сезне олуг газап тотар иде. Ул зина хәбәрен телегез белән каршы аласыз, аннары авызыгыз белән сөйлисез, ләкин ул хәбәр хакында белемегез, дәлилегез юк, янә сез ул җиңел эш, анда гөнаһ юк, дип уйлыйсыз, әмма Аллаһы хозурында ул зур эшдер, газабы каты булыр. Ул хәбәрне ишеткәч, ни өчен «андый сүзне сөйләү безгә лаек түгел, сөбеханаллаһ ошбу сүз бик олуг бөһтандыр», дип әйтмәдегез? Аллаһы сезне «әгәр мөэмин булсагыз, мондый сүзгә мәңге кайтмагыз вә сөйләмәгез», дип вәгәзьлидер. Аллаһы сезгә аятьләрен бәян итәдер, шаять вәгазьләнерсез, Аллаһы белүче вә хөкем итүче. Мөэминнәр арасында фәхеш эшнең фаш булуын сөйләүчеләргә дөньяда вә ахирәттә рәнҗетүче газап булыр, Аллаһы күңелләрдә булган нәрсәне белер, әмма сез белмәссез. Әгәр сезгә Аллаһының фазълы вә рәхмәте булмаса, әлбәттә, дөньяда газап кылыр иде, тәхкыйк, Аллаһы бәндәләренә йомшак вә рәхимле».**

«Нур», 24:11-20

## Гайшә радыяллаһу ганһәнең вафаты

Пәйгамбәр галәйһиссәламнең үлем авыруы көчәйгәч, ул хатыннарын йөреп чыкканда: «Иртәгә кемдә булам? Берсекөнгә кайда булам?» – дип сорашып, Гайшәнең чираты кайчан җитәсен белергә теләгән. Аның хатыннары Пәйгамбәрнең әлеге омтылышын күреп, үз чиратларын Гайшәгә биргәннәр. Гомеренең ахырын Пәйгамбәребез галәйһиссәлам яраткан хатыны янында үткәргән.

Гайшә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам белән тугыз гына ел яшәп калган. Үзе Мөхәммәд галәйһиссәламнең вафатыннан соң якынча илле ел яшәгән, башкаларны дингә, фикһка, әдәбиятка өйрәткән. Өммәтнең иҗтимагый һәм сәяси тормышында катнашкан.

Мөэминнәрнең анасы Гайшә бинте Әбү Бәкер һиҗри белән 57 нче елда, сишәмбе көн, Рамазанның унҗиденче төнендә 66 яшьтә вафат булган. Пәйгамбәр галәйһиссәламнең башка хатыннары белән бергә Бакыйгъ зиратында күмелгән.

# Бөек имам Әбү Хәнифә Ногман бине Сәбит Әл-Куфи

Әбү Хәнифә Әфганстанның төньягындагы затлы фарсы гаиләсендә, Габдел-Мәлик бине Мәрван хәлифәлек иткәндә туа. Аның бабасы исламны Гомәр бине Әл-Хәттаб хәлифә булган вакытта кабул итә. Әбү Хәнфәнең әтисе Куфа шәһәрендә ефәк һәм кием-салым белән сәүдә иткән, аның үлеменнән соң, әтисенең эше аңа күчә.

Әбү Хәнифә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе Куфага килгәч, аның белән очраша, фикһ гыйлемен Хаммад бине Әбү Сөләйманнан һ.б. өйрәнә. Ул тәкъва имам, бөек галим булган, әмирдән түләү алмаган, яшәү өчен сәүдәгәрлек белән шөгыльләнеп, ризык тапкан.

Әл-Хафис бине Хаҗәр: «Әбү Хәнифә табигыйннәрдән санала, аның белән яшәгән башка галимнәргә Сүриядән Әл-Әүзагый, Куфадан Әс-Сәүри, Мәдинәдән Мәлик, Мәккәдән Мөслим бине Халид, Мисырдан Әл-Ләйс бине Сәед керә», – дип әйткән.

## Әбү Хәнифәнең укытучылары

Әбү Хәнифә Мөхәммәд бине Йосыф Әс-Салихый Әш-Шәфигый искә алып үткән 4 мең табигыйннән белем алган. Аның иң бөек укытучыларыннан берсе Гамер бине Шәрахил Әл-Куфи, шулай ук Пәйгамбәребезнең 500 сәхабәсе белән очрашкан Әш-Шәгъби. Аның тагын бер укытучысы – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 200 сәхабәсе белән очрашкан Гата бине Әби Раббах була.

## Әбү Хәнифәнең укучылары

Әбү Хәнифәнең укучылары бик күп булган. Мәккәгә, Мәдинәгә, Димәшкъка, Басрага һәм бөтен Гарәп ярымутравына һәм башка җирләргә аның укучылары таралган.

Әс-Салихи: «Әбү Хәнифәнең якынча 800 укучысы булган һәм ул барысын да исемнәре белән атаган», – диде.

Әбү Йосыф: «Мин Әбү Хәнифә кебек хәдисләрне шәрехләүчене күрмәдем», – диде.

Габдуллаһ бине Давыд: «Мөселманнар намаз укыганда Әбү Хәнифәне догадан калдырмаска тиешләр», – дип әйткән.

Яхъя бине Насыр бине Хәҗиб: «Мин Әбү Хәнифәнең: «Мин хәдисләр сандыгын саклыйм, ләкин бик аз өлешен кешеләргә җиткердем» – дигән сүзләрен ишеттем», – диде.

Хәсән бине Зияр: «Имам 4 мең хәдис риваять итә: аларның 2 меңе Хаммадтан һәм ике меңе башка шәехләрдән китерелә», – диде.

Вакигъ бине Әл-Җаррах (имам Шәфигыйнең укытучысы): «Мин Әбү Хәнифә кебек гыйбадәт кылучыны һәм аның кебек фикһ белүчене очратмадым», – диде.

Имам Шәфигый болай диде: «Кем дә булса фикһ өйрәнергә теләсә, Әбү Хәнифәгә һәм аның укучыларына иярсен».

Шулай ук ул: «Әбү Хәнифәнең китапларын укымаган кеше фикһ гыйлемен тулысынча алмаган булып санала», – диде.

Җәгъфар бине Әр-Рубай: «Мин Әбү Хәнифә янәшәсендә 5 ел яшәдем һәм аның кебек аз сөйләшүче беркемне дә белмәдем. Аннан берәр фикһ мәсьәләсен сорасалар, ул киң итеп аңлатып бирә иде», – диде.

Әс-Салихи: «Әбү Хәнифә беренчеләрдән булып фикһны тәртипкә салды һәм аны кисәкләргә бүлде, соңыннан Мәлик бине Әнәс тә аңа ияр-де», – диде.

Имам Әбү Хәнифә бәхәсле мәсьәләләрне үзе генә хөкем итми иде, аның максаты укучылары белән киңәшләшеп, карар чыгару иде. Кайбер мәсьәләләр айдан артык чишеләләр иде. Болар барысы да мәзһәбнең дөреслегенә файда китерүгә һәм хатаны мөмкин кадәр булдырмауга шәһадәт бирә.

Әсәд бине Әл-Фәрид: «Әбү Хәнифә белән бергә аның 40 укучысы китап төзеделәр. Иң актив төзүчеләрдән Әбү Йосыф, Зөфәр бине Әл-Хөзәел, Давыд Әт-Тәгъи, Әсәд бине Гамер, Йосыф бине Хәмид Әс-Самти, Яхъя бине Зәкәрия бу китапны 30 ел буе яздылар. Гадәттә, һәр сорау өстеннән өчәр көн буе фикер алышалар иде», – диде.

## Әбү Хәнифәнең тәкъвалыгы

Әл-Касыйм бине Могыйн: «Әбү Хәнифә «Ләкин сәгать (Кыямәт) – аларның вакыты һәм бу сәгать иң куркынычы һәм иң ачысы» аятен берничә кат укып бөтен төнне елап басып чыккан», – диде.

Вакигъ: «Валлаһи, Әбү Хәнифә ышанычлы кеше иде. Аның калебендә Аллаһы Тәгалә Бөек һәм Мактауга Ия булучы иде. Ул бөтен нәрсәдә дә Аллаһының ризалыгын эзли иде һәм ул риза булыр иде», – диде.

Габдуллаһ бине Мөбарәк риваятендә Суфьян Әс-Сәүригә: «Йә, Габдуллаһның әтисе, Әбү Хәнифә гайбәттән һәм начарлыклардан бикерактыр! Мин Әбү Хәнифәнең дошманы хакында начар сөйләвен беркайчан да ишетмәдем», – диде. Суфьян: «Валлаһи, ул үзенең хәерле эшләрен киметә торган гамәлне кылмас», – диде.

Әл-Хәкәм бине Һишам Әс-Сәкәфи: «Әбү Хәнифә иң ышанычлы кешеләрнең берсе булды. Әмир аңа җәзалау белән куркытып, казна ачкычларын тапшырырга теләгән иде, ләкин ул кешеләрнең җәзасына караганда Аллаһының җәзасын куркынычрак тапты», – диде.

Әл-Хәсән бине Салих: «Әбү Хәнифә бик тәкъва кеше иде һәм харамнан ерак булды. Ул бик күп шикле әйберләрдән баш тартты. Мин үз ру-

хын һәм белемен шулкадәр саклаучыны күрмәдем. Аның барлык булган мөлкәте яшәве өчен кирәк кадәр генә иде», – диде.

## Имам Әгъзамның гадәти көннәре

Имам Зөфәр: «Мин Әбү Хәнифә янәшәсендә 20 ел яшәдем һәм аңардан да рәхимле һәм шәфкатьле кешене күрмәдем. Ул үзен Аллаһы Тәгаләгә багышлады һәм бөтен көннәрен дә гыйльми эзләнүләрдә һәм кешеләрне укытуда үткәрде», – диде.

Ул бары тик мөһим эшләре буенча гына югалып тора иде, авыруларны зиярәт кыла, җеназа намазларында катнаша, мохтаҗларга булыша иде, туганнарын зиярәт кыла һәм үз мәшәкатьләрен тикшерә иде. Төннәрен ул үзе генә калып, гыйбадәт кылды һәм Коръән укыды, үлеменә кадәр шулай яшәде.

Габдуллаһ бине Мөбарәк: «Әбү Хәнифәдән дә артыграк башка беркемнең дә имам булырга хакы юк, чөнки ул тәкъвалы, гадел, хикмәтле, пакь, галим имам иде. Аның кебек калебе һәм гакылы белән өйрәнүче беркем дә булмады», – диде.

## Имамның юмартлыгы

Кайис бине Әр-Рабигъ: «Әбү Хәнифә Куфа белән Багдад арасында сәүдәгәрлек белән шөгыльләнде һәм сатудан килгән табышка хәдисләр белүче шәехләр өчен кирәкле әйберләр сатып ала иде. Табышның калганын ул аларга биреп: «Үзегезнең кирәк-ярагыгыз өчен тотыгыз һәм бары тик Аллаһыны гына мактагыз; чөнки мин үз мөлкәтемнән бернәсә дә бирмәдем, ләкин Аллаһы, дөреслектә, миңа бу малны сезгә тапшыру өчен бирде», – диде.

Хафс бине Хәмзә Әл-Курайның: «Әбү Хәнифә янәшәсенә чит кеше утырса, ул торып киткәнче, Әбү Хәнифә аның хәлен сораша иде. Әгәр

аның берәр мохтаҗлыгы булса, ул аңа ярдәм итте, әгәр авыру булса, алар якын дуслар булганга кадәр ул аның хәлен белә иде», – диде.

Кайис бине Әр-Рабигъ: «Әбү Хәнифә тәкъва һәм галим кеше иде, аңа ярдәм сорап килүчеләрнең барысына да ярдәм итте. Аның дуслары бик күп иде, үзенең абый-энеләренә бик мәрхәмәтле булды», – диде.

## Имамның үлеме

Әл-Хатыйб һәм Әбү Мөхәммәд Әл-Хариси риваять итәләр: «Әбү Җәгъфәр Әл-Мансур Әбү Хәнифәне Куфадан Багдадка чакырып алды һәм аның Ислам илләре өстеннән баш казый булуын таләп итте, ләкин ул баш тартты. Моның өчен аны төрмәгә яптылар һәм һәркөнне камчы белән 10 мәртәбә суктыруны һәм аның хакында базарларда сөйләүне әмер итте. Аның белән бик начар мөгамәләдә булдылар, аны ашатмадылар һәм эчермәделәр. Болар барысы да 10 көн буе дәвам итә. Ул бик күп елады һәм Аллаһыга гыйбадәт кылды. Моннан соң ул тагын 5 көн яшәде.

Әбү Хәсән Әз-Зияди: «Имам Әбү Хәнифә үлеме якынлашуын тойганнан соң сәҗдә кыла һәм шул вакытта аның рухы тәненнән аерылып чыкты», – диде.

*Мөһәммәт Әбү Зәһрәнең «Әбү Хәнифә» китабыннан,*

*«Иман» 2008*

# Фән

# Коръән турында гыйлем

*(Дәвамы)*

**Коръән тәфсиренең беренче төре – «тапшырылган тәфсир»гә нигезләнгән Коръән тәфсире**

«Тапшырылган тәфсир»не, Коръән тәфсиренең нигезе буларак, ошбу чыганаклар тәшкил итәләр: Коръәннең үзендә булган аңлатмалар, мәсәлән, бер-берсен аңлата-ачыклый торган аятьләр; Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең аңлатмалары (хәдис-тәфсирләре); сәхабәләрнең һәм табигыйннәрнең аңлатмалары (хәбәр-тәфсирләре).

Сәхабәләрдән һәм табигыйннәрдән килгән хәбәр-тәфсирләргә карата галимнәр ихтиләфле булдылар: кайберләре ул хәбәрләрне «тапшырылган тәфсир»ләр төркеменә керттеләр, ә кайберләре – «Коръәнне үзеңчә фикерләп тәфсирләү» төркеменә.

Без исә, гомумән тәфсир китапларының күпчелеге диярлек хәдис-тәфсир һәм хәбәр-тәфсир нигезендә төзелгәнлеген исәпкә алып, хәбәр-тәфсирләрне «тапшырылган тәфсир» төркеменә кертәбез.

Коръән фәннәре арасында иң беренче булып формалашкан фән һәм китап – «тапшырылган тәфсирләр»гә нигезләнгән «Коръән тәфсире фәне» булды. Хәдис тапшыручылар һәм хәбәрчеләр бу фәнгә нигез салучы булдылар. «Хәдис-тәфсир»ләрне беренче булып җыючы имам Мәлик бине Әнәс булган, дигән фараз бар. Соңыннан, һиҗринең икенче гасырында, тәфсир хәдис өйрәнүдән аерылды һәм аерым бер фән буларак формалашты – ул, хәдис-тәфсирләр белән генә чикләнеп калмыйча, үзенә сәхабәләрдән һәм табигыйннәрдән килгән хәбәр-тәфсирләрне дә алды. Шундый тәфсирләрдән: Суфьян бине Гуйәйнә тәфсире, Вәкигъ бине Җәррах тәфсире, Шөгъбә бине Хәҗҗаҗ тәфсире һәм башкаларны-

кы. Аларның барысын да Ибне Җәрир үзенең зур күләмле тәфсиренә туплады.

**«Тапшырылган тәфсир»гә нигезләнгән Коръән тәфсиренең кимчелекләре**

«Тапшырылган тәфсир»ләр (бигрәк тә сәхабәләрдән һәм табигыйннәрдән килгән хәбәр-тәфсирләр) арасына төрле яраксыз мәгълүматлар үтеп керү сәбәпле, тәфсирнең бу төренә карата ышаныч бетү куркынычы сизелә башлады. Бу яман күренешнең тормышка ашуына фәкать галимнәр тырышлыгы гына киртә була алды, шуның өчен Аллаһы аларның барысыннан да разый булсын).

Бу хәлне тасвирлап, Әш-Шәфигый хәзрәт шундый сүзләр әйткән: «Ибне Габбастан сахыйх хәдис-тәфсирләр йөзгә якын данә генә иреште, ә калганнары исә – барысы да зәгыйфь булып чыктылар».

«Тапшырылган тәфсир»нең кимчелекле яклары ошбу сәбәпләр белән бәйле:

1. Тәфсиргә «бәни Исраил»дән («Ягъкуб балаларыннан») килгән риваятьләрнең кушылуы.

2. Килгән төрле хәдис һәм хәбәрләрнең иснәдсез булуы.

3. Уйлап чыгарылган яисә үзгәртелгән хәдис-тәфсирләрнең һәм хәбәр-тәфсирләрнең барлыкка килүе.

Беренче сәбәп – тәфсиргә «бәни Исраил» халкыннан килгән риваятьләрнең кушылуы (ягъни, тәфсиргә яһүдиләрнең һәм насараларның мәдәни йогынтысы).

Тәфсиргә мондый риваятьләрнең кушылуы сәхабәләр чорында ук башланган була. Әмма сәхабәләр, Коръәннең барча нечкәлекләрен ничек кенә белергә теләмәсеннәр – барыбер Китап әһелләренә сораулар белән мөрәҗәгать итмәгәннәр һәм аларның риваятьләрен һич тә кулланмаганнар. Алар Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең «Китап әһелләренә ышанмагыз, ә алардан килгән риваятьләрне, (ачык) инкяр итмичә генә, «Без

Аллаһыга һәм үзебезгә иңдерелгәнгә инандык» [1], дигән сүзләре белән җитәкчелек иткәнгә күрә, «бәни Исраил»ләрнең риваятьләрендә дөреслек белән янәшә ялганның да булуын бик яхшы беләләр иде. Шуңа күрә дә алар гакыйдә һәм шәригать мәсьәләләрендә Китап әһелләре белән бер дә киңәшләшмәделәр һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән килгән сахыйх чыганаклардан читкә тайпылмадылар.

Шулай ук сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең «Миннән бер генә булса да аять тапшырыгыз. «Бәни Исраил»ләрнең риваятьләрен дә тапшырырга ярый. Моның (аларның дөреслеккә туры килгән риваятьләрен китергәндә дигән мәгънәдә) гөнаһы юктыр. Ә кем дә кем минем тарафка ялган сүз әйтсә – урынын утта алсын» [2] дип әйткән сүзләрен дә гел истә тоттылар һәм шул сүзләрнең кысаларында гына булып харамга кермәделәр. Сәхабәләр шулай ук Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең әлеге мәсьәләгә кагылышлы булган башка төрле кисәтүләренә бер дә хыянәт итмәделәр.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең «Бәни Исраил» халкының риваятьләре хакында бәян итмеш хәдисләренең беренчесендә мөселманнарга бу риваятьләрне фәкать кызыклы кыйссалар һәм вакыйгалар белән танышу өчен һәм гыйбрәтле нәтиҗәләр ясау өчен кулланырга ярый, диелә. Болай итү, әлбәттә, ул риваятьләрнең дөреслеккә туры килүен ачыклаганнан соң гына мөмкин.

Икенче хәдисенә килгәндә, монда инде кисәтеп әйтелә – әгәр дә Китап әһелләренең риваятьләре (алар дөреслеккә туры киләләрме яисә юкмы – барыбер) шәригатькә каршы киләләр икән, андый очракларда мөселманнарга ул риваятьләрне куллану тыела. Һәм бу очракларда безгә ул риваятьләрне «уйлап чыгарылган» дип бәяләргә хокук бирелә.

Табигыйннәр исә бу мәсьәләдә, сәхабәләрдән аермалы буларак, Китап әһелләренең риваятьләрен куллануда үзләрен бик чикләмәделәр.

[1] Бохари (4:170).

[2] Бохари (6:20-21).

Аларның чорында күп кенә Китап әһелләренең Исламга килүләре сәбәпле, Исраил риваятьләрен тапшырулар һәм таратулар бик киң җәелде һәм, шул сәбәпле, табигыйннәрнең бер өлеше Коръән тәфсиренә бик күп төрле каршылыклы риваятьләр тутырды. Шулардан берсе – Мөкатил бине Сөләйман атлысы иде. Шулай итеп, тәфсирдә Исраил риваятьләрен куллану бик киң таралды һәм гадәткә дә әйләнде. Аларның яраклылыгы хакында табигыйннәрдән соң килүчеләрдә хәтта шик тә калмады һәм аларны кире кагучы да булмады. Шулай ук «язу чорында» да «бәни Исраил»ләрнең риваятьләрен тәфсир китапларына кертүчеләр табылдылар.

**«Бәни Исраил» риваятьләренең Коръән тәфсиренә тәэсире турында**

Билгеле ки, Коръән тәфсиренә бу риваятьләрләрнең тәэсире тискәре булды, чөнки аларны Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән киңәш һәм кисәтү сүзләре нигезендә тикшереп тормадылар һәм бер-берсеннән аерып та карамадылар. Бу риваятьләр арасында бик күп уйдырмалар һәм булмаган нәрсәләр булды. Нәтиҗәдә, тәфсирчеләр авыр хәлдә калдылар – алар барысы да бер җирлектән чыккан дип, бөтен риваятьләрдән шикләнә башладылар.

«Бәни Исраил»ләрнең риваятьләрен өч төргә бүлеп карарга була:

1. Сахыйх (яраклы, ышанычлы) риваятьләр, аларның сахыйхлыгын Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисләре раслаган очракта һәм алар шәригатькә каршы килмәгән булсалар.

2. Дөреслеккә туры килми торган (уйдырма) риваятьләр. Риваятьнең уйдырма булуы ачыкланса, бу вакытта ул кире кагыла һәм аны тапшыру һәм куллану тыела.

3. Билгесез риваятьләр. Аларны югарыда күрсәтелгән ике төрнең берсенә дә кертеп булмый. Мондый очракта без аларны кабул итә дә, инкяр итә дә алмыйбыз. Югарыда китерелгән хәдисләргә нигезләнеп, аларны кулланырга рөхсәт ителә. Андый риваятьләр күпчелек очракта файда-

сыз булып чыгалар, чөнки аларны дин белән бәйле булган мәсьәләләрдә барыбер кулланып булмый.

Тәфсирченең «бәни Исраил» риваятьләренә карата карашы нинди булырга тиеш?

Мондый риваятьләргә карата тәфсирче бик тә игътибарлы булырга тиеш – аңа андый риваятьләрне кулланганда фәкать акыл-фикерне эшләтеп, риваятьләрнең кирәклеләре белән генә чикләнеп һәм шәригать нигезләреннән һәм максатларыннан чыгып эшләргә кирәк.

Шулай ук Коръәнне аңлатуга Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөннәтендә тиешле мәгълүматлар (хәдис-тәфсирләр яисә хәбәр-тәфсирләр) булса – бу очракта аңа риваятьләрне кулланырга ярамый һәм, бу мәсьәләгә бик тирән кермичә генә, сәләфләрнең бу риваятьләргә карата булган фикерләре яисә ихтиләфле булулары турында гына әйтергә була.

Укучыларны бутамас һәм ялгышу юлына кертеп җибәрмәс өчен, фәкать сахыйх риваятьләргә генә игътибар бирергә һәм калганнарыннан ерак булырга кирәк.

Ә тәфсирче өчен иң дөресе шул булыр – «Бәни Исраил» халкының файдасыз һәм Коръән-Кәримнән читләштерә торган риваятьләрне куллanудан гомумән баш тарту.

«Бәни Исраил» риваятьләрен тапшыручы иң мәшһүр кешеләр:

Габдулла бине Сәләм, Кәгъб Әл-Әхбар, Вәһеб бине Мөнәббиһ, Габделмәлик бине Габделгазиз бине Җүрәеҗ.

Икенче сәбәп – килгән хәдисләрнең һәм хәбәрләрнең иснәдсез булуы.

Төрле уйдырма хәдисләр һәм мәгълүматлар киң тарала башлагач, галимнәр аларның иснәдләренә карата игътибарлы һәм таләпчән була башладылар.

Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән яисә бер-берсеннән хәдисләрне фәкать иснәдләре белән генә тапшыралар иде. Шулай ук табигыйннәр дә фәкать иснәдле хәдис-тәфсирләрне генә җыйдылар һәм шулар нигезендә генә Коръәнне тәфсирләделәр.

Алардан соң килгән тәфсирчеләр хәбәрләрнең иснәдләренә игътибар бирми башладылар һәм хәбәрләрнең чыганакларын ачыкламыйча һәм сахыйхлыгын тикшермичә генә куллануны гадәт иттеләр. Нәтиҗәдә, сахыйх хәдисләр зәгыйфь хәдисләр белән буталып беттеләр һәм кешеләр хәдисләрне шул буталган хәлдә бер-берсенә тапшыра башладылар һәм яздылар. Ә алардан соң килгәннәр, ул хәбәрләрне чынга алып, бу эшне тагын дәвам иттеләр.

Бәлкем, бу сәбәп – «тапшырылган тәфсиргә» иң зур зыян китерә торган сәбәп булгандыр да. Чөнки хәдисләрнең иснәдсез булуы тәфсир өйрәнүче кешеләрне бик нык ялгышуларга китерде – алар барча хәдисләрне дә, араламыйча, сахыйх дип кенә кабул итәләр иде.

Өченче сәбәп – уйлап чыгарган (ялган) яисә үзгәртелгән хәдис-тәфсирләрнең һәм хәбәр-тәфсирләрнең барлыкка килүе.

Шулай ук тәфсир өлкәсендә төрле уйлап чыгарылган яисә үзгәртелгән хәдис-тәфсирләр һәм хәбәр-тәфсирләр дә барлыкка килделәр һәм киң таралдылар. Шул сәбәпле дә сәләфләр калдырган мирасның күп өлеше юкка чыгып бетте. Нәтиҗәдә, без шикле булган һәрнәрсәгә карата ышанычыбызны югалттык – без, шикләнүгә төшкән хәлдә булып, «зәгыйфь» дип бәяләнгән һәрбер мәгълүматны кире кага башладык. Ә ул мәгълүматлар арасында сахыйх мәгълүматлар да булырга бик тә мөмкин бит.

Шулай ук, бу мәсьәләнең киресе дә булды – «сахыйх»ны «зәгыйфь»тән аера белмәгән кайберәүләр бу буталган мәгълүматларның барчасын да «сахыйх» дип кабул иттеләр.

«Тапшырылган тәфсир» нигезендә язылган иң мөһим тәфсири хезмәтләр:

– Әт-Табәриның (Ибне Җәрирнең) «Җәмигу-л-Бәйан фи тәфсири-л-Коръән» дип аталган китабы.

– Ибне Кәсирнең «Тәфсир Әл-Коръән әл-газыйм» исемле китабы.

– Хәзиннең «Лүбәбү әт-тәәъвил фи мәгани әт-тәнзил» дип аталган китабы.

– Әс-Сәгалибинең «Әл-Җәваһир Әл-Хәсән фи тәфсири-л-Коръән» исемле китабы.

*Нуретдин Гыйтырның «Коръән турындагы фәннәр» китабыннан*

# Әл-Мәтуриди тәгълиматы татарларга ничек үтеп кергән?

Билгеле булганча, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын) заманнарында безгә билгеле ислам фәннәренең берсе дә булмаган. Безгә динне өйрәнүне нык җиңеләйткәнгә, бу фәннәр хуплана торган яңалык исемлегенә керә. Ни өчен Пәйгамбәр (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын) заманында алар булмаган соң? Җавап бик гади: аларның зарурлыгы булмаган. Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын) теләсә кайсы замандашы килеп туган мәсьәлә буенча теләсә нинди сорауны аңа килеп сорый алган. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын) бу дөньядан китеп баргач, вазгыять үзгәргән, Аллаһы ачышлары иңдерелү тукталган, мөселманнар Коръән һәм сөннәттә булган олуг бу мирас белән бергә-бер торып калганнар.

Мөселманнарга Коръән белән сөннәт кенә җитми идемени? Нишләп кисәк кенә гакыйдә, фикһ, сира, тәфсир, хәдис һәм башкалар барлыкка килгән соң? Аларның барлыкка килүе берничә сәбәпкә бәйле:

– Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын) мирасын саклап калу зарурлыгы;

– исламны гарәп булмаганнар арасында да тарату;

– исламга таныш булмаган йогынтылар (идеологияләр), диннәр, йолалар, мәдәниятләр белән очрашырга туры килү;

– аерым дин белгеченең шәхси сыйфатларының йогынтысы;

– ислам эчендә төрле агымнар һәм мәзһәбләр барлыкка килү.

Билгеле булганча, Әбү Бәкер хакимлек иткән вакытта, хәлифәттәге сәяси вазгыять тотрыксызлана. Бу – ялган пайгәмбәрләр килеп чыгу, кайбер кабиләләрнең зәкят түләүдән баш тартуы һәм кайберәүләрнең хәтта мөшриклеккә кире кучүләре аркасында килеп чыккан. Шушы катлаулы

вазгыять вакытында Әбү Бәкер барлык фетнәчеләр белән дә сугышырга карар иткән. Сугышлар вакытында беренчеләрдән булып Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын) сәхабәләре шәһит киткән, алар араларында Коръән-хафизлар да күп булган. Мәсәлән, Йәмәм орышы вакытында җитмешләп Коръән белгече һәлак булган. Бу Гомәр бине Әл-Хәттабны сагаерга мәҗбүр иткән, һәм ул Коръәнне язма рәвештә бер җыентыкка туплау кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыккан. Әбү Бәкер бу фикердән, мондый эш Пәйгамбәребез (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын) яшәгән вакытта булмаган, дип башта бераз куркып калса да, Гомәр бине Әл-Хәттабның нык үгетләвеннән соң аның белән килешкән. Нәтиҗәдә, Коръән тексты беренче тапкыр язма рәвештә бер җыентыкка тупланган.

Соңыннан, Госман бине Гаффан заманында, Коръәнне икенче тапкыр бер җыентыкка туплау үткәрелгән. Бу туплауның асылы шунда булган – ул укуның Корәеш вариантында тупланган. Билгеле булганча, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын) заманында гарәп теленең җиде шивәсе булган. Һәм Аллаһы Тәгалә, Коръән барысына да аңлаешлы булсын өчен, аны алда әйтелгән шивәләрнең җидесендә дә иңдергән. Сәхабәләр, Коръәнне Пәйгамбәребездән (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын) алгач, аны үз шәкертләренә үзләре сөйләшкән шивәдә тапшырганнар. Госман бине Гаффан заманында сәхабәләрнең күп шәкертләре хәзерге Әзербәйҗан территориясенә җибәрелә торган гаскәрләрдә җыелган булганнар һәм алар арасында Коръәннне дөрес уку буенча каршылыклар килеп чыккан.

Мөэминнәр арасында фетнә чыгу куркынычын сизеп, Хөзәйфә бине Әл-Йәмән Мәдинәгә ашыккан, анда хәлифәгә барып барысын да сөйләгән, аннан соң: «Өммәтеңә дөрес укуны күрсәт», – дигән. Нәтиҗәдә, Госман бине Гаффан Коръәнне бары тик Корәеш шивәсендә генә саклап калырга карар иткән, башка сөйләшләрдәге бар язмаларны да юк итәргә фәрман

бирелгән. Аннан соң Коръән язуларын камилләштерү дәвам иттерелгән, нокталар кертелгән, сузык авазларны билгели торган тамгалар эшләнгән, соңыннан тәҗвид фәне барлыкка килгән.

Аннан соң сөннәтне саклап калу буенча эшләр эшләнгән, хәдисләрнең беренче җыентыклары төзелгән. Аны сәхабәләр үзләре үк төзи башлаганнар. Араларында иң билгелеләре исә Габдулла бине Гәмер бине Әл-Ас һәм Гали бине Әбү Талиб җыентыклары. Ләкин бу юнәлештә системалы эш бары тик хәлифә Гомәр бине Габделгазиз фәрманыннан соң гына башланган. Алар арасында Бине Шиһаб Әз-Зөһри, имам Мәлик, Әбү Мөхәммәд Габделмәлик бине Габделгазиз бине Җөрәйҗ, Әбү Гәмер Габдрахман Әл-Әүзагый, Әбү Габдулла Суфьян бине Сәед Әс-Сәүри, Әбү Сәләм Хәммәд бине Сәлем бине Динар җыентыкларын аерып күрсәтергә кирәк. Ә тулыландырылган хәдис җыентыклары бары тик һиҗри буенча III гасырда гына дөнья күргән.

I гасыр ахырына таба ислам галимнәре арасында белгечлекләргә бүленү башлана. Беренче махсус хезмәт булып Бине Исхакның Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) тормышы турында язылган китабы исәпләнә. Кызганыч, ул төп нөсхә хәлендә безгә кадәр килеп җитмәгән, без аны Бине Һишам тасвирлавында гына алганбыз һәм бу хезмәт сира фәненең нигезе булып тора. Аннан соң әкренләп гакыйдә, фикһ, ысул әл-фикһ, тәфсир, тарих һ. б. фәннәр буенча да аерым хезмәтләр күренә башлый.

Гакыйдәгә тәфсилләп тукталып, бу фәннең үсешенә төрле мәзһәб белгечләре ярдәм итүен әйтеп китәргә кирәк. Беренче мәзһәбләр дүртенче хәлиф Гали (радыйаллаһу ганһү) вакытында күренә башлый. Бу хариҗиләр һәм шигыйлар була. Башта алар сәяси хәрәкәтләр генә булсалар, вакытлар үтү белән үз идеологияләрен дә булдыралар. Шуңа бәйле рәвештә калган мөселман галимнәре алдында аларның идеяләрен кире кага торган дәлилләр эшләү мәсьәләсе килеп баса. Бу җәһәттән,

аеруча могъtәзиләләрне күрсәтеп китәргә кирәк. Могътәзиләләр үз тәгълиматларында юнан (грек) галимнәре хезмәтләреннән файдаланганнар. Аларның төп ялгышы – аңны Коръәннән һәм Сөннәттән өстенрәк дип санауда. Сөземтәдә алар Коръәннең барлыкка китерелгән булуы, кабердә җәзага тартуның мөмкин түгеллеге, зур гөнаһлар кылучыны иманлы да, иманын җуйган дип тә танып булмавы һ. б. шуның кебек ялгыш нәтиҗәләргә килгәннәр. Һәм, әлбәттә, сөнничелек галимнәре мутәзиләләр идеологиясен кире кагарга мәҗбүр булган. Әгәр дә Әбү Хәнифә мутәзиләләр белән бары тик дини бәхәсләр генә алып барса, Әхмәд бине Хәнбәл заманында вазгыять кискенләшкән. Моның сәбәбе – мутәзиләләрнең хакимияткә килүе була. Дәүләтнең мәҗбүр итү аппаратын кулланып, алар үз тәгълиматларын бар мөселман дөньясына таратырга тырышканнар. Ул чорның күп кенә галимнәре җәзага тартылган, төрмәләргә утыртылган, җәфа чигәргә мәҗбүр булган. Ләкин хәлиф алмашыну белән мутәзиләләр хакимиятләрен югалтканнар һәм сөнничелек галимнәренә ислам дөньясын мутәзиләләр идеологиясеннән арындыру мөмкинлеге туган.

Нәкъ менә шул чорда әһле-сөннәт вәл-җәмәгать төшенчәсе барлыкка килгән. Бу дәвердә ислам гыйлемендә ике мәктәп булган: Әшгариййә һәм Мәтуриди мәктәпләре. Беренчесе – Багдад галиме Әбү Әл-Хәсән Әл-Әшгарига, икенчесе – Урта Азия дин белгече Әбү Мансур Әл-Мәтуридига барып тоташа. Алар икесе дә ислам тәгълиматын тәртипкә салганнар, ә алардан соң килгән бар галимнәр дә бу фән үсешенә зур өлеш керткәннәр. Әл-Әшгари һәм Әл-Мәтуриди хезмәтләре белән танышкан вакытта, аларның I гасыр ислам галимнәре хезмәтләреннән (сәләф) әллә ни аерылып тормаганын күрергә мөмкин. Төрле тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә, Әл-Әшгари мәктәбе күбесенчә ислам дөньясының көнбатышында, ә Әл-Мәтуриди мәктәбе исә көнчыгыш өлешендә таралыш тапкан. Әл-

Мәтуридиның дәвамчылары нигездә – хәнәфиләр, ә Әл-Әшгариныкылар калган өч мәзһәб вәкилләре.

Безнең Идел-Урал төбәгенә Әл-Мәтуриди тәгълиматы Урта Азиядән үтеп кергән. Билгеле булганча, болгарлар (ә аннан соң аларның дәвамчылары – татарлар) Бохара, Сәмәрканд, Кабул һәм башка шәһәрләр мәдрәсәләрендә белем ала торган булганнар. Аннан укып кайткач, алар мөгаллим булып китеп, үз шәкертләрен үзләре укыган программалар буенча укытканнар. Әбү Мансур Әл-Мәтуридиның хезмәтләре шактый катлаулы дини телдә язылган, алар белән бары тик яхшы әзерлекле, гарәп телен камил белгән укучы гына шөгыльләнә ала.

*Габдулла хәзрәт Әдһәмов,*

*Казан шәһәре казые*

# Тарих

# Пәйгамбәрләр тарихы

## Корәешнең бәнү Һәшимне кысулары (Шәгеб[1] Әбү Талиб)

Мәккә кяферләре дин Исламның һәр якка таралуыннан вә халыкның Исламга керүеннән бик куркалар иде, һәрвакыт Исламның йөзгә чыгуыннан каршы килерләр, һәркемне иманнан биздерергә тырышалар иде. Әбү Талиб вә башка бәнү Һәшим кабиләсе – барчасы Исламга килгәне килмәгәне Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне вә башка мөселманнарны кяферләр шуннан сакларга тырышыр иделәр, вә ләкин әһле Ислам көннән-көн күбәймәктә вә һәр тарафта дин Ислам хәбәре ишетелмәктә вә төрле яктан халык Мәккәгә килеп, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күреп, Коръән ишетеп, ихлас итеп иман китермәктә иде. Бу эштән Мәккә кяферләре бик кайгыда иделәр, пәйгамбәрлектән бишенче елда кяферләрдән күп җәфалар күргәч, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләргә Хәбәш мәмләкәтенә һиҗрәт итмәк өчен изен[2] бирде. Хәбәш падишаһы Әсхәмә бине Бәхири[3] исемле Нәҗаши дигән мәшһүр падишаһ иде. Насара динендә иде. Аллы-артлы байтак сәхабәләр анда бардылар. Госман бине Гаффан, зәүҗәсе вә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кызы Рокыя, вә Зөбәер бине Әл-Гаввәм, Госман бине Мәзъгун, Габдуллаһ бине Мәсгүд, Габдрахман бине Гауф, Җәгъфәр бине Әбү Талиб вә гайреләр бармышлар иде, радыяллаһу ганһүм. Нәҗаши бу сәхабәләрне бик кабул итте вә кунак кылды. Бара-бара Хәбәш мәмләкәтендә мөселманнар байтак җыелдылар, Мәккә кяферләре артларыннан барып Нәҗашине вәсвәсә кылып, сәхабәләрне Мәккәгә кайтарып җибәрергә сорасалар да, Нәҗаши ирек бирмәде. Нәбәвәттән җиденче

---

1 Шәгеб – кабилә.

2 Изен – рөхсәт.

3 Әсъхәмә бине Әбҗәр

сәнәдә бер көн Әбү Җәһел вә башка кяферләр иттифакъ иттеләр ки, Һәшим кабиләсе кем булса да, алар берлә, барча мөселманнар берлә алыш-биреш итмик, кыз алыш, кыз биреш кылмыйк, алардан һәр төрле мөгамәләне кисик дип, үзара иттифакъ итешеп, Мансур бине Гикримә дигән кешедән гаһеднамә яздырдылар, ул намәне Кәгъбә эченә асып куйдылар вә һәм Һәшим кабиләсе берлә мөгамәләне өзделәр. Һәшим кабиләсенә вә башка мөселманнарга бик авыр булды, барчасы Әбү Талиб мәхәлләсенә җыелып торыр иде. Базарга барсалар, төрле хәкарәт[1] күрер иделәр: кяферләр боларга тиешле бәһа белән генә нәрсә сатмас иделәр, мөселманнарны кайда күрсәләр дә, кулларыннан килгән кадәр җәфа кылыр иделәр. Ике елдан артыграк ошбу рәвештә хәбәсәдә торган кеби[2] тордылар.

### Ай ярылмак

Нәбәвәттән сигезенче сәнәдә Корәешнең бәгъзеләре Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә әйттеләр ки, ошбу тулган ай ярылсын дип, могҗиза сорадылар. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм дога кылды, ай икегә ярылды: бер яртысы Хира тавының бер тарафында, икенче яртысы икенче тарафында күренде. Ошбу кадәр бөек могҗиза күрсәләр дә, һәнүз[3] иман китермәделәр. Каюлары сихерче, каюлары багучы, фәлән дип һич охшаусыз бөһтан вә ифтиралар[4] кылдылар.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гамме (анасы берлә бер тугмасы) Әбү Ләһәб вә хатыны дәхи Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә вә барча мөселманнарга бик дошман иделәр. Әбү Җәһел, Вәлид бине Әл-Могыйралар берлә иттифакъта булган хәлдә һәлак булдылар. Нәбәвәттән унынчы сәнәдә Җәбраил галәйһиссәлам вәхи китерде вә әйтте ки: «Кяферләрнең Кәгъбә эчендәге гәһеднамәләрендәге язула-

1 Хәкарәт – кимсетү, түбәнсетүләр.

2 Хәбәсәдә торган кеби – биктә, тоткынлыкта торган сыман.

3 Һәнүз – һаман.

4 Ифтира – яла, гайбәт, ялган.

рын көя ашады, «Аллаһы» исеменнән башка бер хәреф калмады», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хәбәрне гамме Әбү Талибка сөйләде. Әбү Талиб кяферләргә барды вә ошбу хәбәрне әйтте вә һәм әйтте ки: «Мөхәммәднең ошбу сүзе раст булса, сез дә инсаф итегез, безне бу кадәр тарлыкта тотмагыз, әгәр ялган булса, мин дә сезнең тарафыгыздан булырмын, Мөхәммәдне ташлармын», – диде.

## Һиҗрәттән соңгы әхвәл мөбарәкә

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдә мөшрикләрдән үзенә вә иманга килмеш сәхабәләргә төрле җәфалар вә чыдамсыз изалар күргәч, вә Мәккәдә күргәнчә, дин Исламны йөзгә чыгару вә кыен күренгәч, Мәдинә шәһәренә күчте. Мәдинә шәһәрендә әүвәлдән иманга килмеш сәхабәләр күбәйгән иде. Алар бик шатланып иттифакъ берлә кабул иттеләр, олуг вә кечүк ир вә хатын Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең килмәгенә зур шатлыклар итте. Мәккәдән күчкән сәхабәләрне бүлешеп, әүвәлләренә алып тәрбия иттеләр.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә биш чакрым чамалы «Кобә» дигән җирдә мәсҗид салды. Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе вә сәхабәләр бергә эшләп тәмам иттеләр. Дин Исламда салынмыш әүвәлге мәсҗид ошбу «Кобә» мәсҗидедер, соңра Мәдинә шәһәрендә икенче мәсҗид салдылар.

Мәккәдә вә әтрафта булган мөселманнар Мәдинәгә күчеп, байтак мөселман җыелды. Көн-бикөн иман китерүчеләр вә Исламга керүчеләр күбәя башлады, мөселманнарның хәлләре куәтләнә башлады. Дин Ислам хәбәре күп җирләргә ишетелде, ерак җирләрдән килеп, дин вә шәригать өйрәнеп, азан берлә җирләренә кайтучылар бар иде. Мәдинәлеләр сәхабәләрдән Исламны көчәйтергә, барча мөселманнарга ярдәм итәргә бик тырыштылар, шул сәбәптән аларга «әнсар» дип исем бирелде, «ярдәмчеләр» димәктер. Мәккә тарафыннан күчеп килмеш сәхабәләр

чын башта Исламны кабул итүчеләр вә Исламны саклаучылар иде. Аларга «мөһаҗирун» дип исем бирелде, «күчүчеләр» димәктер. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә килгәч, дәхи сүрә-сүрә, аять-аять Коръән иңәр иде, сәхабәләргә өйрәтеп, вәхи язучыларга яздыра барыр иде. Мәккәдә иңгән сүрә вә аятьләргә – «сүрә-и мәккия», «айә мәккия», Мәдинәдә иңмешләренә «сүрә-и мәдәния», «айә мәдәния» диелде.

*Галимҗан Баруди, 1899 ел*

# Ике тәфсир тарихы

2019 ел Татарстан Җөмһүрияте мөселманнарының Диния нәзарәте тарафыннан Тәфсир елы дип игълан ителде. Шул уңайдан халкыбызда аеруча киң таралган, дистә еллар дәвамында укып-өйрәнелеп килгән тәфсирләребезне карап китик.

Татарлар арасында «Ногмани тәфсире»н белмәүчеләр бик аздыр. Ул Идел буенда XIX йөз ахырыннан башлап иң киң таралган Коръән тәфсирләренең берсе булып тора. Аның авторы турынданиләр мәгълүм, хезмәтнең тарихы нинди булган соң?

Авторның тулы исеменә килгәндә, чыганакларда ул ике төрле очрый: Ногман бине Әмир бине Госман һәм Ногман бине Сәбит Әс-Сәмәни. Әс-Сәмәни тәхәллүсе руханиның Сәмән авылыннан булуын сөйли.

Ногман XIX гасырның беренче яртысында яшәгән, туган елы төгәл билгеле түгел. Җәмил Зәйнуллин хезмәтләреннән Ногман хәзрәтнең Казан губернасы, Курса авылында күренекле татар мәгърифәтчесе, Нәкышбәнди тарикатенең шәехе Әбү Насыйр Габденнасыйр бине Ибраһим Әл-Курсавидан белем алганы мәгълүм. Курсада мәдрәсә тәмамлаганнан соң, Ногман үзе дә мәдрәсәдә укыта, ә остазы вафатыннан соң, Коръән тәфсире өстендә эшли башлый. Әмма бу зур хезмәтен тәмамлый алмый. Остазы кебек үк, Ногман да хаҗга барганда вафат була, Төркиядә Өскедар шәһәре (хәзер Истанбулга керә) зиратында күмелә. Башка фикер буенча, Ногман Дагъстан якларына китеп, анда мөгаллимлек иткән, шунда вафат булган.

«Ногмани тәфсире»нең бер нөсхәсендә автор турында мәгълүмат китерелә, шуның буенча Ногмани турында түбәндәгеләр мәгълүм. Ул Стәрлетамак өязе Сәмән авылыннан (хәзерге Башкортостан Республикасы) Әмин бине Госман исемле адәмнең улы. Казан губернасы Курса авылында мәшхүр Әбү Насыйр бине Габденнасыйр бине Ибраһимда гыйлем

ала. Бик зирәк һәм сәләтле булып, остазыннан күп файда алды. Кайбер нечкә, четерекле мәсьәләләрне үзләштереп, яшьтәшләреннән аерылып тора. Остазының абыйсы Габделхалик шәехнең кызына өйләнә. Остазы хаҗга киткәч, аны алыштырып тора, дәресләр бирә, остазы башлаган тәфсирне тәмамларга теләп, төзәтмәләр кертә, үзенең тәфсирен яза башлап, аны «Әл-Кәһеф» сүрәсенә кадәр эшли.

Тәфсирнең язылу вакыты һәм урыны төгәл билгеле түгел. Җ. Зәйнуллин фикеренчә, бу 1831–1832 еллар тирәсе. Ногманиның башка әсәрләре булганмы, кызганычка, бүгенге көндә бу мәгълүм түгел.

Курсави да, Ногман хәзрәт тә үз хезмәтләрендә Ибне Әл-Әсир (Гыйзәэддин Әбү Хәсән бине Мөхәммәд Әл-Җәзири), Имам Куртуби һәм башка гарәп вә фарсы авторларының тәфсирләренә таянган.

Ногмани тәфсире беренче тапкыр 1896 елда нәшер ителә. Хезмәт таралып, Идел буе территориясендә авторга югары бәяләмә бирелә. Билгеле, тәфсир төзүгә тирән гыйлемле кеше генә алына ала, Ногмани хезмәте авторның бу сыйфатка ия булуын раслый. Аның Курсавидан кала кемдә һәм кайда гыйлем алуы, хезмәтен кайда язуы мәгълүм түгел.

«Ногмани тәфсире»н шартлы рәвештә өч өлешкә бүләргә мөмкин. Җ. Зәйнуллин билгеләвенчә, бүгенге көндә татарларга билгеле тәфсирне Габденнасыйр Курсави яза башлый, аны тәмамлый алмыйча, хаҗга барганда вафат була. Тәфсирнең икенче өлеше – Ногман хәзрәтнең хезмәте, ул тәфсирне остазы тукталган урыннан дәвам иттергән. Ногман Әс-Сәмәни «Әл-Кәһеф» сүрәсендә туктала. Шулай ук өченче автор да булган.

Тәфсирне нәшер иткәндә, басмаханә җитмәгән сүрәләрне, бу «Әл-Кәһеф»тән «Әл-Фәтех» сүрәсенә кадәр, төрек «Әт-Тибьян» тәфсиреннән алып куйган. Татарлар арасында госманлы тәфсирләре киң таралган була. Р. Фәхретдин фикеренчә, татар телендә тәфсир төзелгәндә, төрек рухание Мөхәммәд Әйнтабинең 1110 елда тәмамланган «Тәфсирүт-Тибьян» хезмәте файдаланырга мөмкин булган.

Бүгенге көндә КФУның Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәдә Ногмани тәфсиренең кулъязмалары саклана, әмма алар барысы да күчермә, ә кулъязманың асыл нөсхәсе (оригиналы) әлегәчә табылмаган. Бу нөсхә тәфсир чыккач басмаханәдә яндырылган, дигән фикер дә бар. Тәфсирнең күчерелгән кулъязмалары Ногман тәрҗемә иткән сүрәләрдән генә тора. Мисал өчен, Сөләйман Хәмидулла улы күчергән нөсхә ике өлештән тора. Беренче өлешкә «Әл-Бәкара», «Әли Гыймран», «Нисә», «Мәидә», «Әнгәм» сүрәләре кергән. Икенче өлеш «Әгъраф», «Әнфәл», «Тәүбә», «Һуд», «Йосыф», «Рәгыд», «Ибраһим», «Хиҗер», «Нәхел», «Бәни Исраил» сүрәләреннән тора. Бүгенге көндә татарлар арасында таралган «Ногмани тәфсире» тулы булса да, Ногман тарафыннан шушы саналган сүрәләр генә тәфсир ителә.

Тәфсирнең күчермә нөсхәләрендә күчерүчеләр өстәгән текстлар да бар. Бу намазны дөрес уку турында, Коръән укуның фазыйлътләре, догалар (мисал өчен, ваба авыруыннан дога), төрле хикәяләрдән өзекләр һәм башка шундый язмалар.

Татар телендә язылган һәм киң таралган булган янә бер тәфсир – «Әл-Фәваид» тәфсире.

Аның авторы Мөхәммәдзариф Әмирхан (1852–1921) – тарихчы, күренекле татар мөгаллиме, рухани, язучы Фатыйх Әмирханның әтисе. Күп еллар дәвамында ул «Әмихания» мәдрәсәсендә укыта.

Мөхәммәдзариф 1853 елның 10 гыйнварендә туа. Ногман кебек үк, ул да Курса авылында гыйлем ала. Аннан соң укуын Казан губернасы Норлат авылы мәдрәсәсендә дәвам итә. Шәкерт вакытында ук Коръәнне тулысынча ятлый. Тавышы бик матур булганлыктан, еш кына мөәзин булып та торган.

1874 елда, мәдрәсәне тәмамлап, Яңа бистә мәчетендә имам булып торган әтисенең ярдәмчесе булып урнаша. 1881 елда Бибирабига исемле мөгаллимәгә өйләнә.

Мөхәммәдзариф имам бөек шагыйребез Габдулла Тукайның җеназасын укый. Бу халыкның хәзрәткә ышанычын һәм мәхәббәтен күрсәтеп тора.

Хәзрәт 1921 елда ваба авыруыннан (холера) вафат була.

Мөхәммәдзариф Әмирхан – татар телендәге иң беренче тәфсирләрнең берсе булган «Тәфсир Фәваид»ның авторы. Хезмәтнең нигезен Мөхәммәд Җамалетдин Әл-Һинди Әд-Дәхләвинең «Фәтех Әр-Рахман фи тәфсир»е, «Мәдарик» тәфсире, «Зөбәде әсәр Әл-Мәһаиб вәл-Әнвар». Мөхәммәдзариф хәзрәт гарәп телен белмәүчеләр үз туган телләрендә Коръән аятьләренең мәгънәләре белән таныша алсын дигән максат куйган. Мөфәссир фикеренчә, төрки телдә язылган тәфсир бик кирәк булган.

Әлеге хезмәтнең кулъязма нөсхәләре шулай ук КФУның Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә фондларында саклана.

Хезмәт өч өлештән тора. Аның башында автор тәфсирнең ни өчен «Фәваид» («Файдалар») дип аталганын аңлата: «Чөнки тәфсир Коръән аятьләренең мәҗмугасы булып тора һәм үз эченә кешеләрне кызыксындырган мәгънәләрнең аңлатмасын ала. Коръән Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелгән була».

Тәфсирне нәшер итәргә 1885 елның 10 гыйнварендa Петербургта рөхсәт бирелүе турында языла.

Киләсе биттә «Әл-Фәтихә» сүрәсенең тәфсире башлана. Китап алтынчы сүрә, «Әл-Әнгәм» белән төгәлләнә. Ул 252 биттән тора.

Тәфсирнең бу өлеше һиҗри буенча 1303 елда Казанда Мөхәммәдзариф акчасына бастырылуы да искәртелгән.

Икенче том «Әл-Әгъраф» сүрәсеннән башланып, «Бәни Исраил» сүрәсенең соңгы аяте белән тәмамлана, 264 биттән тора. Бу китапны бастыруга 1886 елда Россия мәгариф министрлыгы тарафыннан рөхсәт бирелгән.

Өченче том «Әл-Кәһеф» сүрәсе белән башланып, 37 нче «Саффат» сүрәсе белән тәмамлана, 361 биттән тора.

Әлеге тәфсир турында билгеле булган мәгълүматлар менә шушылар.

Ногман бине Сабитның да, Мөхәммәдзариф Әмирхан тәфсире дә татарлар гына түгел, башка төрки халыклар тарафыннан да дистә еллар дәвамында укылган, өйрәнелгән, башка дини хезмәтләр өчен нигез булып торган. Бу тәфсирләрнең күпсанлы күчерелмәләре аларның киң таралган булуын дәлилли. Әлеге хезмәтләр халкыбызда дини әдәбият үсешенә зур этәргеч булып торган.

**Файдаланылган чыганаклар:**

1. Зайнуллин Дж. Г. Во имя Аллаха: Татарская богословская литература XVIII – начала XX веков и ее языковые особенности / Дж. Г. Зайнуллин. – Казань: Магариф, 1999. – 238 с.

2. Рахимова Я. Р. Татарские тафсиры конца XIX – начала XX вв.: «Тафсир Ну‘мани» Ну‘мана бин Сабита ас-Самани и «Тафсир Фава’ид» Мухаммад-Зариф Амирхана. Диссер. на соискание учёной степени кандидата исторических наук. Казань, КФУ – 2018.

# Морад Рәмзи

**(1855–1934)**



Морад Рәмзи Мәкки – мөселман дине белгече һәм татар тарихчысы – озын һәм вакыйгаларга бай гомер кичерә. Ул калдырган иҗади мирас аның XIX йөз ахыры – XX йөз башында мөселман фәнни традицияләре кысаларында эшләгән татар галимнәре буыныннан икәнлеге хакында сөйли. Гомеренең байтак елларын ул мөселман дине тәгълиматының классик хезмәтләрен өйрәнүгә багышлый. Тирән белемнәре аңа гомеренең соңгы чорында Коръәнне татарларга да, уйгырларга да аңлаешлы төрки телгә күчерергә һәм Коръән тәфсирен язарга мөмкинлек бирә. Согуд Гарәбстанында яшәгән елларында (1878–1914), суфичылыкның Нәкышбәнди тармагы тарафдары буларак, ул әлеге тармак вәкилләренең иң әһәмиятле әсәрләрен фарсы теленнән гарәп теленә күчерә. Моңарчы М. Рәмзи тикшеренүчеләрнең бик тар даирәсенә татар тарихы буенча гарәп телендә язылган «Тәлфик әл-әхбәр вә тәлких әл-әсәр фивәкаи Казан вә Болгар вә мүлүкат татар» («Казан, Болгар вакыйгалары һәм татар патшалары турында хәбәрләр вә истәлекләр җыентыгы») хезмәтенең авторы буларак кына мәгълүм иде. Китап дөнья күрүгә басма үзе дә һәм аның авторы да патша хакимиятенең репрессия корбаны була. Соңгы елларда табылган материаллар М. Рәмзи биографиясендәге вакыйгалар хронологиясен тулырак күзалларга, аның фәнни хезмәтләренең һәм башка басмаларының тулы исемлеген бирергә мөмкинлек тудыра.

М. Рәмзи 1855 елның 25 декабрендә (башка мәгълүматларга караганда, 1854 елның 10 октябрендә) Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт

авылында (хәзерге Татарстан Республикасының Сарман районында) туа, 1934 елның 2 апрелендә Чугучак шәһәрендә (Кытайның Синьцзян-Уйгыр автономияле районы) үлә.

Аның әтисе Баһадуршаһ (Батырша) Габдулла яшьтән үк ятим кала һәм яхшы белем ала алмый, ә әнисе мөгаллимнәр гаиләсеннән чыккан укымышлы хатын була (алар Р. Фәхретдиннең чыбык очы кардәшләре). Гаилә традицияләренә тугрылыклы калып, ул үз өйләрендә кызлар өчен башлангыч мәктәп ача.

М. Рәмзи (балачагында аны Мәрдәнша дип йөртәләр) гаиләдәге дүрт баланың берсе була. Ул алты яшендә әнисе мәктәбендә укый башлый, укырга һәм язарга өйрәнә, дин буенча тәүге белемнәрен ала. Сигез яшеннән Әлмәт авылы мәдрәсәсенә керә, анда яшьтәшләре арасында гыйлемле булуы белән аерылып тора. М. Рәмзине алга таба тәрбия кылуда һәм белем бирүдә аның әнисе ягыннан абзасы, танылган мулла Исмәгыйль Әл-Кашкарыйның атаклы шәкертләренең берсе, Әлмәт имамы һәм мәдрәсә мөгаллиме шәех мулла Хәсәнетдин актив катнаша.

Бертуганының улы Мәрдәншаның укуга сәләтен күреп, Хәсәнетдин аның белән өстәмә шөгыльләнә һәм малай бик тиз арада гарәп һәм фарсы телләрен шактый әйбәт үзләштерә. Тугыз яшендә инде ул гарәп теле морфологиясен өйрәнә, ә унбере тулгач кәлям фәнен үзләштерүгә керешә. Шул ук елларда башта әтисе, аннан соң абзасы белән бергә Коръән укый. 18 яшендә инде ул гарәп теле синтаксисы, мантыйк, этика һәм мөселман хокукы буенча әсәрләр белән таныш була.

М. Рәмзи авыл мәдрәсәсендә укытыла торган сабакларны тулысынча үзләштергәннән соң, абзасы киңәшен тотып, 1873 елда укуын дәвам итәргә дип Казанга килә. Үз шәкертен яхшы юлдан җибәрү максатында Хәсәнетдин Ш. Мәрҗанигә һәм аның мөдәррисләренең берсенә тәкъдимнамә яза. Ләкин М. Рәмзи Казанда озак тоткарланмый: укуын Урта Азиядә дәвам итү нияте белән Бохарага китә. Әмма Троицк шәһәренә

килеп җиткәч, ике елга монда калырга була, мәдрәсәдә Шәрәфетдин һәм Мөхәммәтҗан муллалардан дәресләр ала. Алар җитәкчелегендә күп кенә мәгълүм дини хезмәтләр белән таныша, янәдән мантыйкны һәм мантыйк әсәрләренә шәрехләрне өйрәнә.

Шуннан соң Бохарага юл тота. Юлы Ташкент аша үткәнлектән, ул анда тукталып ике ай дәвамында танылган галимнәрнең дәресләрен тыңлый. 1876 ел башында М. Рәмзи, ниһаять, Бохарага килеп ирешә. Монда ул кәлям өйрәнүне дәвам итә. Ләкин Бохарада озак тоткарланмый, 1876 елның язында Ташкентка әйләнеп кайта. Монда тагын ике ел тора, шәһәрдә һәм тирә-юньдә яшәүче галимнәрнең дәресләрендә була. Берникадәр вакыт М. Рәмзи үзе бер остазының кунакханәсендә мөгаллимлек итә. Монда ул очраклы рәвештә суфичылык әдәбиятына һәм гарәп-фарсы телендәге изгеләрнең тормышлары язылган күп санлы китапларга юлыга һәм аларны бик бирелеп өйрәнә.

М. Рәмзи Бохарага кайтырга торганда, дуслары аңа Хиҗазга барырга киңәш итәләр. Ул 1878 елда Ташкент һәм аның янындагы шәһәрләрнең хаҗ кылучылары белән бергә Согуд Гарәбстанына юнәлә.

Хаҗдан соң М. Рәмзи шунда калырга була. Ул укуын Мәдинә шәһәренең төрле мәдрәсәләрендә дәвам итә: башта «Әмин-ага» мәдрәсәсенә йөри, бер айдан «Әш-Шифа» мәдрәсәсендә укый, ә тагын сигез айдан «Әл-Мәхмүдия» мәдрәсәсенә күчә. Мәккәгә килгән елда ук 25 яшьлек М. Рәмзи Коръәнне ятлап бетерә – Коръән-хафиз була. Монда ул суфичылыкның башында шәех Мөхәммәд Мәзһәр торган Нәкышбәнди тармагы тарафдары булып китә.

Ә укуын М. Рәмзи Мәккә шәһәрендә дәвам итә. Шәех Габделхәмид Әд-Дагыстани җитәкчелегендә хәдисләрне тирәнтен өйрәнә, бер үк вакытта төрле фәннәр буенча Мәккәнең башка атаклы галимнәреннән дәресләр ала.

1883–1884 елларда М. Рәмзинең ике остазы да – Мөхәммәд Мәзһәр һәм Габделхәмид Әд-Дагыстани да – бер-бер артлы вафат булалар. Шәех Әд-Дагыстаниның дәвамчысы Мөхәммәд Салих Әз-Зәвави 1885 елда М. Рәмзи Мәккәдән киткәнчегә кадәр аның остазы була.

Мәккәдә һәм Мәдинәдә М. Рәмзи дини тәгълиматлар белән ныклап шөгыльләнә. Игътибар үзәгенә ул кәлям, фикһ, хәдисләр һәм тәфсирләрне ала, изгеләрнең тормыш юлларын өйрәнә, тарихи әсәрләр белән кызыксына, шигырьләр яза. Байтак әсәрләрне кабат-кабат укый, ләкин суфичылык буенча китаплар белән кызыксынуы аеруча көчле була. Ул Ибне Әл-Гарәби язмаларын яттан белә, Әл-Гарәби тәгълиматын иң тирәнтен белүче һәм шәрехләүче Габдрахман Әл-Җами хезмәтләрен өйрәнә.

Мәдинәдә М. Рәмзи суфичылыкның Нәкышбәнди тармагы тарафдарлары изге дип санаган язмаларны фарсы теленнән гарәпчәгә тәрҗемә итү эшенә керешә. Аның рухи остазы һәм зур белгеч шәех Әз-Зәвави М. Рәмзи тәрҗемәләрен башка галимнәрнекеннән уңышлырак дип таба һәм аларны бастырып чыгарырга карар кыла. Аның тәрҗемәләре 1889–1890 елларда Мәккәдә шәех Әз-Зәвави һәм аның ватандашлары акчасына басыла.

Хиҗазда уку елларында ул мөдәррисләрдән, китапханәләрдән һәм торак шартларыннан канәгать кала, ләкин аңа мәдрәсә акчалата ярдәм күрсәтми диярлек. Шуның аркасында Мәдинәдә укыган елларында ул зур кыенлыклар, мохтаҗлык кичерә. Госманлы империясе белән Россия арасында сугыш барганда (1877–1878), Казаннан һәм Төркестаннан хаҗ кылучылар килми. Сугыш туктап юллар ачылгач кына, ул Мәдинәдә хаҗ кылучы якташлары белән очраша.

Мәккәдә аның якташларыннан берничә шәех-дәрвиш, фәннәр үзләштерүче берничә шәкерт һәм аз санлы сәүдәгәрләр генә була. Соңгыларыннан Габдрахман Җәдид Алмания, Австрия һәм Төркия арасында сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Ул Мәккәдә еш була һәм мон-

да күчемсез мөлкәт сатып ала. М. Рәмзи белән танышкач, дустанә мөнәсәбәтләрне туганлык җепләре белән ныгыту йөзеннән, алдан килешенү буенча, Мәккәгә бертуган сеңлесе Әсма Шаһмөхәммәдне (тумышы белән Тәтеш өязенең Шепбашы авылыннан) алып килә. 1895 елда М. Рәмзи һәм Әсма Шаһмөхәммәд никахлашалар. Аларның тугыз балалары булып, шуларның дүртесе яшьтән үлә. М. Рәмзинең өйләнүенә дүрт ел дигәндә (якынча 1899 елда) аларның туганы Йосыф Дәбердиев хаҗга килә. М. Рәмзи йортында тукталып, ул кысанлыктан һәм эсселектән, кечкенә бала елаган тавыштан гаҗиз була. Шуннан соң бу туганнары М. Рәмзи гаиләсе өчен Мәккәдә йорт сатып ала.

М. Рәмзинең берничә тапкыр Хиҗаздан Россиягә кайтып килүе мәгълүм. Аның 1896, 1902 елларда – үзе генә, 1904 елда – хатыны һәм өч баласы белән, 1907, 1909 елларда янә – үзе генә, 1914 елның язында бөтен гаиләсе белән туган якларында булуы төгәл билгеле.

М. Рәмзи истәлекләренә караганда, Хиҗаздан Россиягә кайткач ул күп йөргән, үзенең тарихи хезмәтен тәмамлау өчен кирәкле материаллар туплаган; шушы максат белән Төркестанга барган, Петербург китапханәләрендә һәм архивларында эшләгән. Монда сүз, һичшиксез, тарихчы буларак М. Рәмзигә танылу китергән «Тәлфик әл-әхбәр...» хезмәте турында бара. Бу әсәрендә М. Рәмзи, Ш. Мәрҗанидән соң беренче буларак, борынгы вакытлардан алып үзе яшәгән чорга кадәрге татар халкы тарихын язарга омтыла.

Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты составында эшләгән Казан университеты профессоры Н. Ф. Катанов, үзенең цензорлык бәяләмәсендә, әсәрнең I томы «Россия тарихы белән бәйләнештә Казан һәм Болгар патшалыкларының гражданлык һәм рухи тарихы буенча да мәгълүматларны эченә ала», дип билгеләп үтә. II томны тәкъдим иткәндә ул әлеге томда «Россиядә яшәгән барлык төрки һәм мөселман

халыкларының тарихы һәм хәзерге хәле, аларның элек Россиядә хакимлек итүе һәм соңрак аңа буйсынуы турында мәгълүматлар бар», дип яза.

«Тәлфик әл-әхбәр...» хезмәтенә объектив бәя биреп, Н. Ф. Катанов болай ди: «Автор гарәп чыганакларыннан, Карамзин тарихыннан, татар басмаларыннан, татар газеталарыннан һәм халык риваятьләреннән файдалана», М. Рәмзи язган гарәп теленең катлаулылыгын һәм архаиклыгын ассызыклап үтә. Н. Ф. Катанов фикеренчә, «китап чимал сыйфатында беркадәр фәнни кыйммәткә ия (мәсәлән, рус мөселманнарыннан чыккан галимнәр турында мәгълүматлар), ә гомумән алганда, бик тенденциоз, фәнни белемнәр юк». «Тәлфик әл-әхбәр...»гә үз бәяләмәсендә Н. Ф. Катанов китаптагы «христиан диненә һәм гомумән христианнарга, аерым алганда русларга (хөкүмәткә, руханиларга, дәүләт һәм хәтта патша сарае затларына карата да) явызларча һәм күралмаучан мөнәсәбәт белән характерланучы, шуңа да цензура тарафыннан рөхсәт ителмәгән» иң катгый тәгъбирләрнең тәрҗемәләрен китерә.

Цензура бәяләмәсеннән соң Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты басмага арест сала һәм тиражны (өч мең нөсхә) конфискацияли. Ширкәт типографиясе беркадәр вакытка ябыла, авторга суд эше кузгатыла, ул кулга алынудан чит илгә китеп кенә котылып кала. 1911 елның 18 мартында жандарм идарәсенә бирелгән донесениедә мондый юллар бар: «Минзәлә өязенең Нөркәй волосте Иске Әлмәт авылыннан Морад әфәнде Мәдинәгә китте һәм Төркия гражданлыгы алды, ул моннан ике-өч ел элек Казан шәһәренә кайткан иде һәм анда Россиядән килгән мөселман шәкертләрен укыту өчен акча җыйды».

Ләкин бу эшне 1908–1915 елларда караган Саратов суд палатасы, Матбугат эшләре буенча дәүләт идарәсе һәм Казан комитеты ягыннан басым ясалуга да карамастан, җинаять составы булмау сәбәпле, гаепләүне танымый һәм басмага арест салмый. Әмма тираж юк ителгән була инде, ул вакытта гадәткә кергән гамәл буенча наширләр китапның ике йөзләп

нөсхәсен рәсми рөхсәттән башка гына сатарга өлгерәләр, шуңа басманың берничә дистә данәсе сакланып кала.

Хөкем эше туктатылганга кадәр үк, М. Рәмзи Романовлар династиясенең 300 еллык юбилее уңаеннан «гафу ителгәннәр арасында» була. 1914 елның язында ул гаиләсе белән кыска гына вакытка Россиягә кайта. Бу кайтуларында Әсма ханым кечкенә балалары белән туган авылы Шепбашыда кунак була, ә М. Рәмзи өлкән уллары Фәһми белән Төркестанга юл ала, алар Ташкентта, Бохарада, Нәманганда һәм Әндиҗанда булалар. Төркиягә кайтырга өлгерми калалар, Беренче Бөтендөнья сугышы башланып, төрек хәрби кораблары портны шартлаталар. Кышны алар Казанда чыгалар. М. Рәмзи Төркия гражданы булганлыктан, башка кеше исеме белән яшеренеп яши.

Яз җиткәч, ул Оренбург янындагы Тоз Төбе шәһәрендә торучы туганы Мөслихетдин Нугайбәк янына китә. Гаиләсен монда калдырып, ул өлкән улы белән юлга чыга, Иран аша Төркиягә үтәргә уйлый. Юл уңаеннан, берара каракалпак ишанында кунак булып, Үргәнеч аша Хивага барырга хәл кыла. Ләкин Хиваны баш күтәргән төрекмәннәр камап алган була. М. Рәмзинең юлы сузыла, шуңа күрә ул Үргәнечтән Петр-Александровскийга (Дүрткүлгә) юнәлә, пароходта Чарджоуга йөзәргә һәм Ашхабад аша Иранга җитәргә уйлый. Ләкин Петр-Александровскийда аны эзәрлекләгән рус хакимияте кулына эләгә (бу вакытта М. Рәмзи ялган паспорт белән йөри). Кулга алып Дүрткүл төрмәсендә өч ай тоткач, аны Чарджоу, Ташкент һәм Самара аша тәрәзәләренә тимер рәшәткә куелган тоткыннар өчен вагонда Уфага алып китәләр, Себергә сөрергә булалар. М. Рәмзинең дуслары аны коткару мөмкинлекләрен эзләргә керешәләр. Хәсән Акчура Петербургка барып эчке эшләр министры белән очраша. Бик күпләрнең фидакарьләрчә тырышлыгы белән М. Рәмзи азат ителә, аңа гаиләсе белән Оренбург губернасына китәргә һәм, әсирлеккә төшкән

граждан буларак, сугыш тәмамланганчы (1915–1917) полиция күзәтүе астында яшәргә рөхсәт бирелә.

Февраль революциясеннән соң М. Рәмзи Оренбург делегаты сыйфатында, 1917 елның июлендә Казанда узган Бөтенроссия мөселман руханилары съездында катнаша. Күпмедер вакыттан соң, Хиҗазга китәргә җыенып, Оренбургтан тагын Казанга килә. Ә бу вакытта шәһәргә ак чехлар керә, һәм М. Рәмзи паспортын озайту өчен Мәскәүгә, төрек консулы янына бара алмый. Сугыш хәрәкәтләре астында калмас өчен, ул, авылдан авылга йөреп, Бәйрәкәгә барып җитә һәм мәдрәсәдә укыта башлый.

1919 елның язында ул Уфага бара, аннан Кызыл Яр (Петропавловск) һәм Семипалатинск аша, бик зур кыенлыклар белән Чугучакка килеп җитә. Чугучак халкы М. Рәмзине имам һәм мөдәррис урынына чакыра, акча җыеп, барлык кирәк-яраклары белән аңа йорт сатып ала, һәм М. Рәмзи Чугучакта торып кала.

1921 елда ул Урумчыга һәм Турфанга бара.

Катаракта аркасында сукырайган М. Рәмзи 1923 елда өлкән улы белән бергә Истанбулга килә һәм уңышлы операциядән соң кире Чугучакка, гаиләсе янына кайта.

М. Рәмзи Төркестан мөселманнары арасында (төрки халыкларда гына түгел, ислам динен тотучы дунган-кытайлар арасында да) зур абруй казана. Махсус мәдрәсә бинасы булмаганлыктан, аның Базар мәчетендә (ул аның имам-хатыйбы була) алып барган дәресләренә шәкертләр генә түгел, Чугучакның башка мәчетләреннән муллалар да йөри. Чугучакта төрки телдә беренче хөтбәне М. Рәмзи укый. Туган телдә укылган бу хөтбәләр бик популярлаша: М. Рәмзи килгәнче буш торган Базар мәчетенә халык йөри башлый, ә җомга вакытларында мәчет кенә түгел, аның ишегалды да туп-тулы була, шуңа күрә хәтта кышкы салкын көннәрдә дә мәчет ишеген, халык хөтбәне ишетсен өчен, ачык тоталар.

М. Рәмзинең Чугучактагы һәм тулаем Төркестанда мондый популярлык һәм абруй казануы Кытай хакимиятендә шөбһә тудыра. Чугучак шәһәре башлыгы аңа Төркия гражданнарына Кытайда яшәргә рөхсәт ителми дип белдерә һәм илдән китәргә тәкъдим итә. Чугучак, Куләҗи, Урумчы һәм Мәгътабарани халкы М. Рәмзине Кытайда калдыруны сорап хакимияткә мөрәҗәгать итә. Кытай чиновниклары, М. Рәмзинең элегрәк тартып алынган паспортын һәм башка документларын кире кайтармыйча гына, аңа илнең эчке өлкәләренә барырга рөхсәт бирмәячәкләрен белдереп, Кытай гражданлыгы алырга тәкъдим итәләр. Мәскәүдәге Төркия илчелеге аша М. Рәмзи Әнкарага шикаять җибәрә. Әнкарадан Нанкин шәһәренә җибәрелгән протест файда китерми. Киресенчә, бу хакта белгән җирле чиновниклар аңа тагын да ныграк каныга башлыйлар. М. Рәмзи теләмичә генә Кытай хакимияте тәкъдимен кабул итәргә мәҗбүр була. М. Рәмзинең Төркестан чоры турындагы материалларда аның иҗади эше чагылыш тапмаган диярлек. Ләкин шунысы мәгълүм: аның зур дини гыйлемгә ия булуы турында белгән хакимият, Коръәнне җирле төрки телгә күчерергә тәкъдим ясый. Һәм бу тәкъдим аның ниятенә дә туры килә. Аның Коръән тәфсире язуы турында мәгълүматлар бар. Моннан тыш, «Тәлфик әл әхбәр...»нең төрки телгә (ихтимал, татарчага) тәрҗемәсе булуы мәгълүм. Мөгаен, тәрҗемә Чугучакта яшәгәндә ясалгандыр.

Көнчыгыш Төркестанда милли-азатлык көрәше барган елларда М. Рәмзи бердәм фронт булып Кытайга каршы чыккан төркиләр һәм дунганнар яклы була. Төркиләр һәм дунганнар арасында башланган каршылыкларның таркалуга китерүеннән куркып, ул өлгереп килгән конфликтны бастыру өчен һәр ике халыкта да булган абруеннан файдаланырга карар бирә.

1933 елның октябрь башында, Чугучакка дунганнар кергәндә, М. Рәмзи шәһәр мөселманнарын алар белән бергә булырга чакыра һәм Чугучакта, аның тирә-юнендә дунганнар белән бәрелешләр килеп чык-

масын өчен күп көч куя. Чугучактагы татар байларыннан берничә кеше баш күтәрүчеләргә акчалата ярдәм күрсәтә.

Урумчыдан (Синь-Цзянның административ үзәге) тиз генә зур хәрби көч белән Кытай хакимиятенә хезмәт иткән акгвардиячеләр килеп җитә. Дунганнар җиңелә. Шәһәрдә калган Җәмигъ мәчете ахуны Хәсән, татар байлары һәм аларның кардәш-ырулары үтерелә, аларның мөлкәтләре талана. Шәһәрнең дүрт мөхтәрәме, татар мәхәлләләре имамы Хафиз Гәрәй, М. Рәмзи һәм аның кодасы кулга алына һәм үлемгә хөкем ителә. Мондый хөкем карары җирле халыкта зур ризасызлык тудыра һәм җәзалаучылар, баш күтәргән халыктан куркып, аларны азат итә. Бу вакыйгалардан соң М. Рәмзи озак яшәми. Ул Чугучак шәһәрендә күмелгән.

Үзенең фәнни-педагогик эшчәнлеге белән М. Рәмзи XIX йөз мәгърифәтчелек фикере традицияләрен уңышлы дәвам итә һәм гамәлдә татар интеллектуаллары плеядасының «соңгы могикан»ы була.

*«Татар зыялылары: тарихи портретлар» җыентыгыннан.*

*Төзүчесе – Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин. «Мәгариф»нәшрияты, 2003*

# Тугызынчы мөфти – Габдеррахман Расүли

Габдеррахман хәзрәтнең тәрҗемәи хәле: Габдеррахман бине Шәйхел-ислам Зәйнуллаһ бине Хәбибулла Расүли 1881 елның 10 нчы октябрендә Троицк шәһәрендә дөньяга килә. Атасының мәдрәсәсендә – «Расүлия»дә укыган. Аннан соң үзлегеннән укып гыйлем алган. Заманының голәмәләре белән нык бәйләнештә була.

1917 ел 2/IX дә әтисе дөньяга бик танылган зат – Зәйнуллаһ ишан хәзрәте дөньядан ахирәт сәфәренә күчә (иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун). Риза хәзрәт бу хәбәрне ирештереп, бөтен әтрафка телеграмма бирә.

1920-1930 елларда заманындагы каты кысуларда тыйнак кына дини хезмәттә дәвам итә. 1936 елда хәзрәт вафатыннан соң, сайлаусыз гына мөфтилек хезмәтендә вафатына кадәр эшли. Инде бу чорларны күргән һәм хәтерли алган кешеләр ниләрне күз алдына китерә алыр икән... Риза хәзрәт вафатыннан соң нәзарәт әгъзаларыннан Кәшшаф, Җиһангир, Зияэддин, Габдулла һәм Мөхлиса казый хәзрәтләр юк ителде, озатылдылар. Нәзарәттә мөфти белән каравылчы гына калды дисәң дә, артык булмас. 1941 елда фашистлар гаскәре Мәскәүгә килеп җиткәч, Сталинга да динчеләр кирәк булды. Шул чагында христиан динендәге дин башлыкларының дәрәҗәләрен кире бирә, Патриарх исемнәре кире кайтарыла. Ташкенттан мөфти ишан Бабахани һәм Габдеррахман мөфти хәзрәтләрен чакыртып киңәш сорый. 1943 елда Габдеррахман хәзрәт мөселманнардан акча җыеп, фронтка ярдәм итә. Казаннан да Кыямеддин хәзрәт 100000 сум ярдәм итә. Шуңа Сталин рәхмәт кәгазе җибәрә. 1947 елда Габдеррахман мөфти беренче мәртәбә мөселманнар садакасы белән хаҗга бара. Икенче Бөтендөнья сугышы беткәч, 1945 елда, әнә шушы сугыш вакытындагы хезмәтләрен искә алып, хөкүмәттән рөхсәт

алып, «Ислам дине» дигән исем белән бер китап бастырып, халыкка тарата. 1946 нчы елда ишан Бабахан Сталиннан Бөтен СССРга бер мәдрәсә ачуны гозерләп сорагач, Бохара шәһәренә 100 урынлык дип шәкертләргә Ислам дине укытыр өчен рөхсәт ала. Ләкин анда динсез, атеистлар, госбезопасность куштаннарының кысулары аркасында 50-60 тан артык кеше укытмадылар.

1950 елның 5 нче июлендә Габдеррахман Расүли 9 нчы мөфти хәзрәте вафат булды. Уфада нәзарәт ихатасында дәфен кылына.

Әнә шушы мәдрәсә һәм анда укучылар, укырга теләүчеләр хакында язылачак әле. Бу урында әлегә кыскартабыз.

# Унынчы мөфти – Шакирҗан Хияледдинов

Шакир хәзрәт Хияледдинов вафат булгач, Мәскәү имамы Әхмәдҗан Мостафин 1 ел ярым чамасы вакытлыча мөфтилек вазифасын үтәп торды. Ул, әлбәттә, үзе дә Мәскәүдән китәсе килмәгәндер, әммә гаиләсе Мәскәүне ташламагач, Уфада төпләнеп тора алмады. Әхмәдҗан Мустафин хәзрәт мөфтилек вазифасыннан бушатуны үтенгәч, кечкенә генә сайлау үткәреп, Ленинградка байтак еллар имамәтчелек кылганнан соң, имамәтчелектән азат ителгән кеше Габделбари хәзрәт Исаевны мөфтилеккә сайладылар. Габделбари хәзрәт тә гаиләсен Ленинградта ташламау сәбәпле, Уфада берүзе, әүвәл, нәзарәтнең бер бүлмәсендә, аннан соң, гостиницада ялгыз 4 елга якын яшәде. Бу чорларда инде совет хөкүмәте һәм аның җитәкчеләре бу дәүләттә динне чын мәгънәсендә бетердек дип сөйләделәр. Хәтта бер генә җитәкчедән түгел гади кеше авызыннан да «Аллаһы теләсә», яки «Аллаһыга шөкер» кебек сүзне дә ишетү булмады. Шуңа күрә мөфтиләрнең дә бер нинди дини эш күрсәтер

өчен түгел, тик чит илдән килгән кешеләргә күрсәтер өчен: бездә дингә ирек, әнә күрәсез мөселманнарның да үз дини идәрәләре бар, һәм бөтен Татарстанның үзенә Казан каласында бер мәчет бар һәм Башкортостанда Уфада бер мәчет бар, теләгәнчә дин тотарга хокуклылар, дип күрсәтер өчен генә кирәге бар иде. Шуңа күрә бу затлар вакытында нәзарәттә эш тә юк иде. Дөресрәге, эш күп иде, ирек юк иде.

Инде менә, ниһаять, көтмәгәндә генә бер яшь кеше Бохара мәдрәсәсен тәмамлап, татарлардан беренчеләрдән булып Мисырның Каһирә шәһәрендәге Әзһәрия мәдрәсәсенә китте һәм мәдрәсәне, ягъни Әзһәрияне 4 елда уңышлы тәмамлап кайтты. Казанда Мәрҗани мәчетендә 1 елдан артыграк беренче имам булып эшләгәч, шул яшь кеше – Тәлгать Сафа улы Таҗеддинов хөкүмәтнең саклау органнары тәкъдиме белән һаман да кечкенә генә сайлау үткәреп, мөфти итеп сайланды.

*Габделхак хәзрәт Саматовның*

*«Милләтебездә Ислам дине» китабыннан*

# Мөселман галимнәренең казанышлары

Мөселман галимнәре дөнья фәнен үстерүгә зур өлеш керткән. Мисал өчен, Ибне Синаның «Әл-Канун» китабы ислам дөньясында гына түгел, Ауропада да табиблык эшенең нигезе булып саналган. Моңа дәлил булып бу китапның 600 ел дәвамында Ауропа университетларында уку әсбабы булуы тора. Башка мисалларны да карап китик.

## Тыйб – медицина

Рази (864–925) беренче булып җил чәчәге һәм бизгәк авыруларын аерып чыгара һәм тасвирлый. Әхшәмседдин (1389–1459) микроблар барлыгын ачыклаган. Камбур Вәсим (1761 вафат) туберкулез микробын ачкан. Инде мең ел элек Ибраһим Җәссар (1009 вафат) махау авыруының (проказа) сәбәпләрен билгеләп, аны дәвалау ысулларын тәкъдим иткән. Ибне Хәтиб (1313–1374) ваба (холера) авыруының йогышлы булуын фаразлый. Аммар исемле мөселман галиме тугыз гасыр элек үк үзенә генә билгеле булган ысул белән күзләргә операция ясаган. Гали бине Габбас (994 вафат) ракка хирургик операция ясый. Ул язган «Китаб әл-мәлики» медицина энциклопедиясе бүгенге көндә дә әһәмиятлелеген югалтмаган. Беренче хастаханә 707 елда, Вәлид бине Габделмәлик хәлифә хакимлек иткән чорда ачыла.

## Әл-җәбер – алгебра

Мөселман галимнәре математика өлкәсендә дә зур уңышларга ирешкән. Бу казанышлар бүгенге көн галимнәрен дә сокландыра. Күренекле Ауропа галиме Жак Рислер: «Безнең Яңарышның (Ренессанс) математика остазлары булып мөселманнар тора», – дип әйткән. Алгебра-

га нигез салучы Хәрәзми (780–850) беренче булып ноль санын кулланган. Ул «Әл-Җәбер вә әл-мөгабилә» дип аталган беренче алгебра китабы авторы да. Шушы «Әл-Җәбер» сүзе көнбатыш галимнәре әйтелешендә үзгәреп, «алгебра» булып китә. Беттани (858–929) тригонометриягә нигез сала. Әбүл-Вафа (940–998) тригонометриягә тангенс, котангенс, косинус төшенчәләрен кертә. Насреддин Түси (1201–1274) – тригонометрия буенча язылган беренче төпле фәнни хезмәтнең авторы. Тригонометриядә үзгәрмә зурлыкны Ибне Юныс (1009 вафат) керткән. Икебуын формуласын Ньютон керткән дип саналса да, беренче булып аны Гомәр Хәйәм (1123 вафат) кулланган.

## Йолдызлар турында гыйлем – астрономия

Мөселман галимнәрен бик кызыксындырган тагы бер фән – астрономия (гөлүмен-нөҗүм). Ислам дәүләтләренең зур шәһәрләренең һәрберсендә диярлек обсерваторияләр булган. Аларда мөселман галимнәре гасырлар дәвамында фәнни тикшеренүләр алып барып, күп серләр ачкан. Бу ачышлар исә Джордано Бруно (1546–1601), Коперник (1473–1543), Галилей (1564–1642) кебек күренекле галимнәрне илһамландырган. Мөселман галимнәре астролябияне (йолдызларның урынын билгеләү, алар арасындагы араны үлчәү өчен җайланма) камилләштергән. Зәркали (1029–1087) ул вакыт өчен иң төгәл һәм уңайлы астролябия уйлап чыгарган. Мөселман галимнәре Ауропа галимнәреннән күпкә иртәрәк Җирнең шарсыман булуын һәм әйләнүен фаразлаган. Бируни Җирнең үз күчәре һәм Кояш тирәли әйләнүен дәлилләгән. Һиндстанның Нандана шәһәре янында үткәргән тикшеренүләре нигезендә бу галим Җир шарының мәйданын санап чыгара алган. Бу ысул бүгенге көндә дә «Бируни кагыйдәсе» дип атала. Әл-Фирганинең астрономия өлкәсендәге хезмәтләре 700 ел дәвамында Ауропада уку әсбабы буларак кулланылган. Ул Кояшта таплар барлыгын да ачыклаган. Билгеле хаким Олугбәк

(1394–1499) гомерен фәнгә багышлаган. Сәмәркандта ул зур обсерватория төзетеп, үз чорының бөек астрономы буларак танылган.

## Физика

Исмәгыйль Әл-Җәзари (1206 вафат) «Китаб әл-һиләл» хезмәтендә кибернетикага нигез сала. Оптикага нигез салучы Ибне Хәйсәмнең (965–1051) «Китаб әл-мәназир» хезмәте Роджер Бэкон (1214–1294), Кеплер (1571–1630) һәм Леонардо да Винчи (1452–1519) кебек галимнәрнең эшчәнлегенә этәргеч булып тора. Бу хезмәт 600 ел дәвамында фән дөньясында төп чыганаклардан саналган. Ибне Герарe (1100 вафат) беренче булып кыру станогы кора. Ибне Фирнәнәс 880 елда аэропланга охшаган беренче аппарат эшли. Бу корылма өчен ул кош каурыйлары һәм тыгыз тукыма кулланган. Ул озак кына вакыт һавада очып тора һәм салмак кына җиргә төшә. Көнбатышта аэропланда беренче тапкыр 1903 елда гына очалар әле.

## Химия

Химия турында сүз чыккач, иң беренче булып искә Җәбир бине Хәйян төшә. Аның химия өлкәсендәге хезмәтләре Пристли (1733–1804) һәм Лавуазьен (1743–1794) кебек галимнәрнең ачышларыннан да кыйммәтрәк. Джордано Бруно аны дөньяның даһилары (генийлары) рәтенә кертә. Үзенең махсус лабораториясендә фәнни тикшеренүләр үткәреп, Җәбир күп серкәләрне (кислота) ачыклый ала. Искә алынган Рази күкерт кислотасын һәм чиста спиртны таба. Бәшир исемле мөселман галиме Ауропалы Бранттан бераз алданрак фосфорны ача. Беренче булып дары һәм пушканы да мөселманнар кулланган. Кысылган һава көче белән эшли торган пушканы солтан Мәхмәт (1432–1481) уйлап таба.

## Җәгърафия – география

Мөселман галимнәре җәгърафиянең фән буларак җитешүенә дә зур өлеш кертә. Җир шарының төрле почмакларын өйрәнгән Әүлия Челәбинең (1611–1682) һәм бар кыйтгаларда булып кайткан Ибне Батутаның (1304–1369) сяхәтнамәләре бик кыйммәтле тарихи һәм географик хәзинәләр булып торалар. Күп гасырлар элек Бируни Американың барлыгын фаразлаган. Васко де Гаманың (1450–1554) сәяхәтләрендә юл күрсәтүче булып мөселман диңгез сәяхәтчесе Ибне Мәҗид Идриси (1100–1166) торган. 850 ел элек бүгенге көн хариталарына (карталарына) бик якын дөньяның географик харитасы төзелә.

## Табигать гыйлеме

Ибне Байтар (1190–1248) исемле галим, Урта гасырларда күренекле үләннәр белгече һәм фармацевт, үзенең китабында 1400 дару үләне һәм үсемлегенә тасвирлама бирә. Бу хезмәт әлеге өлкәдә иң әһәмиятле фәнни чыганак булып торган. Дамири атлы галим (1349–1405) «Хәятүл-хаявән» («Хайваннар яшәеше») дигән хезмәтендә хайваннар дөньясы хакында төгәл мәгълүматлар туплый.

Беренче кәгазь җитештерү фабрикасы Багдадта 794 елда Һарун Әр-Рәшиднең улы Ибне Фазыл тарафыннан төзелә. Шундый ук фабрикалар Мисырда 800 елда һәм 950 елда Әндалуста (Испания территориясе) төзелә. Ауропада мондый фабрикалар күпкә соңрак барлыкка килә: Византиядә – 1100 елда, Сицилиядә – 1102 елда, Алманиядә — 1228 елда, Бөекбриятаниядә – 1309 елда.

*Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшинның*

*«Россиядә Ислам тарихы» китабыннан тәрҗемә*

# Тәрбия

# Өйләндерүдә ата вә ана вазифасы

Иргә тапшыру вакыты килеп җиткәч, кыз баланы, никадәр генә малсыз вә җиһазсыз булса да, динле, гүзәл тәрбия алган кешегә бирү өчен тырышу – ата вә ана вазифасыдыр. Аллаһы Тәгаләдән куркучы вә халыклардан оялучы зат, хатынын сөйсә, хөрмәт белән тотар. Әгәр дә, Аллаһы сакласын, мәхәббәте булмаса, җәфага салмас.

Малына яки дәрәҗәсенә кызыгып, бозык инанулы, диндә игътибарсыз кешеләргә кыз бирү ярамый. Дөнья малы никадәр күп булса булсын, вә дөнья дәрәҗәсе никадәр биек саналса саналсын, Ахирәт гамәленә күчереп исәпләгәндә, юк хөкемендәдер.

Газиз Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләренең иярченнәре (табигыйннәре) арасында беренче остаз булган Әбү Мөхәммәд Сәгыйд бине Әл-Мөсәййиб хәзрәтләре, хөрмәтле бөек ханымнарны ул вакытның хәлифәсе булган Габделмәлик бине Мәрван үзенең тәхет варисы – углы Вәлид – өчен сораганда, кире кагып, сәхабәләр төркемендә иң фәкыйрь булган, бер яки ике, яки өч дирһәм мәһәр бәрабәренә өйләнгән кешегә (кызын) биргән иде («Вафийятел – әгъян», 1 кис., 206 б.; «Мәшһүр хатыннар» исемле әсәрдә дә телгә алынды).

Балаларны өйләндергәндә, ата вә ана өчен балаларны җәберләү рөхсәт ителмәгән кебек, тәмам үз ихтыярларына салып, бер читтән күзәтүче булып тору да ярамый.

Тәмам үз ихтыярларына бирелсә, яшьлек исереклеге вә милек һәм көчле солтан булганлыгы сәбәпле, ихтимал ки, ялгышырлар, вә ялгышуларын да белми калырлар. Вә моның нәтиҗәсе буларак, олуг үкенечләргә очрарлар.

Хәл болай булганда, ата вә ана үзләренең камил солтан булуларын, балаларын өйләндерүдә үз ихтыярларына куюны угылларына вә кызла-

рына сөйләү, алар ниятләгән нәрсәдә булган хәвеф-куркуларын аңлатып бирү тиештер.

Ирексез сурәттә булган никахта күңелләр бер-беренә охшамаганлыктан, тормышлары зәһәрле вә иң дөресе – җәһәннәм газабы дәрәҗәсендә авыр булу мөмкиндер. Балаларның бәхетле булуын теләгәндә, көчләп никахлау ярамас.

Ирексезләү белән яки ирексезләүгә бик якын булган никахларның еш таралган сәбәбе – ирләрнең карт вә яки бай булып, кызларын бай хатыны итү белән бәхетле яшәтү теләге булыр. Ләкин бәхет дип аталган нәрсә һичвакытта мал белән сатып алынмас.

Шуның өчен, яшь кызларны яшьләренә туры килмәгән картларга, тәрбияле кызларны тәрбиясез байларга бирү – бәхет өмет ителәчәк өйләнешү булмыйча, фәкать мал бәрабәренә барлыкны вә бәхетне сатудыр.

Гакыл вә шәригать җәһәтенчә теләнгән никах – ата вә ана, вә өйләнүче балаларның ризалыклары вә шатлыклары белән булган никахтыр.

Әгәр дә балалар, үзләренең гадилекләре вә тәҗрибәләре азлыгы сәбәбеннән, ата вә аналар яраклы күргән карашларга ризасызлык күрсәтсәләр, бу тәкъдирдә, өйрәнү юлы белән күңелләрендә булган шөбһәләрен бетерү һәм теләкләрен дә кузгату турында тырышу кирәк булыр. Ничек кенә булса да, балаларны ирексезләп өйләндерү ярый торган эш түгел, чөнки, ихтыяҗларыннан башка сатылып китәргә – алар мал түгелләр бит!...

Бер-беренә тәрбия җәһәтенчә канәгатьләнерлек, вә бер-берен ошаткан егет белән кызның никахларына фәкать фәкыйрьлеген сәбәп итеп күрсәтеп, ризалык бирмәгән ата вә аналар үз вазифаларын үтәгән булмаслар, чөнки, әхлагы гүзәл булган кешенең фәкыйрьлеге һич гаеп түгел. Малсыз кеше – кешесез малдан хәерле түгелме?...

## Гаилә вә хатын

Ир белән хатынның шәригать кушкан сурәттә бергә кушылуыннан, ягъни җан һәм тән бер булуыннан – гаилә төзелер.

Ир кешенең үзе өчен бер хатын сайлап алуы – дөньяда булган тереклегендә, шатлык вә кайгысында бер иптәш, икенче сүз белән әйткәндә, һәрбер ак вә кара көннәрендә сыеначак, кайгылы вакытта юатып, җанны рәхәтләндерәчәк бер сердәш табуы булыр.

Хатын кеше – адәм баласында холыкларны гүзәлләндерергә сәбәп булучы, каты күңелләрне йомшартучы вә кешеләрнең дуслашуларына бер сәбәпче, кешеләрне җанвар түгел, ә кеше итүче бер куәттер, чөнки дуслык вә якынлык кебек нәрсәләр никадәр нык булсалар да, гаилә төзүгә кодрәтләре җитмәс.

Шуңа нигезләнеп, хатын – хезмәтче түгел, бәлки гаиләдер. Бу сүздә арттыру бар, дип уйланмасын! Чөнки ирләр – гаиләнең җитәкчеләре булган хәлдә, хатыннар – җитәкченең идарә итүендә булган гаиләнең нигез терәкләре вә өйнең идарә итүчеләре булырлар. Бу тәкъдирдә аларга «гаилә» дип әйтергә дөрес булыр.

Бөек бер затның әйтүенә караганда: хатын идарәсендә булмаган өйгә «өй» дип әйтү дөрес булмас, вә хатын идарәсендә булмаган бер өйдә утырганнарга да «гаилә» дип тә әйтелмәс.

Хатын яхшы булу шарты белән дөнья вә Ахирәтнең бәхетенә беренче сәбәп булганы кебек, һәртөрле рәхәт тә аның кулына ышанып тапшырылгандыр.

Изге хатын бетми торган хәзинә булганы кебек, бу дөнья сәфәрендә иренә юлдаш, мәшәкатьләрдә юатачак юаныч, авырлыкларда таяныч булыр.

Изге хатын иренең малын саклар. Иренең башына килгән хәсрәтләрне сүндерүдә көче бетмәс тәкъдирдә гайрәтле бер гаскәр кебек ирен юату турысында бөтен кодрәтен сарыф итәр. Күп вакыт булыр, кайбер нәрсәләрдә

әйберне сак тотып, һичкемгә сиздермичә, азмы-күпме мал җыяр да, иң кирәк бер вакытта иренә чыгарып биреп шатландырыр.

Хатын – гаиләнең терәге, дигән идек. Әгәр дә гаилә пароходка охшатылса, шөбһәсез, хатын пароходның койрыгына охшар. Дөнья зурлыгында булган пароходлар, гизеп йөрүләрендә койрык хәрәкәтенә иярүләре кебек, дәүләт мисалында булган гаиләләр дә, гаилә эчендә булган хатын хәрәкәтенә иярәчәкләрдер. Ләкин пароход койрыгы команданның (башлык) кушуына күрә хәрәкәтләнгән хәлдә, хатын фәкать үзенең тәрбиясенә яраклы ысул белән хәрәкәт итәчәктер.

Күз уңыбызда булган милләтләрнең хәлләре, хатыннар хәлләре белән һәрвакытта тигез булуы, шушы дәгъваның дөрес икәнен исбат итәр. Мәсәлән, хатыннары тәрбияле булган милләт – тәрбияле; хатыннары тәрбиясез булган милләт – тәрбиясез; хатыннары тырыш вә идарә итүчән милләт – бай; хатыннары ялкау вә яки исраф итүчән милләт – фәкыйрь буладыр.

## Хатын вә тәрбия

Гаиләнең нигез терәге – хатын, дигән идек. Бу фикер иң дөрес бер фикер булса кирәк, чөнки кешеләр холык вә тәрбия мөнәсәбәтендә хатыннардан башка беркемгә дә иярмәсләр. Араларында бөек мәктәпләрдә вә бөек фикерле адәмнәр янында гыйлем өйрәнгәннәр дә булыр, ләкин алар да аналарыннан алган тәрбия белән яшәрләр вә бу тәрбияне соңгы көннәренә кадәр сакларлар.

Шул сәбәпле, хөрмәтле фәлсәфәчеләрнең берсе: «Кешеләр һәрвакыт хатыннар теләгән кебек булачаклардыр; бөек вә өстен кешеләр, әгәр дә ихтыяҗыгыз булса, хатыннарга бөеклек вә өстенлек өйрәтегез!» – дигән. Чыннан да, алтын белән язарга лаек вә дөрес бер сүздер!..

Тәрбияле хатын ата вә анасын, ир һәм баласын, бер сүз белән әйткәндә, бөтен гаилә халкын вә гаиләгә мөнәсәбәтле булган дус вә

күршеләрне, шулай ук, булса хезмәтче ир-егетләрне вә хатын-кызларны үзенең тәрбиясе вә гүзәл холкы белән шатландырыр, үзе дә бәхетле булып гомер сөрер. Әмма тәрбиясез хатын, киресенчә, ата вә анасын, ир һәм баласын дөнья мәсхәрәсенә калдырыр, үзе дә бәхетсез булып яшәр, балаларын тәрбиясез калдырып, гомерләрен астын өскә китерер. Кызлык вә аналык кебек дөнья вә Ахирәт нигъмәтләреннән өлеш алмыйча, мәхрүм калыр.

Бер кеше никадәр бай вә никадәр мәртәбә иясе булса да, тәрбияле хатыны булмаса, бәхетле түгелдер, чөнки бәхет – гаиләсе эчендә рәхәт гомер итүдән гыйбарәт булып, гаилә эчендә рәхәт күрмәгән бер кеше, гаилә тышында рәхәт күрә белмәс.

Шул сәбәпле, хатыннарның тәрбияле булулары иң кирәкле бер нәрсә булып, моның файдасы да бөтен милләткә тиядер. Ләкин хатыннар өчен тиеш булган гыйлем вә кирәкле булган тәрбия нинди нәрсәдер?!... Һичшиксез, хатыннар өчен тиеш булган гыйлем вә тәрбиядән максат – үз вазифаларын белү, инсафлылык өйрәнү вә соңыннан болар белән гүзәл сурәттә эш итү, дип әйтү булыр.

Кешеләрне бәхетле итәчәк нәрсә, фәкать гыйлем генә булмыйча, бәлки гыйлем белән берлектә булган инсафлылыктыр. Инсафлылык исә гүзәл холык, дип әйтү булыр. Бу очракта, адәмнәрне бәхетле итәчәк нәрсә – үз вазифасын белү, вә белгәнен гүзәл холык белән үтәүдер. Инсафлылык, ягъни гүзәл холык булмаганда, гыйлем агачының җимеш бирмәве һәркемгә мәгълүмдер.

Кешеләрнең бәхетләре тәрбиягә бәйле булып, тәрбия дә хатыннар кулында булганлыктан, гомумән, милләтне тәрбияле итү вә гүзәл холык ияләре итү; хатыннарга тәрбия бирү вә моннан тыш, аларны балаларына тиешле тәрбия бирә белерлек дәрәҗәгә җиткерү кирәк булыр.

Әгәр дә хатыннар арасында тәрбия вә гыйлем таралса, беренче максатыбыз булган тәрбия вә гүзәл холык балаларга күчәр вә гаҗәеп тизлек

белән кавем, кабилә, милләт арасына җәелер вә аз гына бер вакыт эчендә нык тамырланыр.

Бөтен адәм баласына беренче дәрәҗәдә мөгаллимәлек иткән һәм дә иң әһәмиятле нәрсәләр хакында мөгаллимәлек иткән затларның гыйлем вә тәрбиядән мәхрүм калуларын дөрес санау – бикләнгән кешеләрне төяп барачак пароходны сукыр вә надан бер адәм җаваплылыгына ышандырып сәфәр чыгару кебектер...

Хатыннарның тәрбиясе бу дәрәҗәдә тиеш булган икән, бездә бу мәсьәләгә һаман әһәмият бирелмидер. Хатыннарны тәрбия итеп вә алар арадашлыгы белән бөтен кавем-кабиләгә гүзәл холык вә инсафлылык орлыклары чәчү фикере дөньяның һәр тарафында мәйдан алганда, бездә кайбер затлар тарафыннан хатыннарга гыйлем өйрәтү бозыклыкка сәбәп булачак, дигән бер ялган инану таралуы – үкенүле хәлләрдәндер.

Гыйлемле ирләрдән кайбер вакытларда кабәхәтлекләр һәм дә олуг кабәхәтлекләр килеп чыгар, шулай булуга карамастан, болар хакында, галим булганнары өчен «мондый кабәхәтлекне эшләделәр», дип әйтелмәс. Шуның кебек, гыйлемле хатыннардан да бозыклык килеп чыкканда, «бозыклыкларына гыйлемнәре сәбәп булды», дип әйтү дә дөрес булмас. Бозыклыкларга сәбәп, кирәк ирдә, кирәк хатында булсын, гыйлем вә инсафлылык булмыйча, бәлки гыйлем вә инсафлылыкның юклыгыдыр, һәм шуның белән бергә, кайбер вакытта, сирәк булса да, гыйлемле кешеләрдән дә кабәхәтлек килеп чыгар, чөнки, бу галимдә булган сәбәпләр гакылларны хәйран итәчәк дәрәҗәдә төрле-төрле булып, күбесе – Аллаһы Тәгаләнең Үзенә хас булган серләрдәндер.

Хатыннарга гыйлем укыту зарарлы, дип әйтү, тәмам хаксыз сүз булып, кешеләрнең яртысыннан гыйбарәт булган бу зирәк вә һәр нәрсәгә сәләтле бәндәләрне гыйлемнән өлешсез калдыруга вә шул сәбәпле, гомумән, адәм баласын тәрбиядән мәхрүм итүгә сәбәп булыр.

Балаларына тәрбия бирә белмәгән вә гүзәл холыклар өйрәтә алмаган хатыннан файда күрелмәве, шулай торсын, бик кыйммәтле булса да, уза торган дөньяда күп дәрәҗәдә зарарлар күрелер. Чөнки моның кебек хатыннар милләт эчендә чума авыруы микробларыннан да зарарлы булган кешеләр җитештерерләр.

Тәрбиясезлек исә аерым бер өйрәтүгә мохтаҗ булмыйча, бәлки тәрбия өйрәтелмәгәнлектән мәйданга килер. Икенче төрле итеп әйткәндә, балага гүзәл тәрбия бирмәү – үзе тәрбиясезлек өйрәтү булыр.

Эш моның белән калмас. Бәлки тәрбиясез булган хатыннар балаларына тәрбия бирә алудан мәхрүм булганлыкларына карамыйча, тыйб (медицина) гыйлеменнән мәхрүм булганнары хәлдә табиблык иткән кешеләр мисалында, үз идарәләрендә булган балаларны табигый хәлләрендә тотмыйча, тәрбияләү сыйфаты белән иң бөек тәрбиясезлекләргә сәбәп булачак әшәке холыклар дәресләре бирерләр. Аллаһы сакласын, моның кебек балалар бер вакытта да яхшылыкны кабул итмәячәк дәрәҗәдә бозылган булып җитешерләр.

Табигый хәлләрендә калган балаларны гүзәл мәктәпләр вә гүзәл холыклы мөгаллимнәр арадашлыгы белән яхшыландыру кулай булыр, ләкин тәрбиясез хатыннардан тәрбия алган балаларны яхшыландыру авырдыр. Чөнки, анадан алган тәрбиясен бала үзенең гомере буенча ташлый алмыйдыр. Тәрбиясез хатыннар кочагында тәрбияләнгән балалар, хәтта мәктәпкә кереп гыйлем өйрәнгәндә дә, табигатьләре бозылу сәбәпле, гыйлемнәрен дә юк нәрсәләргә корал итәрләр.

Кайбер кешеләрдән күренер: баласының үлүе белән малының әрәм булуы арасында сайлап алу ихтыяры бирелсә, бөтен дөньясын корбан итеп, баласының сәламәтлеген сатып алырга әзер булырлар. Эш болай булганда, үлемнән хәтәр башка бер куркынычтан саклану турысында тиешле дәрәҗәдә тырышмас.

## Тәрбия

Бер баланың динендә игътибарсыз, ата вә анасына усал мөгамәләдә булуының бозык холыкка нигезләнүе үлемнән куркыныч икәнлегендә һичкемнең низагы булмаса кирәк.

Үзенә хәерле киләчәк буын җитештереп, көчсез калганнан соң, гомерләрендә аның шәфкате күләгәсендә рәхәт гомер кичерү нияте белән тәрбиялəп үстергән баласыннан усал мөгамәлә күргән ата вә ана өчен баласының дөньяда яшәвендә нинди файда булыр?!...

«Эх, мондый балаларым дөньяда һич булмаса иде!»; «Эх, өйләнмичә үлгән булыр идем»; «Эх, дөньяга килмәгән булыр идем!» – дип хәсрәт чиккән ата вә аналар бу дөньяда азмы?!...

Шулай булуга карамастан, мондый хәсрәтләргә күп вакытта ата вә аналар үзләре сәбәпче булалардыр, ягъни тәрбия биреләчәк бер вакытта, балаларына тиешле тәрбия бирмичә, җиңелгә санаулары – мондый нәрсәләргә сәбәп булыр.

Эш болай булгач, хатыннарга тәрбия бирү иң кирәкле нәрсәләрдән булып, тузан кадәр дә җиңелгә санау ярамас. Хатыннарның бизәкләре – энҗеләре, хәтфә камзуллары, ефәк күлмәкләре, алтын беләзекләре түгел, бәлки тәрбияләредер.

*Ризаэтдин Фәхретдин*

# Мирас

# Чистайның беренче җәмигъ мәчетенә – 160



Беренче мәхәллә мәчете 1859 елда Малмыж өязе сәүдәгәре Хәсән Муса улы Якупов акчасына 1844 елгы «үрнәк» проект буенча салынган.

Ике катлы агач бинасы ишегалды эчендә тора. Күләм-фәза композициясе буенча, манарасы түбә уртасыннан бераз алдарак урнашкан. Вестибюле, кече һәм төп гыйбадәт заллары, михрабы мәчетнең төньяк-көньяк күчәре буенча сузылган. Бинаның хуҗалык өчен билгеләнгән беренче каты бүрәнәләрдән салынган, такта белән тышланган. Вестибюле кызыл кирпечтән салынган һәм, манараны уртада калдырып, кече зал белән уртак түбә ябылган. Төп зал өстендәге сигез кырлы барабанда гөмбәз калкып тора. Михрабы көньяк фасадтан чыгып тора. Залларында ярымтүгәрәк аркасыман тәрәзәләр бар, фасадлары кәкре элементлар һәм юка такталар беркетелгән путалар белән бизәлгән. Манарасында яктылык фонаре һәм балкон бар, ул сигез кырлы биек чатыр белән тәмамлана.

Классицизм стилендәге дини архитектура һәйкәле.

## Чистай шәһәренең икенче җәмигъ мәчете

XIX гасырның икенче яртысында халык саны арткач (ир-атлар саны 942 кеше), Чистайның беренче җәмигъ мәчете гыйбадәткә килүчеләрне сыйдыра алмый башлаган. 1874 елның 17 нче декабрендә җирле мөселманнар яңа кирпеч мәчет төзү һәм икенче мәхәллә оештыру хакында



карар чыгарган. Беренче мәхәлләдәге 249 ир-ат булачак яңа мәхәлләгә күчәргә теләк белдергән. Аның указлы мулласы, икенче гильдия сәүдәгәре М. Г. Мөхәммәткамалов мәчетне үз акчасына салдырырга теләсә дә, бу ниятне тормышка ашыру җиңел булмаган. Казандагы Духовная Консистория мәхәллә карарына каршы килгән һәм «… шәһәрнең православ халкына яңа төзелеш бер дә ошамый, ул бөтенләй кирәк түгел», дип тискәре бәя биргәч, Казан губерна идарәсе 1875 елның августында Чистай мөселманнарының үтенечен кире каккан.

Әлеге вакыйгалардан соң мөселманнар Хөкүмәт Сенатына мөрәҗәгать иткәннәр. Өч ел узгач кына башкаладан уңай җавап килгән. Сенатның 1879 ел 8 нче февраль указы белән губерна идарәсенең карары юкка чыгарылган һәм мәчет төзелешенә кичекмәстән рөхсәт бирергә кушылган. 1879 елның 27 нче февралендә үк Чистай мәхәлләсе губерна идарәсенең яңа мәчет салырга ярый дигән рәсми рөхсәтен ала, тиздән мәчетнең ике катлы бинасы төзелә башлый. 1882 елда мәчет төзелеп бетә; 1885 елда аңа өстәп кирпечтән ике болдыр төзелә (архитекторы Н. Паренсов). 1900 һәм 1903 елларда указлы мулла, икенче гильдия сәүдәгәре М. М. Мөхәммәткамалов акчасына ике янкорма салына, мәчет киңәйтелә.

Яңа оешкан мәхәлләнең беренче имамы булып Самара губернасы Бөгелмә өязенең Иске Үтәмеш авылы (Татарстанның хәзерге Чирмешән районына керә) кешесе Мөхәммәтзакир Хәйретдинов (15.08.1861 туган) билгеләнә. Бер арада Казан губернасы Спас өязенең Иске Үргәагар авылы (Татарстанның хәзерге Әлки районына керә) кешесе Мөхәммәтшаһит Фәхретдиновның мулла булып торуы мәгълүм. 1885 елның сентябрендә

ул беренче мәчеткә күчкән. Икенче мәхәлләнең соңгы имамнарыннан берсе – Чистай өязе Яуширмә авылы кешесе Шиһабетдин Шәрәфетдинов (1864 туган). Аңа указ 1894 елның 10 нчы июнендә бирелгән.

XX гасыр башында Чистайның икенче мәхәлләсендә 745 ир-ат исәпләнгән.

# Печән базары мәчете тарихыннан

## «Нурулла»га – 170 ел



Печән базары мәчете (Юнысов мәчете, җиденче мәчет). Элеккеге Мәскәү һәм Печән базары урамнары чатында урнашкан ике катлы кирпеч мәчет 1849 елда, беренче гильдия сәүдәгәре Гобәйдулла Мөхәммәтрәхим улы Юнысов (1776–1849) васыять иткән акчага, аның уллары-коммерция советниклары бертуган Юнысовлар тарафыннан төзетелгән. Аның фасадлары Печән базары майданына караган.

Мәхәллә имамнарының берсе булып Сәгәтдин хәзрәт сайланган. Аны 1856 елда Апанаев мәчете мулласының улы, Бохара мәдрәсәсен тәмамлаган Габделгани Сәгыйтов (1813–1871) алыштырган. Аның вафатыннан соң, 1871 елның 23 нче июлендә имамлык вазифалары ахун Хуҗиәхмәт Мозаффаровка күчкән. Хуҗиәхмәт хәзрәт мәхәллә халкы алдында абруй казанган. Аның кызы Мәхмүдә XX гасыр башында талантлы шагыйрә буларак танылган. Улы Мансур Мозаффаров атаклы татар композиторы булып үскән. Х. Мозаффаров, 22 ел дәвамында имам-хатыйб булып торганнан соң, күңелсез вакыйгага очраган – (бәлки үзе дә белеп бетермичә) балигъ булмаган кызны никахлаган һәм бу гамәле өчен (ә ул җинаять булып саналган), 1893 елның 19 нчы маенда хөкем ителеп, кулга алынган һәм руханилыктан читләштерелгән.

Әлеге вакыйгадан соң мәчеттә бер генә рухани – икенче мулла Габдулла Габделкәрим улы Апанаев (1861–1919) калган. Г. Г. Апанаев бай сәүдәгәр гаиләсендә туган, Казанның атаклы мәдрәсәләрендә укыган һәм, 1890 елның 15 нче декабрендә указ бирелеп, Печән базары мәчетенә имам-хатыйб ярдәмчесе булып билгеләнгән. Үз эшчәнлегенең берен-

че елларында ук ул алдынгы карашлы рухани, җәдидчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле булып танылган. Галимҗан Барудидан үрнәк алып, Г. Апанаев Евангелистлар урамында (хәзерге Татарстан урамы) урнашкан Печән базары мәчетен үзгәртеп кора башлый, аны тулысынча үз карамагына ала. Бай сәүдәгәрләр мәхәллә имамы булып алдынгы карашлы, укымышлы-галим кеше торуын теләгәннәр һәм 1895 елда Г. Апанаевны беренче мулла вазифасына тәкъдим иткәннәр. Әмма мәхәллә байларының бу ниятләре тормышка ашмый. Яңа фикерле һәр мөселман кешесендә «панисламист» күрергә күнеккән хакимият әһелләре җәдидче Апанаевны Казандагы үзәк, баш мәчеттә беренче рухани булуына юл куймаганнар. 1897 елның 24 нче февраленда имам-хатыйб булып Шакир Хәсән улы Уразгилдиев (1861–1908) билгеләнгән. Хәер, бу вакыйга хәлне үзгәртмәгән, чөнки Г. Г. Апанаев барлык мәсьәләләрне дә үзе чишәргә омтылган, элеккечә үк мәдрәсә белән җитәкчелек иткән. 1906 елда Габдулла хәзрәт либераль юнәлешле «Азат» гәзитен нәшер итә башлаган, шул ук чорда ул мөселманнарның Бөтенроссия съездларында да катнашып килгән; аның кандидатурасы Дәүләт Думасы сайлауларына чыгарылган. Г. Г. Апанаевның эшчәнлеге властьларда ризасызлык тудырган, бертуганы, беренче гильдия сәүдәгәре Мөхәммәтбәдретдин Габделкәрим улы Апанаев кебек үк, ул «ышанычсыз» шәхес буларак бәяләнгән. 1908 елның маенда Габдулла хәзрәт вазифаларыннан читләштерелгән һәм ике елга Вологда губернасына сөрелгән. Ул яңа алымнарга нигезләп укытучылык курслары оештыруда гаепләнгән.

1908 елда Ш. Х. Уразгилдиев вафат булган һәм беркадәр вакытка мәчет руханисыз калган.

1908 елның 19 нче сентябрендә өлкән имам булып Рязань губернасының Касим өязе кешесе Мөхәммәттаиб Шиһабетдин улы Алтынбаев (туган елы – 13.03.1882) билгеләнгән. М. Ш. Алтынбаев Кышкар мәдрәсәсен тәмамлап, Казанга килгәнче, Сембер губернасының Курмыш

өязе авыларының берсендә мулла булып торган. Печән базары мәчетендә эшли башлау белән, ул Г. Г. Апанаев керткән үзгәреш-яңалыкларны бетерү юлына баскан: кадимлекне кайтарган, мәдрәсә программасында булган дөньяви фәннәрне алдырган.

Г. Г. Апанаев инде беркайчан да үзенең элеккеге руханилык вазифаларын (Печән базары мәчетендә) кайтарып ала алмаган, 1919 елда совет суды хөкеме белән «контрреволюцион эшчәнлек»тә гаепләнеп атып үтерелгән.

Казанда баш гыйбадәтханә (җамигъ) саналган Печән базары мәчете мәхәлләсе Мәскәү һәм Печән базары урамнарын иңләгән. XX гасыр башында анда ир-ат затыннан 29 хуҗалыкта 270 кеше исәпләнгән. Мәдрәсәдә 40 шәкерт укыган.

*«Татарстан Җөмһүрияте: татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре» китабыннан, «Фест» нәшрияты, 1995 ел.*

# Нәсыйхәт

# Дәгъват кылу ысулы

## Имам-дәгъватчы булуның әһәмияте һәм өстенлеге

Имам-дәгъватчының төп бурычы – үз тирәсендәге кешеләрне туры юлга, ягъни дин юлына чакыру, башка төрле әйткәндә, күркәм әхлакый тәрбия бирү, кешеләрдә яхшы сыйфатларны тәрбияләү. Шушы сүздән аңлашыла ки, имамның җәмгыяттәге урыны бик зур. Күз алдыгызга китерегез, әгәр дә балалар бакчасында балалар була торып, тәрбияче булмаса, мәктәп була торып, укытучылары булмаса, университет, институт була торып, остазлары булмаса, ул биналардан үзләренә һәм җәмгыятькә файдалы нәсел чыгарга мөмкинме? Әлбәттә юк. Шуның кебек, үзенең төп ролен җиренә җиткереп үтәүче имамнар булмаса, рухи тәрбиядән өлешсез калган нәселләр һәлак булачаклар. Көтүчесез калган көтү кебек таркалачаклар. Тәндә барлыкка килгән авырулардан котылырга ярдәмен күрсәткән табиб кирәк булган кебек, кешедә булган кайбер кимчелекләрдән котылырга, яхшы сыйфатларны үзләштерергә юл күрсәткән имамнар да һичшиксез кирәк. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَلْتَكُن مِّنكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ إِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ ۚ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ ﴿١٠٤﴾

**«Сезнең арада игелеккә чакырып, яхшылыкны кушып, начарлыктан тыючы бер төркем кешеләр булсын. Һичшиксез, алар котылучылардан булырлар».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:104

Ибне Габбастан тапшырыла: Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: «Бер көн гадел (намуслы) имам булып тору, алтмыш ел гыйбадәт итүдән хәерлерәк», – дип әйткән.

Башка бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кыямәт көнне кешеләр арасында Аллаһы Тәгаләгә иң сөекле һәм иң якын булган кеше – гадел имам», – дип әйткән (Тирмизи).

Югарыда әйтелгәннәрне йомгаклап шуны әйтү кирәк, имам булу яисә имамнарны тәрбияләү иң әһәмиятле, саваплы һәм файдалы эшләрдән булып санала.

## Имам-дәгъватчының эчке сыйфатлары

1) Ихласлы булу, дөрес ният белән имамчылык вазыйфасын башкару.

Аллаһының Расүле галәйһиссәлам: «Галимнәр янында мактаныр өчен, наданнар белән бәхәсләшер өчен, яисә кешеләрне үзегезгә каратыр өчен белем алмагыз, кем шулай эшләсә җәһәннәм утына лаек булыр», – дип әйткән[1].

2) Түбәнчелекле булу, тәкәббер булмау, бернәрсә белән дә беркемнән дә үзен өстен куймау.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йөрәгендә тузан бөртеге кадәр генә булса да тәкәбберлек булган кеше җәннәткә кермәс», – дип әйткән. Сәхабәләр аннан: «Аяк һәм өстенә киенгән киемнәре яхшы булуын сөйгән кеше хакында (ни әйтәсең)?» – дип сорыйлар. Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Тәкәбберлек – ул хакыйкатькә разый булмау һәм кешеләргә лаек булган хакларын бирмичә кимчелек китерү», – дип җавап кайтарган (Мөслим).

3) Тәкъва булу, харамнардан саклану, хәтта шөбһәле нәрсәләрдән дә качу.

Ибне Мәҗәһтән риваять ителгән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Шөбһәле әйберләрне шикләнеп эшләүдән тыелмый торып, бер кеше дә чын тәкъвалардан саналмас», – дип әйткән.

---

1 Ибне Мәҗәһ хәдисләр җыентыгыннан.

4) Гайбәттән, сүз йөртеп кешеләр арасын бутаудан, фетнәләрнең килеп чыгуына сәбәпче булудан бик нык саклану.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Әй телләре белән иман китереп, йөрәкләре белән иман китермәүчеләр! Мөселманнарның гайбәтләрен сөйләмәгез, аларның яшерен эшләрен күзәтмәгез, чөнки кем аларны күзәтеп йөрсә, Аллаһы Тәгалә дә ул кешенең кимчелекләрен күзәтер һәм аны үзенең өендә оятка калдырыр», – дип әйткән[1].

5) Дөрес сүзле булу, ялган сөйләмәү.

Әбү Давыдтан китерелгән хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Ялганнан бик нык сакланыгыз. Чынлыкта, ялган гөнаһларга илтә. Ә инде гөнаһлар исә утка алып бара. Чынлыкта, кеше ялганлый, аның эче ялган белән тула һәм ул Аллаһы каршысында ялганчылардан булып языла. Дөрес сүзле булыгыз, чынлыкта дөреслек яхшылыкка илтә. Ә инде дөреслек исә җәннәткә илтә. Һәм кеше дөрес сөйләве белән, аның эче дөреслек белән тула. Һәм ул Аллаһы каршысында тугрылардан булып языла», – дип әйткән.

Имам Мәликтән китерелгән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмннән: «Иманлы кеше куркак була аламы?» – дип сорыйлар. Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Әйе», – дип җавап кайтара. Аңа янә: «Иманлы кеше саран була аламы?» – дип сорау бирәләр. Ул сораугa: «Әйе», – дип җавап кайтара. Аннан: «Иманлы кеше ялганчы була аламы?» – дип сорыйлар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Юк», – дип җавап кайтара.

6) Дөрес фигыльле булу.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

---

1 Имам Әхмәд, Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لِمَ تَقُولُونَ مَا لَا تَفْعَلُونَ ﴿٢﴾ كَبُرَ مَقْتًا عِندَ اللَّهِ أَن تَقُولُوا مَا لَا تَفْعَلُونَ ﴿٣﴾

**«Ий, мөэминнәр, эшләмәгән вә эшләмәячәк эшләрне ник эшләгән булып сөйлисез? Эшләмәгән эшләрегезне эшләгән булып сөйләүләрегез, Аллаһы хозурында зур гөнаһ, бик яман эштер».**

«Саф / Рәт», 61:2-3

7) Башка диннәрне һәм аларның ияләрен сүкмәү һәм аларга тел тидермәү.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَلَا تَسُبُّوا الَّذِينَ يَدْعُونَ مِن دُونِ اللَّهِ فَيَسُبُّوا اللَّهَ عَدْوًا بِغَيْرِ عِلْمٍ

**«Мөшрикләр табына торган сыннарны сүкмәгез, наданлыклары белән сезгә ачу итеп Аллаһыны сүгә башларлар».**

«Әнгәм / Терлек», 6:108

Бик зур галимнәрнең берсе Хаким югарыдагы аятькә тәфсир биреп: «Сыннарны, башка диндә булган пот төшенчәләрен сүкмәүнең ике сәбәбе бар. Беренчесе, потлар үзләре буш әйберләр, аларның өсләрендә бернинди гөнаһ юк, чөнки, алар күп вакытта агачтан, таштан, яисә шуларга охшаш булган әйберләрдән ясалганнар. Шуңа күрә, әгәр дә син потларны сүксәң, димәк, син буш әйберләрне сүгәсең дигән сүз. Икенчесе, башка диннәрдә булган потларны яисә төшенчәләрен сүгеп мәсхәрә итү, Аллаһы Тәгаләне һәм Аның хак динен сүгүгә сәбәп була», – дип әйткән.

Шулай ук, шәех Суютый (аңа Аллаһының рәхмәте ирешсен) югарыдагы аятькә таянып: «Әгәр дә кешеләрне яхшылыкка чакыру, начарлыктан тыю зуррак бозыклыкка алып килсә, бу эшкә керешү кешенең өстеннән төшә», – дип әйткән.

8) Мәрхәмәтле булу, кешеләргә карата каты мөнәсәбәтле булудан тыелу.

Аллаһы Тәгалә Үзенең соңгы сөекле пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында Коръәни Кәримдә:

وَلَوْ كُنتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ لَانفَضُّوا مِنْ حَوْلِكَ

**«Ий, Мөхәммәд галәйһиссәлам, Аллаһының рәхмәте белән өммәтеңә шәфкатьле булдың, әгәр каты күңелле булсаң, әлбәттә, синең яныңнан качар иделәр»,** – дип әйтә.

«Әли Гыйимран / Гыймран гаиләсе», 3:159

Димәк, әлеге аятькә таянып, Аллаһы Тәгалә юлында имамлык кылып, кешеләрне игелеккә чакырган вакытта һәркемгә карата йомшак мөнәсәбәттә булу кирәк, дип әйтә алабыз.

9) Кешеләр турында яхшы фикердә булу.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Кешеләр хакында начар уйлар, фикерләр уйламагыз, чөнки, фәлән-фәлән, фәсмәтәндер, дип берәр кеше турында дәлилсез начар фикер йөртү һәм аны сөйләү иң начар ялган сүз булып санала», – дип әйткән[1].

Ибне Сирин: «Сиңа кардәшең турында берәр начар сүз килеп ирешсә, син аңа берәр аклау табарга тырыш. Әгәр дә бернәрсә дә таба алмасаң, үз-үзеңә әйт: «Мин кардәшемне аклый торган бер генә аклау да таба алмадым. Бәлки аның үзе генә белгән берәр аклавы бардыр», – дип әйткән.

10) Кешеләрнең кимчелекләрен яшерү.

Ибне Мәҗәһтән риваять ителгән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәллам: «Берәр кеше мөселман кардәшенең дөньяга кагылышлы берәр авырлыгын чишәргә ярдәм итсә, Аллаһы Тәгалә дә Кыямәт көнне аның авырлыгын чишәр. Берәр кеше, берәр мөселман кардәшенең

[1] Имамнар Бохари, Мөслим, Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

кимчелеген яшерсә, Аллаһы Тәгалә дә аның дөньяда һәм Ахирәттә кимчелеген яшерер», – дип әйткән.

11) Биргән вәгъдәне үтәү. Әманәтне саклау, хыянәт итмәү.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам бер хәдисендә: «Дүрт төрле сыйфат бер кешедә барлыкка килсә, ул чын монафикъ булыр. Ә инде дүртесенең берсе булса, бу сыйфатны калдырганчыга кадәр, монафикъларның бер сыйфаты бар дигән сүз. Беренчесе – әманәт алса, хыянәт итәр. Икенчесе – сөйләсә, ялган сөйләр. Өченчесе – вәгъдә бирсә, үтәмәс. Дүртенчесе – бәхәсләшсә, чиктән чыгып гөнаһка керер», – дип әйткән. متفق عليه

12) Ачуны күңелдә сакламыйча гафу итә белү.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَلَا يَأْتَلِ أُولُو الْفَضْلِ مِنكُمْ وَالسَّعَةِ أَن يُؤْتُوا أُولِي الْقُرْبَىٰ وَالْمَسَاكِينَ وَالْمُهَاجِرِينَ فِي سَبِيلِ اللَّهِ ۖ وَلْيَعْفُوا وَلْيَصْفَحُوا ۗ أَلَا تُحِبُّونَ أَن يَغْفِرَ اللَّهُ لَكُمْ ۗ وَاللَّهُ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٢٢﴾

**«Ий мөэминнәр, сездән һичкем якын кардәшләренә, мескеннәргә һәм Аллаһы ризалыгы өчен дөрес дин булган җиргә күчеп килгәннәргә мал бирмәскә, ярдәм итмәскә ант итмәсен, бәлки кимчелекләрен гафу итегез вә хаталарын кичерегез, Аллаһы Тәгаләнең үзегезне ярлыкавын әллә сөймисезме? Аллаһы белеп Ярлыкаучы вә белеп рәхмәт Итүче».**

«Нур», 24:22

13) Дөнья байлыгына һәм дәрәҗәсенә күңел бирмәү.

Ибне Мәҗәһтән китерелгән хәдистә риваять ителә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәллам янына бер кеше килеп: «Миңа бер эш турында сөйләп күрсәт. Ул эшне эшләгәннән соң, Аллаһы Тәгалә мине сөяр бул-

сын», – дип әйткән. Мөхәммәд галәйһиссәлам аңа: «Дөнья ләззәтләренә бирелмә, Аллаһы сине сөяр. Кешеләрнең кулларында булган әйберләргә кызыкма, алардан да читләш, кешеләр сине сөярләр», - дип җавап кайтарган.

14) Күршеләр белән яхшы мөнәсәбәттә яшәү. Туганнар белән яхшы мөнәсәбәттә булып, туганлык җепләрен өзмәү, авыруларның хәлен белү.

Иман камиллегенең бер билгесе – күршегә яхшылыклар кылу һәм аны рәнҗетүдән саклану. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ ﴿٣٦﴾

**«Аллаһыга гына гыйбадәт кылыгыз, Аңа бернәрсә белән дә ширек кылмагыз, ата-анага, кардәшләргә, ятимнәргә, мохтаҗларга, күршенең кардәш булганына да, булмаганына да, иптәшкә дә яхшылык эшләгез».**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

15) Курыкмыйча, хикмәт белән хакны әйтә белү.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

ادْعُ إِلَىٰ سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ

**«Раббыңның юлына хикмәт һәм күркәм вәгазь белән чакыр».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:125

## Имам-дәгъватчының тышкы сыйфатлары

1) Чисталыкка, пакьлеккә игътибарлы булу. Ягъни тәннең, киемнең, яшәгән җирләренең пакь булуы.

Мөхәммәд галәйһиссәлам бер хәдисендә: «Чисталык – иманның яртысы», – дип әйткән[1].

2) Сакаллы булу.

Бөтен галимнәр, сакалы үскән кеше өчен сакал җибәрү – вәҗиб, бер кул учы озынлыгында үстерү – сөннәт, аннан озынрак итү – мәкруһ, аны бөтенләй кисү һәм башка дин ияләренең сакалларына охшатып йөртү – харам дигән фикергә килгәннәр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мыекларыгызны бик нык кыскартыгыз, сакалыгызны үстерегез», – дип әйткән[2].

3) Чапан, чалма һәм түбәтәйгә игътибарлы булу; бөтен гыйбадәтләрне шул киемнәрдән башкару.

Әбү Давыдтан китерелгән хәдистә Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мөшрикләр белән безнең аермабыз шунда: без чалмаларыбызны түбәтәй өстенә чорныйбыз», – дип әйткән.

Әбү Сәгыйд Әл-Худриның сүзләреннән хәбәр ителгәнчә: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләре белән намаз башкарган вакытта аяк киемен сала һәм сул ягына куя. Аның артында намаз үтәүчеләр пәйгамбәрнең шулай эшләгәнен күреп, аяк киемнәрен салдылар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам намазын тамамлагач сәхабәләреннән: «Ни өчен аяк киемнәрегезне салдыгыз?» – дип сорый. Алар исә: «Син аяк киемеңне салдың. Без дә синең артыңнан кабатлап аяк киемнәребезне салдык, - дип җавап бирделәр. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Җәбраил миңа килеп: «Синең аяк киемеңдә нәҗес бар», – дип әйтте (мин шуңа күрә салдым, диде). Сүзен дәвам итеп: «Мәчеткә килгәннән соң аяк киемегезне карагыз, әгәр дә анда нәҗес, пычрак күрсәгез, аны нәҗестән чистартыгыз һәм намазыгызны аяк киемегез белән башкарыгыз», – дип боерды»[3].

---

1 Имам Мөслим, имам Әхмәд бине Хәнбәл хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

3 Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Гыйбадәтегездә яһүдиләрдән аерылыгыз, аларга охшамагыз. Чынлыкта, алар намазларын аяк киемсез һәм оекбашсыз үтәрләр», – дип әйткән[1].

4) Авызның һәм тешләрнең чиста, җирәнгеч ислардән пакь булуы.

Ибне Мәҗәһ хәбәр итүе буенча, Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мисвәк кулланыгыз, чөнки мисвәк куллану авызга чисталык бирә. Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирештерә. Җәбраил миңа бу хакта бик күп сөйләде, хәтта мин тешләрне чистарту минем өммәтемә фарыз булмасмы икән, дип курка башладым. Әгәр дә һәрвакыт мисвәк кулланып, тешне чистарту өммәтемә авыр булыр, дип курыкмаган булсам, теш чистартуны фарыз иткән булыр идем», – дип әйткән.

5) Ислемай куллану.

Имам кеше чиста һәм пакь булып, пөхтә кием кию белән беррәттән яныннан хуш ис килүенә дә игътибарлы булырга тиеш. Исле майлар куллану сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең күркәм сөннәтеннән булып санала.

## Имам-дәгъватчыга карата булган бүгенге көн таләпләре

1. Кимендә ике ел мәдрәсә тәмамлауга дипломы булу.

2. Мәхәллә тарафыннан сайланып, тәкъдим ителү.

3. Мөфти, мөхтәсиб тарафыннан имамлыгы теркәлеп, шәһадәтнамә бирелү.

## Имам-дәгъватчының төп вазифасы – вәгазь-нәсыйхәт

Имам кешенең төп вазифасы – кешеләрнең милләтенә, диненә, тормыш хәленә, дәрәҗәсенә карамыйча аларны дингә чакыру. Шулай

1 Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

ук диндә булучыларга вәгазь-нәсыйхәт белән рухи тәрбия бирү. Әгәр дә имам кеше имам исеме алып, югарыда язылган дәгъват вазифасын үтәмәсә, аның дин юлында булуында бернинди файда юк. Имам кеше җомга, гает, җеназа, никах һәм шулай ук төрле изге ният белән уздырыла торган мәҗлесләрдә һәм җыелышларда халыкка вәгазь-нәсыйхәтләрен әйтергә бурычлы.

## Вәгазь-нәсыйхәтләрендә уңышлы имамның сыйфатлары

1. Гыйлемле булу. Бигрәк тә дини белеме булмаган имам берничек тә, башка кешеләргә дөрес юнәлеш бирә алмаячак. Буш савыт башка савытларны берничек тә тутыра алмаячак. Коръәни Кәримдә һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисләрендә гыйлем турында, аның өстенлеге турында бик күп мәгълүмат бар. Аларны искә төшереп торуда хаҗәт юк, дип инанам.

Имам булган кеше бигрәк тә җомга, гает, җеназа намазларын, Күсүф, Хүсүф, Истиска намазларының нечкәлекләрен өйрәнеп яхшы белергә тиеш. Шулай ук күп аятьләрне, хәдисләрне яттан белеп, хата җибәрмәс өчен фикһ фәнендә булган нечкәлекләрне дә өйрәнеп белергә тиеш.

2. Имам булган кеше сөйләгән сүзләренә капма-каршы гамәл кылмаска тиеш, чөнки кешеләр күп вакытта матур вәгазьгә түгел, ә эшләгән эшкә бәя биреп, гамәл кылалар. Әгәр дә имам кеше берәр изгелеккә чакырып, ул изгелекне үзе эшләмәсә, шулай ук берәр гөнаһтан тыеп, үзе ул гөнаһтан тыелмаса, аның халык алдында абруе үсмәячәк. Һәм инде, әлбәттә, сөйләгән вәгазе дә үтмәячәк.

3. Курыкмас (кыю) йөрәкле булу. Имам булган шәхес кемгәдер яраклашып, яисә кемнәндер куркып, сөйлисе сүзләрен сөйләмичә калырга, яисә әйтергә теләмәгән сүзләрне әйтергә тиеш түгел. Киресенчә, хәленә, урынына, вакытына карата хикмәт белән хәрәкәт итәргә тиеш. Бигрәк тә

безнең чорда хикмәт белән хәрәкәт итә белмәгән имам кешедән зарардан башка бернинди файда булмаячак.

4. Имам кеше вәгазен нинди телдә сөйли, шул телне яхшы белергә тиеш һәм шулай ук вәгазь белән мөрәҗәгать иткән халыкның һәм, әлбәттә, үзенең милләтенең тарихын белергә тиеш.

5. Имам, кешеләрне куркытып түгел, ә киресенчә, кызыктырып, йомшаклык белән күңелләренә өмет биреп, дингә чакырырга тиеш. Балаларга балаларча, яшьләргә яшьләрчә, олыларга олыларча эндәшә дә белергә тиеш.

## Уңышлы вәгазьнең шартлары

1. Сөйләячәк вәгазьне әзерләгән вакытта ниятләгән теманы ныклап өйрәнү һәм сөйләгән вакытта башлаган темадан читкә китмәү. Сөйләячәк темадан читкә китеп, тагы берничә темага керү – сөйләнгән вәгазьне уңышсызлыкка алып киләчәк.

2. Вәгазьне бер телдә генә сөйләү һәм ул телнең нечкәлекләрен белү.

3. Гомум халыкка сөйли торган вәгазь вакытында ихтиләфле мәсьәләләргә кермәү, ягъни кирәксез бер мәсьәләдә берничә караш булган мәсьәләләрне сөйләүдән тыелу.

4. Сөйләнә торган вәгазь чынбарлыктан ерак булмыйча, кешеләрнең тормышларына, дөньяларына һәм Ахирәтләренә кагылырга тиеш. Мәсәлән, Мәскәү кебек зур шәһәр мәчетендә минбәргә басып, көндәлек тормышында кое очрамаган кешеләргә әгәр дә коега күгәрчен төшсә, аны ничек иттереп пакьләү турында сөйләүләр бик зур мәгънәсезлек булып саналыр.

5. Вәгазь-нәсыйхәтне кешеләрне ялыктырып, нәфрәтләндерер дәрәҗәдә озын, озак иттереп сөйләмәү. Вәгазь никадәр мавыктыргыч булса да, өчәр сәгатькә сузылса, кешеләр аны тыңламаячаклар һәм хәтерләрендә дә калдырмаячаклар.

6. Кешеләрнең тормышларына бәйле, файдалы тема сайланганнан соң, шушы темага кагылышлы аять, хәдисләрне һәм шулай ук кешеләрнең тормышларында булган мисалларны әзерләү.

7. Сәясәткә кермәү.

8. Имам кеше вәгазен һәм минбәрне үзенең максатларына ирешү, шәхси ачуларын чыгарыр өчен кулланырга тиеш түгел.

9. Тирән фәлсәфәләргә кермәү. Барысы да аңлаячак дәрәҗәдә гади итеп аңлату, чөнки күп вакытта вәгазь тыңлаучылар арасында галим кеше белән бергә гади кеше дә була. Балалар һәм яшьләр белән бергә олы яшьтәге кешеләр дә була. Алар һәрберсе сөйләгән вәгазьне, ишеткән нәсыйхәтләрен үз дәрәҗәләрендә аңлыйлар. Шуны онытмыйча хәрәкәт итү вәгазь сөйләүченең иң әһәмитле эше булып санала.

10. Вәгазь сөйләгән вакытта тыңлаучыларның берсе торып басып, капма-каршы сүз сөйләп, фетнә күтәрә башласа, иң хәерлесе, ул кеше белән бәхәскә кермичә, тынычлык белән фетнәдән имин булган хәлдә җыелышны тәмамларга тырышу.

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*Казанның «Галиев» мәчете имам-хатыйбы*

# Динебездә юмартлык үрнәкләре

## Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең юмартлыгы һәм киң күңеллелеге

Бохари һәм Мөслимнең сахих хәдисләр җыентыгында китерелә: «Пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәлам кешеләрнең иң юмарты һәм киң күңеллесе, ә Рамазан аенда ул кешеләргә файда алып килгән ирекле җил кебек булган һәм бер кешегә дә яхшылык кылудан баш тартмаган». Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламне тасвирлап, Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу: «Ул кешеләрнең иң юмарты, иң киң күңеллесе, иң гаделе, килешүләрне иң яхшы үтәүче, аралашуда кешеләрнең иң йомшагы һәм мәрхәмәтлесе иде. Аны күрүче хөрмәт белән аннан курка, аның белән аралашучы аны ярата, аны тасвирлаучы: «Аңа тиңне мин элек тә, соңыннан да күрмәдем», – дип әйтә, аннан нәрсә генә сорасалар да, аны сораучысына бирә иде», – дип әйткән.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә туксан мең дирһәм китергәннәр. Ул аларны үзе янына чыптага куйган һәм, барлык акчаны таратып бетергәнче, беркемнең дә үтенечен кире какмаган. Күпмедер вакыттан соң акча сорап тагын бер кеше килгән. Пәйгамбәр галәйһиссәлам аңа: «Минем бернәрсәм дә юк инде, ләкин минем хисапка сатып ал, һәм безгә берәр нәрсә килсә, мин сиңа аны түләячәкмен», – дип әйткән. Бу сүзләрне ишеткәч, Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әй, Аллаһының Илчесе, Аллаһы сиңа эшли алмый торган эшне йөкләмәде», – дигән. Ләкин Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә бу сүзләр ошамаган. Шулвакыт акча сораучы кеше: «Сарыф ит һәм Гареш хуҗасы (Аллаһы) нигъмәтләреңне киметер дип курыкма», – дип әйткән. Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам елмайган һәм аның йөзендә шатлык күренгән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Хөнәеннән зур хәрби табыш алып кайтканда, бәдәвиләр табышның бер өлешен үзләренә бирүен сорап, аны

агачка терәгәннәр, агачның ботаклары аның япмасын эләктергән. Шунда Пәйгамбәр галәйһиссәлам туктап: «Бирегез минем япмамны! Әгәр дә минем мондагы күгән куаклыгы кадәр малым булса, мин аны, һичшиксез, сезнең арагызда бүлеп бирер идем, ул вакытта сез мине саран дип тә, куркак дип тә, ялганчы дип тә санамас идегез», – дип әйткән (Бохари).

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән риваять ителә: «Без Пәйгамбәрдән нәрсә генә сорасак та, ул аны Ислам юлына бирә иде. Бервакыт аның янына бер кеше килде һәм нәрсәдер сорады. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа зәкяткә җыелган сарыкларны шундый күп бирде, хәтта алар ике тау арасын тутыралар кебек тоелды. Аннары ул кеше үзенең кабиләдәшләренә әйләнеп кайткан һәм: «Әй, кешеләр, Исламны кабул итегез, чөнки, дөреслектә, Мөхәммәд ярлылыктан курыкмаган кеше кебек бүләкләр бирә», – дип әйткән»(Мөслим).

## Сәхабәләрнең юмартлыгы

Сәхабәләр юмартлыкның өстенлеген һәм әһәмиятен бик яхшы белгәннәр, шуңа да кайсы гына сәхабәне алсак та, аның үз малын дин юлында кызганмавына тап буласың. Алар үзара яхшы гамәл кылуда ярышканнар. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән булган: «Һичшиксез, миңа иң күп ярдәм күрсәткән кеше – Әбү Бәкер, ул минем өчен беркайчан да малын кызганмады һәм һәрвакыт миңа дус булды» (Мөслим). Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам Әбү Бәкернең малын үз малын куллангандай дин юлында сарыф иткән. Шул рәвешле, пәйгамбәрлек килгән вакытта Расүлебез галәйһиссәлам өчен бу бик зур таяныч булган.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң илдә корылык башлана. Кешеләр ярдәм сорап Әбү Бәкер янына килә, ләкин дәүләттә бер тиен акча калмаган була. Шул вакытта Госман радыяллаһу ганһенең азык-төлек белән төялгән кәрваны кайта. Сәүдәгәрләр аның янына ашыга. Ләкин Госман радыяллаһу ганһе: «Мин малымны иң зур бәя

тәкъдим иткәнгә генә бирәм», – дип әйткән. Һәм ул шулай эшли дә: бөтен азыкны Мәдинәдә яшәүчеләргә таратып чыга һәм алардан моның өчен бер тиен акча алмый, чөнки Госман радыяллаһу ганһе Аллаһы Тәгаләнең бүләге кешеләр тәкъдим иткәннән күпкә артыграк булуын яхшы белә. Икенче вакытта Госман радыяллаһу ганһе тулы бер гаскәрне коралландыруны үз өстенә ала.

Тирмизи һәм Әбү Давыд җыентыкларында түбәндәге хәдис китерелә: Гомәр радыяллаһу ганһе әйткән булган: «Аллаһының Илчесе безгә үз малларыбыздан мохтаҗларга өлеш чыгарырга боерды. Мин дә үз малымны сарыф иттем. Соңыннан Расүлебез галәйһиссәлам: «Үз гаиләңә нәрсә калдырдың?» – дип сорады. Мин: «Яртысын», – дип җавап бирдем. Соңыннан ул Әбү Бәкергә шул ук сорауны бирде. Әбү Бәкер: «Мин аларга Аллаһы Тәгаләне һәм Аның Расүлен калдырдым», – дип җавап бирде. Мин шул чакта: «Дөреслектә, мин беркайчан аннан уздыра алмам», – дип әйттем».

Мөселманнар Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килгәч, әнсарлар зур юмартлык күрсәтә һәм һәр гаилә үз өстенә берәр мөһаҗирне алып, үз малын аның белән уртаклаша.

Бервакыт Пәйгамбәр галәйһиссәлам янына бер мосафир килә, ләкин аның өендә кунак сыйларлык бер бөртек ризык табылмый. Шул чакта әнсарларның берсе ул кешене үзенә кунакка алып китә, ләкин хатыны аңа: «Балаларыбызга җитәрлек кенә ризык калды», – дип әйтә. Сәхабә балаларын иртәрәк йоклатып, ризыкны мосафирга тәкъдим итә. Хатынына исә утны сүндерергә куша. Әнсар һәм аның хатыны бары тик ашаган булып кыланалар, чынлыкта исә ач көенчә йокларга яталар. Икенче көнгә Расүлебез галәйһиссәлам аңа: «Аллаһы Тәгалә сезнең шундый нәрсә уйлап чыгаруыгызга гаҗәпләнде һәм бик сөенде», – дип әйткән.

Бер кеше Сәгыйть бине Гаска үтенеч белән мөрәҗәгать иткән. Сәгыйть йөз мең дирһәм бирергә боергач, бу кеше елап җибәргән. Ул:

«Нигә елыйсың?» – дип сораган. Тегесе: «Җир синең кебек кешене йотачагы өчен елыйм!» – дип җавап кайтарган. Шуннан соң Сәгыйть аңа тагын йөз мең бирергә боерган.

Риваять кылулары буенча, бервакыт Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу елап җибәргән. Аннан: «Ни өчен елыйсың?» – дип сораганнар. Ул: «Миңа инде җиде көн беркем дә кунакка килми. Мин болай итеп Аллаһы миңа үзенең нәфрәтен белдерә дип куркам», – дип җавап биргән.

Исән чагында ук җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе – Габдрахман бине Гауф. Бервакыт аның Мәдинәгә кәрваны кайта: җиде йөз дөягә ашлык, он һәм башка азык-төлек төялгән була. Гайшә радыяллаһу ганһә Расүлебез галәйһиссәламнән аның җәннәткә шуышып керәчәген ишеткәч, бу хәбәрне Габдрахман бине Гауфка җиткерә. Шатлыгыннан ул бөтен кәрванын Аллаһы юлында сарыф итәргә боера. Шул вакыйгадан соң Габдрахман ачык һәм яшерен рәвештә садака өләшә башлый. Әүвәл кырык мең көмеш дирһәм, соңыннан кырык мең алтын динарны мохтаҗларга тарата, күпмедер вакыт үткәч – 200 мыскал алтынны. Моннан тыш, хәрбиләргә ике мең ат бүләк итә. Үзе вафат булгач та, ул бик зур мирас калдыра, шул исәптән, Бәдер сугышында катнашканнарга һәм Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең хатыннарына. Шундый байлыкка ия була торып, Габдрахманның әхлагы камил саклана.

## Исламда хатын-кызларның юмартлыгы

Ислам тарихына күз салсак, мөселман хатын-кызларының да җәмгыятькә үз өлешләрен керткәннәрен күреп була. Мөслимәләрнең дә мөһим бер әхлакый сыйфаты булып юмартлык тора. Һәм шундый киң күңелле хатын-кызлардан – Әбү Бәкернең кызлары Гайшә һәм Әсма. Алар турында Әсманың улы Габдуллаһ: «Мин гомеремдә беркайчан туган апам Гайшә һәм әнием Әсмадан юмартрак хатын-кызлар күрмәдем, гәрчә аларның юмартлыгы төрле булса да. Апам аз-аз акча туплап, һәм

җитәрлек күләмдә җыелгач, аны мохтаҗлар арасында бүлеп бирә иде. Әнием исә, үзендә нәрсә булса да барлыкка килүгә, киләсе көнгә хәтле дә түзеп тормыйча, шул ук көнне аны мескеннәргә илтеп тапшыра иде», – дип әйткән.

Гайшә радыяллаһу ганһә киңкүңеллелек, талымсызлык һәм юмартлык белән аерылып торган. Ул ачлык һәм ярлылыкка сабыр иткән. Үзе турында онытса да, мохтаҗлар турында беркайчан да онытмаган, аларга һәрдаим ярдәм итәргә тырышкан.

Аның энесе Гурвә бине Зөбәер: «Мин аның җитмеш мең дирһәм бүлгәнен, шул ук вакытта ямаулы кесәле күлмәк киеп йөргәнен күрдем», – дип сөйләгән.

Шулай бервакыт хатын-кызлардан берсе Гайшә радыяллаһу ганһәгә һәдия (бүләк) җибәргән. Әмма Гайшә аны кабул итми. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам моны белгәч: «Әй, Гайшә, ни өчен һәдияне кабул итмәдең?» – дип сорый. Ул: «Аны җибәргән кеше миннән мохтаҗрак булганы өчен, йә, Расүлуллаһ!» – дип җавап биргән. Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Син бүләкне кабул ит, ләкин соңрак ул хатынга зуррак һәдия бир һәм үзенә ярдәм ит», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең башка хатыннары да юмартлык күрсәтүдә калышмаган. Шул исәптән Сәүдә бинте Зәмга радыяллаһу ганһә дә. Бервакыт Гомәр радыяллаһу ганһе аңа бүләк итеп акча җибәргәч, ул соңгы дирһәменә кадәр Аллаһы юлында таратып бетергән. Үзенең көннәрен һәм төннәрен Гайшәгә бирүе дә аның үзен корбан итәргә әзер булуы турында сөйли.

Иренең үрнәгенә ияреп, Зәйнәб бинте Җәхеш радыяллаһу ганһә дә юмарт һәм тыйнак була. Шулай көннәрнең берендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм барлык хатыннары барында: «Миннән соң сезнең иң озын куллыгыз миңа иярәчәк», – дип әйткән. Пәйгамбәр галәйһиссәламнән соң беренче булып Зәйнәб бинте Җәхеш үлгән. Шул

вакытта Пәйгамбәр хатыннары аның «иң озын куллы» (юмарт) булуын белгәннәр, чөнки Зәйнәб кул эшләрен яратып башкарган (тире эшкәрткән, күннән киемнәр теккән, дисбеләр ясаган) һәм ярлыларга шул малдан садакалар тараткан. Аның күркәм сыйфатлары турында Гайшә радыяллаһу ганһә болай дигән: «Мин Зәйнәбтән дә тәкъварак, гаделрәк, туганлыкны ныграк саклаучы, садака таратуда аяусызрак кеше күрмәдем. Шулай итеп, ул Аллаһы Тәгаләгә якынлаша иде».

# Сихердән ерак булыйк!

Сихер сүзе яшерен булу, яшерен йогынтыга ия булу дигәнне аңлата.

Бу сүз гарәп телендәге (سحر) «сәхәрә» фигыленнән (тамырыннан) барлыкка килгән. Сихер – ул төрле әфсеннәр уку, төеннәр бәйләү һәм кешеләрнең акылына, җанына-тәненә тискәре йогынты ясау. Сихерче – җеннәргә, шәйтанга мөрәҗәгать итүче кеше, ул үзенең имансызлыгы аркасында аларга кирәк булган юньсез һәм динсез гамәлләр башкара. Сихерче ул гамәлләрне җеннәр һәм иблис аңа сихерендә ярдәм итсен өчен эшли. Алдарак сихерчеләр башкара торган берничә кабахәт эшләрне санап китәрбез. Сихерчеләр гади кеше белмәгән яшерен белемнәргә ия булулары турында сөйлиләр, сихер кулланып, башкаларның үлеменә ирешәләр, яраткан парларны бер-берсенән аералар, кешеләр арасында үзара җылылык яки салкынлык хисләре тудыралар, аларның фикерләрен, карашларын үзгәртәләр.

Шәригать атамалары нигезендә сихер ике төркемгә бүленә:

1. Әфсеннәр уку, төеннәр бәйләү һ.б. Сихерче алар аркылы сихерләнүчегә зыян салу өчен шәйтаннардан ярдәм ала.

2. Сихерләнүченең тәне һәм аңына, аның теләк, сәләт һәм һәвәслекләренә төрлечә зыян салу өчен, төрле төнәтмәләр, кайнатмалар куллану. Боларны кайчак сөйдергеч сихер дип тә атыйлар.

## Хәдисләрдә сихер турында

Аллаһының Расүле галәйһиссәлам: ‘‘Иң авыр гөнаһлардан сак булыгыз:

1. Аллаһыга иптәшкә илаһ китерүдән, бу Аллаһыга табынгандай икенче берәүгә табыну (ширек) була.

2. Сихердән. Бу – күрәзәлекләр, әфсеннәр, фал салулар, сөйдергеч сихерләр һ.б.

3. Гаепсез кешене үтерүдән.

4. Рибадан табылган табышны файдаланудан.

5. Ятимнәр мөлкәтен файдаланудан.

6. Тәкъва мөслимәне зинада гаепләүдән», – дип әйтте (Имам Бохари, Мөслим).

Әбү Талибның улы Гали кәррамәлләһу вәҗһәһудән риваять ителә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Өч төр кеше оҗмахка кермәс:

1. Даими хәмерне кулланучы кеше (хәмер дигәндә, аңны миңгерәтә торган теләсә нәрсә күз алдында тотыла);

2. Туганлык мөнәсәбәтләрен өзгән кеше;

3. Сихерчегә ышанган кеше», – дип әйтә (Имам Әхмәд).

Ниндидер сихри әфсеннәре булган әйберләрне муенга, киемгә һәм беләккә тагу Ислам динендә рөхсәт ителми. Мондый гамәлләр тора-бара кешене мәҗүсилеккә китерергә мөмкин. Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе тапшырулары буенча, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әфсеннәр (Рукъя), әфсенле бөтиләр (Тамаим), сөйдергеч әфсеннәр (Тиваля) – ширек», – дип әйткән[1].

Бу хәдистә Рукъя (әфсеннәр) сүзе астында, Ислам диненә кадәр булган әфсеннәр күз алдында тотыла.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам тагын: «Күрәзәчегә килеп, аның сүзләренә ышанган кеше – иманыннан, Мөхәммәдкә иңдерелгәннән (Коръәннән) ваз кичкән кеше була «, — дип әйткән.

Сихерчелек — зур гөнаһ, чөнки сихерче үзе генә иманыннан язып калмый, ә аңа мөрәҗәгать иткән кешене дә иманыннан яздыра. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

[1] Имам Әхмәд, Әбү Давыд, ибне Мәҗәһ.

**«Шәйтаннар имансыз булдылар, чөнки сихер китабын алар язды һәм (аларны Аллаһы диненнән чыгарып) кешеләргә өйрәттеләр.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:102

## Күрәзәлек: ялганмы әллә чынмы?

Әгәр сихерчеләр киләчәкне юраган вакытта кайбер вакытларда ни дә булса дөрес әйтәләр икән, болар барысы да – иблис вәсвәсәләре. Иблис, Аллаһының фәрештәләргә биргән боерык һәм күрсәтмәләрен тыңлап торып, үзе ишеткәннәренең кайберләрен сихерчеләргә җиткерә, ә соңгылары исә, ул ишеткәннәренә үзләренең гөман, фараз һәм хыялларын өстәп, ярдәм сорап килүче кешегә ниндидер бер «ачыш» итеп тәкъдим итә. Күп кешеләр үзләренең киләчәкләрен белү һәм аны яхшырту өчен сихерче һәм күрәзәләргә мөрәҗәгать итәләр, ләкин тәкъдир — бары тик Аллаһы Тәгалә кулында, бер генә җан иясе дә Аллаһы ризалыгыннан башка үз тәкъдирен үзгәртә алмый. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Әйт: «Мин үземә файданы да, зарарны да китерүче түгелмен, ул Аллаһы эшедер, Ул нәрсә теләсә, миңа шул ирешер. Әгәр Мин (яшерен) файдаларны белә торган булсам, әлбәттә, үземә күп файдаларны булдырыр идем һәм Миңа һичбер зарар ирешмәс иде ...»**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:188

## Сихерче һәм ялган дәвалаучыларның киң таралган билгеләре

1. Алар авыруның нинди дә булса берәр әйберен (мәсәлән, аның фоторәсемен, чәч бөртекләрен, киеменең берәр кисәген һ.б.) китерүне сорыйлар. Ислам галимнәре алар турында: «Яшерен һәм серле белемнәргә иямен диюче һәркем янына йөрергә кирәкми! Күлмәкне дә, башка киемне дә, гомумән, бернәрсәне дә, алар сорады, дип алып барырга ярамый», – дип әйтәләр;

2. Алар ниндидер аңлаешсыз сүзләр, әфсеннәр укыйлар яки язалар;

3. Корбан итеп китерергә ниндидер берәр җан иясен (күгәрчен, тычкан, күсе, куян, һ.б.; алар сораган ул җан иясе хәтта чебен дә булырга мөмкин) алып килүне сорыйлар. Гадәттә, аларның кара төстәгеләрен китерергә кушалар, чөнки җеннәргә кара төс ошый;

4. Алар ниндидер хәрефләр, тамгалар, сүзләр язылган кәгазь бирергә мөмкиннәр. Аны суда тотып, шул суны эчәргә тәкъдим итәләр;

5. Алар нинди дә булса әйберләр биреп, аны каядыр илтеп күмәргә кушалар. Бу – бозым – сихернең бер төре;

6. Алар караңгы, кояш нуры үтмәгән бүлмәләрдә булырга яраталар, чөнки җеннәр дә караңгылык ярата;

7. Алар ниндидер кәгазь бирәләр дә, аны яндырып, шуның төтенен үзеңә төтәтергә кушалар;

8. Алар кергән кешенең исемен, аның әнисенең исемен, аның торган җирен, авыруын әйтеп бирергә мөмкиннәр, чөнки бу мәгълүматларны аларга җеннәр җиткерә, һәм шул ук җеннәр аларга сихердә ярдәм итәләр.

## Сихердән дәвалау

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

**«Без мөэминнәрнең күңелләренә шифалы аятьләрне вә Коръәннән рәхмәтле хөкемнәрне иңдерәбез»**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:82

Нинди авыру Раббыбыз, җир һәм күк Хакиме Сүзенә каршы тора алсын? Әгәр дә ул таулар эченә кереп качкан икән, Ул шул тауларны ярыр иде, әгәр дә ул авыру җир эченә кереп яшеренсә, Ул шул җирне актарып ташлар иде. Коръәндә җан һәм тәннең бар сырхауларының да сәбәбе күрсәтелгән, аларны дәвалау ысуллары да, һәм шулай ук, Аның Китабын аңлаучыларга авырулардан саклану юллары да.

Сихерне икенче сихер белән дәвалау шәригать тарафыннан тыелган һәм имансызлык чагылышы булып тора. Җәбир: «Аллаһы Расүленнән сихерне (икенче бер сихер белән) дәвалау турында сорагач, ул: «Бу – шәйтан гамәлләренең берседер», – дип сөйләде» , – дип әйткән. Сихерне рөхсәт ителгән дәвалау – Коръән аятләре, зикерләр, догалардан торган рукъя укудан тора. Гайшә радыяллаһу ганһә шундый бер вакыйганы сөйләгән: «Бервакыт, бер хатын рукъя укып (бер кешене) дәвалаган вакытта, Аллаһының Расүле галәйһиссәлам, аңа кереп, ул дәвалаучыга: «Аны Аллаһы Китабы белән дәвала!» – дигән.

*«Сихердән сак булыгыз» китабыннан,*

*«Хозур» нәшрият йорты, 2013*

# Намазда сафларның тигезлеге

Имам Бохари үзенең сахих хәдисләр җыентыгы китабында Әнәс бине Мәликнең сүзләрен китерә: «Без һәрберебез җилкәләребезне вә табаннарыбызны янәшәдә торучы кеше белән тигезли идек».

Шулай ук Әбү Давыдтан килгән хәдистә Пәйгамбәребезнең сүзләре җиткерелә: «Рәтләрегезне тигез сафларга тезегез, җилкәләрегез буенча тигезләнегез, буш урыннарны тутырыгыз, – шуңа өстәп ул – рәтләрегезне тыгызлагыз, аларны якынайтыгыз һәм муеннарыгызга карап тигезләнегез», – дип әйткән.

Намаз укучы мөселманнардан тыгыз рәвештә рәтләргә тезелергә, җилкәләрне җилкәләргә вә табаннарны табаннарга тидерәсе була. Бер кешенең гәүдәсе икенче кешенең гәүдәсенә тиеп торырга тиеш. Монда аерым табаннарны гына тигезләү һәм тыгызлау турында сүз алып барылмый, чөнки табан аралары гына тыгызланса, намаз укучылар бер-берсеннән ерагая да алалар. Әгәр дә андый рәтләргә күз төшерсәң, аларның гәүдәләре арасында байтак кына урын калган икәнен һәм табаннар кушылган җирдә генә аз урын калганын күрәсең. Әлбәттә, мондый рәвештә басу бик дөрес түгел һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дә сөннәтенә каршы килә.

Кайбер мәчетләргә кергәч, үзенең аяк араларын зур итеп калдырып, янәшәдә басып торучы кешенең табанына тыгыз итеп куеп, намаз укучыны күрергә була. Ә гәүдә арасы, җилкә белән җилкә арасы 20-30 см га кадәр җитә. Вә шул рәвешле андый кешеләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен үтибез дип уйлыйлар, чөнки аяклар тыгыз итеп куелган. Ә бит янәшәңдә басып торучыны гәүдәң белән тоймасаң, алар белән бер сафта тормасаң, бу пәйгамбәребезнең сөннәтенә туры килми.

Икенче бер мәсьәлә булып бу эшләрдә урталыкны саклау тора.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең урталыкны сайлагыз дигән сүзләрен һәркемнең ишеткәне бардыр. Әмма ни өчендер, колак салмыйча, киресен эшләргә яратабыз. Нинди дә булса бер гамәл кылганда урта юл белән бару – хәерле күренештер. Ә гыйбадәтне төркем белән кылганда, урталыкның әһәмияте тагын да арта. Шулай ук намаз укыганда да.

Сафларга тезелү мәсьәләсен генә алыйк. Калабыз мәчетләренә намаз укырга кергәч, табаннарын янәшә торучы кешенең табанына артык тыгыз итеп куючы кешеләрне күрәсең. Бу – артыклык. Янәшәдә басып торучыларга комачаулый һәм уңайсызлыклар тудыра. Намаз уртасында шулай итеп аякларны артык тыгызлап куйгач, күрше кеше шуңа игътибар итеп, намазында ихласлыгын югалтырга мөмкин. Ә мондый төр тыгызлану сөннәткә туры киләме соң?

Беренчедән, Пәйгамбәребезнең Бохари хәдисләр җыентыгында килгән мондый хәдисе бар: «Рәтләрегезне тигезләгез, югыйсә Аллаһы Тәгалә сезнең арагызга төрле каршылыклар урнаштырачак». Шушы хәдисне җиткерүче Ән-Ногман бине Бәшир: «Шуннан соң мин бер сәхабәнең табаннарын вә җилкәләрен янәшә торучыларга тыгыз итеп куеп басканын күрдем», – дип әйтә. Хәдискә күз салсак, пәйгамбәребез рәтләрне тигезләргә генә кушты. Ә тигезләнү нәкъ менә аяк табаннары, җилкәләр белән башкарыла, чөнки кеше рәттән алга-артка чыгып тормаска тиеш. Ә Ногманның «шуннан соң мин бер сәхабәнең табаннарын вә җилкәләрен янәшә торучыларга тыгыз итеп куеп басканын күрдем» сүзләренә карасак, бу кеше, намаз башланыр алдыннан, үзенең бер сафта тигез торганына инаныр өчен эшләгән булса кирәк. Шуңа күрә, әгәр кеше үзен сафта тигез торганына инанса, ул артык тыгызланмаса да була. Һәм бигрәк тә намаз уртасында, кешене намазыннан, хошугълыгыннан бүлү куркынычы бар.

Ә хәзер күз алдыгызга китереп карагыз әле: сез ике яктагы кешенең дә табанына үзегезнең табаннарыгызны тыгыз итеп куяр өчен, сезгә ая-

кларыгызны борырга да туры килүе бар. Җилкәләр белән дә: бер якка терәп куйсаң, икенче якта урын күбрәк калачак. Хәдистә дә исә, артык тыгызлану турында әйтелмәгән. Иң мөһиме: рәтләр тигез булырга тиеш. Гомәр радыяллаһу ганһе намазга имам булып басканда рәтләр буенча йөреп, аларның тигезлеген карап чыга торган иде.

Бер-беребезгә хөрмәт белән карап, арабызда буш урын калдырмыйча, шулай ук калганнарга уңайсызлыклар тудырмыйча, намазларыбызны Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырлык итеп, хошугълык белән укырга язсын.

# Йәгез, бер дога!

# «Кәнзүл-Гареш» догасы

بسم الله الرحمن الرحيم

لاَ إِلهَ إِلاَّ اللّٰهُ، لاَ إِلهَ إِلاَّ اللّٰهُ، لاَ إِلهَ إِلاَّ اللّٰهُ الْمَلِكُ الْحَقُّ الْمُبِيْنُ. لاَ إِلهَ إِلاَّ اللّٰهُ الْحَكَمُ الْعَدْلُ الْمَتِيْنُ. رَبُّنَا وَرَبُّ أٰبَائِنَا الأَوَّلِيْنَ. لاَ إِلهَ إِلاَّ أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِيْنَ. لاَ إِلهَ إِلاَّ اللّٰهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيْكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ يُحْيِي وَيُمِيْتُ وَهُوَ حَيٌّ دَائِمٌ لاَيَمُوْتُ أَبَدًا بِيَدِهِ الْخَيْرُ وَإِلَيْهِ الْمَصِيْرُ وَهُوَ عَلى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيْرٌ. وَبِه نَسْتَعِيْنُ وَلاَحَوْلَ وَلاَقُوَّةَ إِلاَّ بِاللّٰهِ الْعَلِيِّ الْعَظِيْمِ. لاَ إِلهَ إِلاَّ اللّٰهُ شُكْرًا لِنِعْمَتِهِ، لاَ إِلهَ إِلاَّ اللّٰهُ إِقْرَارًا بِرُبُوْبِيَّتِهِ. وَسُبْحَانَ اللّٰهِ تَنْزِيْهًا لِعَظَمَتِه. أَسْأَلُكَ اللّٰهُمَّ بِحَقِّ اسْمِكَ الْمَكْتُوْبِ عَلى جَنَاحِ جِبْرِيْلَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَ بِحَقِّ اسْمِكَ الْمَكْتُوْبِ عَلى مِيْكَائِيْلَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الْمَكْتُوْبِ عَلى جَبْهَةِ إِسْرَافِيْلَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الْمَكْتُوْبِ عَلى كَفِّ عَزْرَائِيْلَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ سَمَّيْتَ بِه مُنْكَرًا وَنَكِيْرًا عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ وَأَسْرَارِ عِبَادِكَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ تَمَّ بِهِ الإِسْلاَمُ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ تَلَقَّاهُ أٰدَمُ لَمَّا هَبَطَ مِنَ الْجَنَّةِ فَنَادَاكَ فَلَبَّيْتَ دُعَاءَهُ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَكَ بِه شِيْثُ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ قَوَّيْتَ بِه حَمَلَةَ الْعَرْشِ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اَسْمَائِكَ الْمَكْتُوْبَاتِ فِى التَّوْرَاةِ وَالإِنْجِيْلِ وَالزَّبُوْرِ وَالْفُرْقَانِ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ

اَسْمَائِكَ إِلى مُنْتَهى رَحْمَتِكَ عَلى عِبَادِكَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ تَمَامِ كَلاَمِكَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه إِبْرَاهِيْمُ فَجَعَلْتَ النَّارَ عَلَيْهِ بَرْدًا وَّسَلاَمًا عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه إِسْمَاعِيْلُ فَنَجَّيْتَهُ مِنَ الذَّبْحِ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه إِسْحَاقُ فَقَضَيْتَ حَاجَتَهُ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه هُوْدٌ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ دَعَاكَ بِه يَعْقُوْبُ فَرَدَدْتَ عَلَيْهِ بَصَرَهُ وَوَلَدَهُ يُوْسُفَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه دَاوِدُ فَجَعَلْتَه خَلِيْفَةً فِى الأَرْضِ وَأَلَنْتَ لَه الْحَدِيْدَ فِى يَدِه عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ دَعَاكَ بِه سُلَيْمَانُ فَأَعْطَيْتَه مُلْكَ الأَرْضِ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه أَيُّوْبُ فَنَجَّيْتَه مِنَ الْغَمِّ الَّذِيْ كَانَ فِيْهِ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه عِيْسى ابْنُ مَرْيَمَ فَأَحْيَيْتَ لَهُ الْمَوْتى عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه مُوْسى لَمَّا خَاطَبَكَ عَلى الطُّوْرِ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَتْكَ بِه أَسِيَةُ امْرَأَةُ فِرْعَوْنَ فَرَزَقْتَهَا الْجَنَّةَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه بَنُوْ إِسْرَائِيْلَ لَمَّا جَاوَزُوْا الْبَحْرَ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه الْخَضِرُ لَمَّا مَشى عَلَى الْمَاءِ عَلَيْكَ يَارَبِّ. وَبِحَقِّ اسْمِكَ الَّذِيْ نَادَاكَ بِه مُحَمَّدٌ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَوْمَ الْغَارِ فَنَجَّيْتَه عَلَيْكَ يَارَبِّ. إِنَّكَ أَنْتَ الْكَرِيْمُ الْكَبِيْرُ. وَحَسْبُنَا

اللّٰهُ وَنِعْمَ الْوَكِيْلُ وَلاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللّٰهِ الْعَلِيِّ الْعَظِيْمِ. وَصَلَّى اللّٰهُ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِهِ وَصَحْبِهِ وَسَلَّمَ

**Мәгънәсе:** Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы исеме белән.

Аллаһыдан башка бернинди илаһи зат юк, Аллаһыдан башка бернинди илаһи зат юк. Ачык, хак падишаһ булучы Аллаһыдан башка бернинди илаһи зат юк. Хөкем иясе, гадел һәм таянычлы Аллаһыдан башка бернинди илаһи зат юк. Безнең Раббыбыз һәм әүвәлге ата-бабаларыбызның Раббысы, Синнән башка бернинди илаһи зат юк, Син барча кимчелекләрдән пакь, ә мин үз-үзен кыерсытучы залимнәрдән булдым. Аллаһыдан башка бернинди илаһи зат юк, Ул бердер, Аңа тиңдәш юк, Аның кулында падишаһлык, Ул гына барча мактауларга лаек, Ул гына тереклек бирә һәм үтерә. Ул мәңге яшәүче, беркайчан да үлмәс, бөтен хәерле булган нәрсә Аның кулында, соңгы кайту урыны Аның каршына һәм Ул һәрнәрсәне эшләргә кодрәтле. Без Аның Үзеннән ярдәм сорыйбыз, биек һәм бөек Аллаһыда гына көч һәм куәт. Аллаһыдан башка илаһи зат юк, нигъмәтләре өчен Аңа шөкер кылабыз. Аның Раббы икәнен тәсдикъләп, Аллаһыдан башка илаһи зат юк. Аллаһы Үзенең бөеклеге белән барча кимчелекле сыйфатлардан пакь. Әй, Раббым Аллаһы, Җәбраил галәйһиссәламнең канаты өстенә язылган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Микаил галәйһиссәламнең канаты өстенә язылган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Исрафил галәйһиссәламнең маңгае өстенә язылган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Синнән сорыйм Газраил галәйһиссәламнең кулы өстенә язылган исемеңнең хакы-хөрмәтенә. Әй, Раббым Аллаһы, Үзең атаган Мөнкәр вә Нәкир исемнәре хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, исемеңнең һәм колларыңның серләренең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Ис-

лам диненең камилләшүен тәмам иткән исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Җәннәттән куылганнан соң Адәм галәйһиссәламгә иңдерелгән, шуның белән ул Сиңа ялварган һәм Син аның догасын кабул иткән исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Шис галәйһиссәлам Сиңа ялварган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Гареш фәрештәләренә куәт бирә торган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Тәүратта, Инҗилдә, Зәбурда һәм Фурканда (Коръәннең башка исеме) язылган исемнәреңнең Синең каршыңдагы хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, колларыңа рәхмәтеңне тулысынча ирештер дип, исемнәреңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Синең камил Каләмеңнең (сүзеңнең) хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Ибраһим галәйһиссәлам дога кылып ялварганнан соң, Син аның өчен утны салкынлык һәм тынычлык бакчасына әйләндергән исемеңнең Синең каршыңдагы хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Исмәгыйль галәйһиссәлам дога кылганнан соң, Син аны чалынудан коткарган исемеңнең Синең каршыңдагы хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Исхак галәйһиссәлам дога кылып, Сиңа ялварганнан соң, Син аның хаҗәтен үтәгән исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Һуд галәйһиссәлам дога кылып, Сиңа ялварган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Ягъкуб галәйһиссәлам дога кылып, Син аның күзләренең нурын (күрү сәләтен) һәм баласы Йосыф галәйһиссәламне кайтарган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Давыд галәйһиссәлам дога кылганнан соң, Син аны җир йөзендә хәлифә иткән һәм тимерне аның кулында эреткән исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Сөләйман галәйһиссәлам дога кылганнан соң, Син аңа җир йөзендә падишаһлык биргән исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы,

Әюб галәйһиссәлам дога кылганнан соң, Син аның эчендә булган кайгыдан аны коткарган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Мәрьям улы Гайсә галәйһиссәлам дога кылганнан соң, Син аның өчен үлгәннәрне терелткән исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй Раббым Аллаһы, Муса галәйһиссәлам Тур тавында Синең белән сөйләшкәндә, Сиңа дога кылган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Фиргавен хатыны Асия, Сиңа дога кылганнан соң, Син аны җәннәт белән нигъмәтләгән исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Исраил балалары диңгез аша чыкканда Сиңа дога кылган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, су өстендә барган вакытында Хозыр галәйһиссәлам дога кылган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Әй, Раббым Аллаһы, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм җиңү көнендә Сиңа дога кылганнан соң, Син аны коткарган исемеңнең хакы-хөрмәтенә Синнән сорыйм. Йә Раббым! Чынлыкта, Син юмартлык һәм бөеклек Иясе. Безгә Аллаһы җитә һәм Ул –иң хуш таяныч. Биек һәм бөек Аллаһыдан башка бүтән затта көч һәм куәт тә юк. Әфәндебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның әһеленә һәм сәхабәләренә Аллаһы Тәгаләнең салаваты һәм сәламе булсын.